Хәмидуллина, Р. Җаннар назга төренә: [Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция] / Р. Хәмидуллина // Хәмидуллина, Р. Китапханә сәхнәсе. Китапханәчеләргә, балалар бакчалары тәрбиячеләренә, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек. 1 нче чыгарылыш / Р. Хәмидуллина. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2012. – Б.101-110.

Сәләхова, Ф. Елда көтеп алына торган фестиваль: [Г. Афзал исемендәге иҗат фестивале кунагы шагыйрә] / Ф. Сәләхова // Актаныш таңнары. – 2012. – 30 май.

Кайнар табадан төште сөенеч өләшүче китапчыклар: [«Башмаклы мәче», «Санагыч» китаплары чыгу уңаеннан] // Актаныш таңнары. – 2012 – 30 май.

Ил-көн хәбәрләре: [шагыйрә Ә. Ситдыйкованың А.С. Грибоедов премиясенә лаек булу хакында] // Актаныш таңнары. – 2012. – 6 июнь.

Хәлим, А. Иҗатына бер караш: [шагыйрәнең «Яшәр өчен килдем» дип исемләнгән нәсерләр китабының кулъязмасына сүз башы] / А. Хәлим // Мәйдан. – 2012. – № 7. – Б.103-104.

Хәмидуллина, Р. Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә: [шагыйрәнең «Утлы җимеш» шигырьләр җыентыгы чыгу уңаеннан] / Р. Хәмидуллина // Мәйдан. – 2012. – № 7. – Б.104-105.

Иҗат дәрте белән яши: [шагыйрә иҗаты турында] // Шәһри Чаллы. – 2012. – 15 авг.

Әхтәмова, И. Шагыйрь иҗатын өйрәнгән шагыйрә...: [«Нур Баянның шигъри дөньясы» китабы чыгу уңаеннан] / И. Әхтәмова // Шәһри Чаллы. – 2012. – 22 авг.

Хәмидуллина, Р. Тугандыр ул моңга уралып: [шагыйрә Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышланган кичә турында] / Р. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2012. – 26 окт.

Фәхертдинова, С. Телләр дуслыгы – милләтләр татулыгы: [телләр дуслыгына багышланган очрашу кунагы шагыйрә Әлфия Ситдыйкова] / С. Фәхертдинова // Көмеш кыңгырау. – 2013. – 10 май.

Галиева, С. Встреча с поэтессой Альфией Ситдиковой: [о ежегодных встречах в Набережных Челнах на радио «Күңел»] / С. Галиева // Мизгелләр Мгновения. – Әлфия Ситдыйкова белән очрашулар хакында / С. Галиева. – Алматы, п. Таугуль, ул. Центральная 3 Б.: ТОО «Таугуль-Принт», 2013. – Б. 21-22.

## *2014*

Хәмидуллина, Р. Шигырь белән тулган барлык җиһан...: [«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе эшчәнлеге, шагыйрә Әлфия Ситдыйкова турында сүз бар] / Р. Хәмидуллина // Мәдәни җомга. – 2014. – 21 февр.

Фәрхетдинова, Ч. Заманча китап «Бакча»сы: [«Замана авторлары – балаларга» проекты «Иң яхшы нәшир» – Әлфия Ситдыйкова] / Ч. Фәрхетдинова // Мәдәни җомга. – 2014. – 18 апр.

Хәмидуллина, Р. Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә: [Әлфия Ситдыйкованың «Утлы җимеш» шигъри җыентыгына күзәтү] / Р. Хәмидуллина // Хәмидуллина, Р. Китапханә сәхнәсе. Китапханәчеләргә, балалар бакчалары тәрбиячеләренә, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек. 2 нче чыгарылыш / Р. Хәмидуллина. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2014. – Б. 91-96.

Әлфия Ситдыйкова: [шагыйрәнең биографиясе, библиографиясе бирелгән] // Әдәби Чаллы / төз.: Р. Хәмидуллина, Ә. Ситдыйкова,– Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 203–207.

Хәлимов, З. Утлы җимешләрен авыз иттем: [шагыйрәнең «Утлы җимеш» китабы чыгу уңае белән / З. Хәлимов // Шәһри Чаллы. – 2015. – 27 февр.

Ай кызы. Бакча туган тел бәйрәме: [49 нчы санлы балалар бакчасында «Туган тел» көне атналыгы кунагы шагыйрә Әлфия Ситдыйкова] / Ай кызы // Көмеш кыңгырау. – 2015. – 7 март.

Якупова, С, Шагыйрьле авыл – бәхетле авыл: [язучы Ш. Шәйдуллинның тууына 76 ел тулу уңае белән үткәрелгән очрашу кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / С. Якупова // Шәһри Чаллы. – 2015. – 18 март.

Зарипова, Н. Язучылар десанты – 21 нче мәктәптә [«Ләйсән» берләшмәсенең эшчәнлеге, Әлфия Ситдыйкова турында да сүз бар] / Н. Зарипова // Шәһри Чаллы. – 2015. – 17 апр.

Шәкүрова, З. Шигырь белән тулган барлык җиһан...: [Әдәбият елы уңае белән 12 нче китапханәдә үткән чара кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / З. Шәкүрова // Шәһри Чаллы. – 2015. – 6 май.

Әнәсова, А. Бүген бездә бәйрәм: [37 нче мәктәп укучылары белән шагыйрә Ә. Ситдыйкова очрашты] / А. Әнәсова // Көмеш кыңгырау. – 2015. – 23 май.

Гасыймова, Р. Әкият иленә сәяхәт: [Арча төбәгендә – Тукай эзләрен саклаган Кушлавыч, Кырлай якларына сәяхәттә шагыйрә Ә. Ситдыйкова булып кайтты] / Р. Гасыймова // Көмеш кыңгырау. – 2015. – 30 май.

Гасыймова, Р. Татар гаме, Тукай рухы монда!: [Түбән Кама шәһәрендә «Габдулла Тукай исемендәге ял һәм уку паркы»нда үткән чара кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / Р. Гасыймова // Көмеш кыңгырау. – 2015. – 26 сент.

Абдуллина, С. Чаллы каләм ияләрен зурлый: [кичә кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / С. Абдуллина // Көмеш кыңгырау. – 2015. – 12 дек.

Хәмидуллина, Р. «Бишле билгесе куям»: [Әлфия Ситдыйкова иҗаты буенча шигъри композиция] / Р. Хәмидуллина // Хәмидуллина, Р. Китапханә сәхнәсе. Китапханәчеләргә, балалар бакчалары тәрбиячеләренә, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек. 3 нче чыгарылыш / Р. Хәмидуллина. – Казан: Редакционно-издательский центр, 2016. – Б. 40-46.

Миннәхмәтова, Э. Серле дә, күңелле дә очрашу: [6 нчы санлы шәһәр китапханәсе кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / Э. Миннәхмәтова // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 6 февр.

Ульданова, Ә. Язучылар килделәр: [28 нче санлы мәктәптә шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / Ә. Ульданова // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 7 февр.

Хәлимов, З. Утлы җимешләрдән авыз иттем: [шагыйрә Ә. Ситдыйкованың «Утлы җимеш» шигъри җыентыгы турында] / З. Хәлимов // Безнең фикер. – 2016. – 27 февр.

Хәкимуллина, Л. Кояштай ягымлы шагыйрә: [шагыйрә Ә. Ситдыйкова кичә кунагы] / Л. Хәкимуллина // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 27 февр.

Хәлимов, З. Китаплар белән таныштык: [27 май Гомумроссия китапханәләр көне уңае белән үткән кичәдә шагыйрә Ә. Ситдыйкова иҗаты турында сүз булды] / З. Хәлимов // Шәһри Чаллы. – 2016. – 3 июнь.

Мартынова, М. Мөслимгә сәяхәт: [бертөркем язучылар арасында шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / М. Мартынова // Шәһри Чаллы. – 2016. – 10 июнь.

Әхмәтҗанов, М. Өзелмәсен хәтер җепләре: [Әлфия Ситдыйкованың «Хәтер җебе» китабы басылып чыгу уңаеннан] / М. Әхмәтҗанов // Мәдәни җомга. – 2016. – 15 апр.

Гыйззәтуллина, Ф. Иҗади сабантуй: [шагыйрә Ә. Ситдыйкова белән очрашу] / Ф. Гыйззәтуллина // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 26 апр.

Рәхмәтуллина, Р. Тукайга чәчәкләр: [шагыйрә Ә. Ситдыйкова кичә кунагы] / Р. Рәхмәтуллина // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 30 апр.

Галим, З. Телсез, имансыз кеше – иң бәхетсез кеше: [Тукай районы Боерган авылында үткәрелгән кичә кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / З. Галим // Шәһри Чаллы. – 2016. – 27 июль.

Хәлимов, З. Тагын бер очрашу: [әдәбият елы уңае белән үткәрелгән кичә кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / З. Хәлимов // Шәһри Чаллы. – 2016. – 14 авг.

Зарипова, Н. Гомернең моңлы агышы: [шагыйрә Ә. Ситдыйкова 21 нче мәктәп кунагы] / Н. Зарипова // Көмеш кыңгырау. – 2016. – 8 окт.

Зарипова, Н. Гомернең моңлы агышы: [шагыйрәнең 21 нче мәктәптә үткән кичәдә катнашуы турында] / Н. Зарипова // Шәһри Чаллы. – 2016. – 12 окт.

Ганиева, Н. Исеме халык телендә: [шагыйрә Әлфия Ситдыйкова Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә лаек булды ] / Н. Ганиева // Хәзинә. – 2016. – 2 нояб.

Якупова, С. Халкына хезмәт итүче: [«Мин дөньяны үзем иҗат итәм» Әнвәр Шәрипов иҗатына багышланган кичә кунагы шагыйрә Ә. Ситдыйкова] / С. Якупова // Шәһри Чаллы. – 2016. – 16 дек.

## Ә. Ситдыйкова сүзләренә иҗат ителгән җырлар

Ситдыйкова, Ә. Язмышлар; Бәхет кошы; Яшел яфрак; Кил әле; Хисләр бураны: [җырлар] / Ә. Ситдыйкова сүз., Ф. Талипова көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Бәхетле бул; Соңгы сөю: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Илнур Фәйзуллин көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Яныйк әле: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., М. Гәзетдинов көе, Б. Нигъмәтуллин, З+З.Билалов башкаралар // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Соңга калма: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., М. Гәзетдинов көе, М. Гәзетдинов башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Бәхет төне: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Р. Әхмәтханов көе, Айзирә Әхмәтханова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Синең караш – илһам чишмәсе: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Р. Нәгыймов көе, Дания Сибгатуллина башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Әнкәй: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Г. Идрисова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Балан: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Ф. Миннебаев көе, Ф. Гәрәева башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Унҗиде яшь: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., И. Фәйзуллин көе, Румия Фәтхетдинова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Зөбәйдә чишмәсе: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Гөлсинә Акбитова көе, Г. Акбитова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Иркен туган авылым: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Гөлсинә Акбитова көе, Г. Акбитова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Җанда кабынган учак: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Илнур Фәйзуллин көе, И.Фәйзуллин башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Бергә булыйк: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., А. Якшимбетов көе, Гөлнара Габидуллина башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Ак җилкән: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., А. Якшимбетов көе, Радик Шаяхметов башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Түз йөрәгем: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Рубис Зарипов көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Бусагама минем килерсең: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Р. Зарипов көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Наз илендә: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., И. Фәйзуллин көе, Эльнара Нурмөхәммәтова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Кичер мине: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Ф. Талипова көе, Ә. Әгъзәмова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Мизгел: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Гөлсинә Акбитова көе, Г. Акбитова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Син: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Гөлсинә Акбитова көе, Э. Сабирова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Яңа ел җыры: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Риназ Әхмәтов көе, Дания Сибгатуллина башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Сөю: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Илнур Фәйзуллин көе, И. Фәйзуллин башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Син – бүгенге көнем: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Гөлсинә Акбитова көе, Г. Акбитова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Сөю: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., М. Исхаков көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. «Мин тагын да иске хистән кабындым бер...»: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Илнур Фәйзуллин көе, И. Фәйзуллин башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Әдәмсу – туган авылым: [җыр] / Ә. Ситдый-

кова сүз., Г. Акбитова көе, Г. Акбитова башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Яралы сандугач. Рәйсә: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Имамиева көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Елама җаным: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Мәсгут Исхаков көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Туган көн: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 65.

Ситдыйкова, Ә. Кайтам сиңа, Актаныш: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе, Робсон Мусин башкара // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 84.

Ситдыйкова, Ә. Синдәй яр табалмам мәңгегә: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе, Сәрия Нәбиуллина башкара // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 119.

Ситдыйкова, Ә. Сөю: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Мәсгут Исхаков көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Алабуга җыры: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Мин яшьлекне җырлыйм: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 119.

Ситдыйкова, Ә. Сабантуе гүзәле: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 44.

Ситдыйкова, Ә. Күҗәкә җыры: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Илдар Шәмсетдинов көе / Рәзилә Галиева башкара // Актаныш басмалары: [җырлар, ноталар] / Төзүчесе Ләбиб Лерон. – Казан., «ТАТМЕДИА» «ПИК»«Идел-Пресс»., 2010. – Б. 112.

Ситдыйкова, Ә. Светофор: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Мәсгут Исхаков көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Күҗәкә авылы җыры: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Инсаф Хәбибуллин көе, Рәзилә Галиева башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Аксыбы авылы көе: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Флүрә Талипова көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Икшермә авылы көе: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Флүрә Талипова көе // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Яңа ел җыры: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Ринас Әхмәтов көе, Дания Сибгатуллина башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Җилкән: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе, Дания Сибгатуллина башкара // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 57.

Ситдыйкова, Ә. Язлар үтеп бара димә: [җыр, нота] / Ә. Ситдыйкова сүз., Факил Сафин көе // Сафин, Ф. Җыр – гомер ул!: [зурлар һәм балалар өчен җырлар] / Ф. Сафин. – Казан., РИО ГБУ «РЦМКО»., 2013. – Б. 144.

Ситдыйкова, Ә. Яратасым килә үзеңне: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Айдар Тимербаев көе, Зинира һәм Ризат Рамазановлар башкара // Шәхси архивта саклана.

Ситдыйкова, Ә. Үкенмим: [җыр] / Ә. Ситдыйкова сүз., Айдар Тимербаев көе, Илсөя Бәдретдинова башкара // Шәхси архивта саклана.

# Шагыйрә Ә. Ситдыйкова фотолары урын алган җыентыклар

Сабакташым Рәдиф Гаташ белән Чаллы ханымнары янында (Роберт Миңнуллинның иҗат кичәсеннән соң) 30.10.2008.(Әлфия Ситдыйкова, Рәдиф Гаташ, Ләйсән, Хатыйп Миңнегулов, Роза Хәмидуллина): [фотосурәт] // Хатыйп Миңнегулов турында. О профессоре Миннегулове (На татарском и русском языках) / Х. Миңнегулов. – Казан: Идел-Пресс. 2009. – Б. 352–353.

Каләм осталары хезмәт һәм сугыш ветераннары арасында. Урындыкта утырганы – Советлар Союзы Герое И.Маннанов. 1983 ел: [фотосурәт] // Мәйдан. – 2010. – № 1. – Б. 85.

Чаллы Язучылар оешмасына 30 ел. Ә. Ситдыйкова, Ф. Дунай, Ф. Сафин, Р. Бәшәр, Ш. Шәйдуллин (2004 ел): [фотосурәт] // Мәйдан. – 2010. – № 1. – Б. 108.

Язучы Әмирҗан Моталлаповның 70 яшьлек юбилей кичәсендә: Вахит Имамов, Факил Сафин, Әлфия Ситдыйкова, Мирһади Разов: [фотосурәт] // Актаныш таңнары. – 2004. – 30 сент. – Б. 3.

Корабль времени или Вспоминания...// Встреча со студентами Набережночелнинского Автомеханического техникума. 28.04.2010. Вера Хамидуллина. Корабль времени или Воспоминания...(лирика)/ Казань. Идел-Пресс. 2010. – С. 152.

Авыл җаны үлемсезме?: [«Авыл җаны – Күҗәкә горурлыгы» китабын тәкъдир итү кичәсендә Сәяф Хаҗиев, Шамилә Акмалова, Әлфия Ситдыйкова, Вахит Имамов]: [фотосурәт] // Актаныш таңнары. – 2010. – 3 ноябрь. – Б. 4.

Шифалы орлыклар үсенте бирсен (Чаллы шәһәренең 37 нче мәктәбендә укучылар белән очрашу мизгелләре): [фотосурәт] // Шәһри Чаллы. – 2011. – 5 март.

Тукайның – 125, Гамил Афзалның 90 еллыгы уңаеннан. Илһамлы канат бирүче фестиваль. Такталачык авылы кунаклар кабул итә: [фотосурәт] // Актаныш таңнары. – 2011. – 25 май.

«Көмеш кыңгырау» бәйрәме (газета көне уңаеннан узган чарада): [фотосурәт] // Көмеш кыңгырау. – 2011 ел. – 7 май.

## Награды и поощрения

• Почетная грамота Центральной городской библиотеки имени Мусы Джалиля. (2007)

• Почетная грамота ГУ «Телерадиокомпания «Чаллы-ТВ» за добросовестный труд и в связи с 50-летием. (2007)

• Награждена Грамотой «Телерадиокомпания «Чаллы-ТВ» за многолетний безупречный труд во благо процветания телерадиокомпании. (2009)

• Благодарственное письмо Управления образования Исполнительного комитета г.Набережные Челны благодарит Ситдикову Альфию Мирзануровну за активное участие в работе Научно-методического центра изучения духовного наследия и пропаганду творчества поэтов и писателей г.Набережные Челны и региона. (2009)

• Благодарственное письмо Главы Актанышского муниципального района. (2010)

• Диплом и медалью «За солнечную деятельность» Международной акции «Солнечный храм». (2010)

• Муниципальное учреждение «Информационно-методический центр» города Набережные Челны благодарственное письмо информационно-методический центр выражает благодарность Ситдиковой Альфие Мирзануровне за организацию и проведение городской научно-практической конференции школьников «Литературное наследие». (2010)

• Филиал ОАО «Татмедиа» детская и юношеская редакция газеты «Серебряный колокольчик» на основе редакционного Совета присваивает заслуженное звание Ситдиковой Альфие Мирзануровне «Писатель – наставник» № 007 за плодотворные литературные труды, за вклад развитии детского творчества в протяжении долгих лет, за воспитание любви татарскому языку, литературы, истории молодого поколения и за успехи в области переводческой деятельности. (2011)

• Литературная премия Союза писателей России имени А. Грибоедова и памятная медаль А.С. Грибоедова за высокую гражданскую позицию в общественной литературно-издательской деятельности. (2012)

• Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы Ситдый-

кова Әлфия Мирзанур кызы нәтиҗәле намуслы хезмәте, актив иҗади эшчәнчелеге һәм 55 яшьлек юбилее уңаеннан Яр Чаллы шәһәре МЭРы Почет Грамотасы белән бүләкләнә. (2012)

• Оргкомитет Международного проекта Национальная литературная премия ЗОЛОТОЕ ПЕРО РУСИ, Содружество литературных сообществ, МГО Союза писателей России Благодарит Алфию Ситдикову за высокий художественный уровень переводов с русского языка. (2012)

• Специальный приз «Золотая бабочка» радио «Күңел» за значительный вклад в развитии татарской культуры и искусства. (2012)

• За верное служение художественному слову, за подвижническую деятельность на ниве отечественной литературе награждена дипломом литературно-общественной премии «Светить всегда» с вручением ордена «В.В. Маяковский». (2012)

• Оргкомитет Международного проекта Национальная литературная премия ЗОЛОТОЕ ПЕРО РУСИ, Содружество литературных сообществ, МГО Союза писателей России благодарит: Альфию Ситдикову за помощь в реализации Международного проекта ЭНЦИКЛОПЕДИЯ ЗОЛОТОГО ПЕРА. Оргкомитет сообщает, что переводы рекомендованы для широкого круга читателей всего мира. (2013)

• Диплом Международного литературного конкурса «Лучшая книга года 2013» Специальным призом «Переводческий Олимп». (Берлин, 2013) за переводы книжной серии «Современные авторы детям» российского издательства «Идел-Пресс».

• Благодарственное письмо Главы Мензелинского муниципального района. (2014)

• Благодарственное Письмо заведующего детского сада № 10 города Арска З.Д. Хакимовой за личный вклад в национальном воспитании детей, за духовное обогащение, за самоотверженный и добросовестный труд. (2014)

• Золотое Перо Руси национальная литературная премия Серебряное Перо Руси номинация ЛИТЕРАТУРНЫЕ ПЕРЕВОДЫ ЛАУРЕАТ награждается Ситдикова Альфия Мирзануровна за популяризацию и поддержку русской литературы посредством художественного перевода. (2014);

• Диплом Исполнительного комитета г. Набережные Челны за победу в городском конкурсе «Женщина года. Мужчина года: женс-

кий взгляд» в номинации «Женщина – культура и духовность». (2015)

• Министерство Культуры Республики Татарстан награждает автора книги «Радуга Сабантуя» Альфию Ситдикову дипломом III степени за III место в конкурсе «Книга года – 2013». (2015)

• Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Мактау Грамотасы белән Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге әгъзасы Ситдыйкова Әлфия Мирзанур кызы татар әдәбияты үсешенә зур өлеш керткәне өчен бүләкләнә. (2015)

• Благодарность награждается Ситдикова Альфия писатель, поэт-переводчик, член Союза Писателей Республики Татарстан за большой вклад в формирование экологической культуры детей и подростков, сохранение культурного наследия родного края, за поддержку природоохранных начинаний детского движения «Зелёная планета» в Татарстане, помощь в организации и проведении регинального этапа XIII Всероссийского детского экологического форума «Зелёная планета 2015», приуроченного Году литературы в Российской Федерации. (2015)

• Муниципальное образование город Набережные Челны ДИПЛОМ награждается Ситдикова (Хазиахметова) Альфия Мирзануровна участник городского конкурса в области литературы и искусства в номинации «Литература». (2016)

• Хаҗиәхмәтова Әлфия Мирзанур кызы «Татнефть» ААҖнең «Рухият» Фонды Советы һәм Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсенең карары нигезендә (беркетмә 5.10.2016 ел) әдәбияттагы казанышлары өчен Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия белән бүләкләнә, ЛАУРЕАТ билгесе тапшырыла. (2016)

• Мэр города Набережные Челны. Диплом награждается Ситдикова Альфия Мирзануровна победитель городского конкурса в области литературы и искусства в номинации «Литература». (2017)

# I

# ЭФИРДА – «КҮҢЕЛ» РАДИОСЫ

*«Әдәби учак» сәхифәсендә очрашулар*



**«Күңел» кызлары белән. 2012 ел**

# Сәмум җилен җиңгән әдип гомере...

*(2006 ел, 27 июль. Яр Чаллы. «Күңел» радиосы)*

***(язучы Газиз Кашапов-Үзиле иҗатына багышлана)***

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Урамнарны бәс каплаган инде,*
*Кыш кышлыгын итә барыбер.*
*Кешеләрдә ике гомер түгел,*
*Тик бер генә гомер, бары бер.*

Әлеге юллар танылган прозаик Газиз Кашапов-Үзиленең йөрәгеннән тамган сүзләр.

Газиз Кашапов 1942 елның 21 августында Аксубай районы Яңа Үзи авылында дөньяга килә. Ул хәрби училище тәмамлап гомерен хәрби хезмәт белән бәйли. Офицер тормышы аңа күп нәрсә бирә. Ул аның бәхете дә, фаҗигасе дә. Хезмәт вазыйфасын үтәгәндә авариягә эләгеп, хәрби хезмәткә яраксыз дип табылса да, көчле рухлы егет сынмый, сыгылмый. Казан Дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген читтән торып тәмамлый. Әлмәт шәһәренә күчеп килеп, үзенең әдәби эшчәнлеген башлап җибәрә. «Сәмум җиле» повестын ул Әлмәттә яза. Аның ул әсәре 1976 елда «Казан утлары» журналында басылып чыга, һәм аны укучылар бик җылы кабул итәләр.

Газиз Кашапов Яр Чаллы шәһәре белән тормышын 1978 елда бәйли. КамАЗ радиотапшырулар редакциясе хәбәрчесе булып эшли. 1983 елда СССР Язучылар Союзына кабул ителә. 1988-1989

елларда Чаллы Язучылар оешмасын җитәкли. 1991 елның 30 августында язучының йөрәге тибүдән туктый.

Кыска гына иҗат гомерендә ул үзен киң колачлы хәрби темага язучы итеп танытты. Хөрмәтле укучыларыбыз! Сез «Солдат иртә ир була», «Убырут», «Лачын кошка күкләр кадерле», «Җир җылысы», «Кыямәт бүлмәсе», «Елан агуы» повестьлары, «Язмышыңа ышан», Хәсән Туфанга багышланган «Киек каз юлы» романнарының авторы, язучы Газиз Кашаповның тормышы, иҗаты хакында аның хатыны Фәһимә ханым Кашапова белән булган әңгәмә аша танышырсыз.

– Фәһимә апа! Сез Газиз абыйга тугрылыклы гомер юлдашы һәм чын иптәш булгансыз. Аның белән бергә тормышның бәхетле мизгелләрен дә, авырлыкларын да тигез күтәргәнсез. Ул хәрби кеше буларак, сезгә күчмә тормыш белән яшәргә дә туры килә. Халык мәкалендә ике күченүне бер януга тиңлиләр. Сезгә хәрби офицер хатыны һәм шул ук вакытта язучы хатыны да булырга туры килгән. Офицер хатыны булу авыррак идеме, әллә язучы хатыны булумы?

**Фәһимә апа:** Аны ничек аерасың, аерып булмый аны. Хәрби кешенең бер авырлыгы, ә иҗат кешесенә тынычлык та, аерым бүлмә дә кирәк. Ул чакта өч бала. Балаларны карарга кирәк.

Иҗат кешесе белән яшәргә авыр. Алар бит хыялланып йөриләр дә, шул хыялларны үтәргә кирәк. Иҗат кешесе белән яшәү ничек икәнен язучы хатыннары үзләре генә белә инде.

Армиядән комиссовать иттеләр дә, Чиләбегә күчтек. Анда күчкәч бик авырды, бер ел урында ятты. Аның бит авариядә миләре кысылган иде. Шунда профессор әйтте: әгәр бер сүз дә каршы әйтмәсәгез, бөтен тормышны аныңча көйләсәгез, ул бәлки яшәр, ләкин барыбыр шул чир аны алып китәчәк, дип. Шул чирдән исән калып, үзенең тырышлыгы белән шул дәрәҗәләргә иреште инде, Аллага шөкер. Университетта укырлык булды. Дөрес, безнең яктан да бик күп ярдәм булды инде. Минем әни дә кешеләргә ярдәм итә торган иде. Ул инде коръән укып, үләннәр белән дә дәвалады.

**Әлфия Ситдыйкова:** Иҗат белән үзеңнең гомереңне бәйләр өчен сәләт белән бергә тырышлык та, рухи ныклык та кирәк. Һәм әлбәттә, кемнеңдер дөрес юнәлеш бирүе дә мөһим. Газиз абыйга иҗатка кереп киткәндә кемнәр булышты?

**Фәһимә апа:** Без бергә укыдык, бер авыл кешеләре. Яшь вакыттан ук шигырьләр язды. Сәләте бар иде. Чиләбедә торган вакытта татар-башкорт китапханәсенә йөри башлады. Аннары укырга

керде. Укырга кергәндә Мөхәммәт Мәһдиев ярдәм итте. Әлмәткә күчкәч яза башлады.

**Әлфия Ситдыйкова:** Минем белүемчә, Әлмәттә яшәгән чорда аңа шагыйрә Саҗидә Сөләйманова зур ярдәм күрсәткән. Иҗади дуслык бигрәк тә «Сәмум җиле» китабын язганда көчәйгәндер.

**Фәһимә апа:** Кечкенә генә «Сәмум җиле» китабын Саҗидә апа җиде тапкыр яздырды. Язу эшенә бик авырлык белән кереп китте ул.

**Әлфия Ситдыйкова:** Туры сүзле, үткен каләмле язучы яшәгән чорда Әфганстанда сугыш бара иде. Ул хәрби кеше һәм язучы буларак бу вакыйгаларга битараф булмагандыр. Туры сүзле булганы өчен аңа «кыен ипиен» күп ашарга туры килгәндер, әйеме?

**Фәһимә апа:** Әфганстан аның җанына, авырткан җиренә бик тия иде. Ике-өч авылдашның баласы үлеп кайтты. Аннары үзе белән бергә укыган Юнысның малае табутта кайтты. Саташырга җитте инде ул чакта. Гел авыл балалары кайта иде бит табутта. Шуннан Газиз язып чыкты, җыелышларда да бик каты сүзләр әйтте. Аңа тукта, әгәр дә шулай дәвам итсәң, үзеңнең дә дүрт балаң, күрсәтәбез без сиңа дип янаулар да, телефоннан шалтыратулар да булды. Үтте инде баштан.

**Әлфия Ситдыйкова:** Газиз абый кайсы әдипләр белән тыгыз элемтәдә яшәде?

**Фәһимә апа:** Бик күп язучылар белән аралашты. Аяз абый Гыйләҗев, Мөхәммәт абый Мәһдиев, Туфан Миңнуллин. Алар белән киңәшләшеп яшәде инде.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Син бит минем ышанычым идең,*
*Таянычым идең арганда.*
*Ничә тапкыр йолып алдың мине,*
*Өметсезлек килеп сарганда.*
*Рәхмәт синең назлы кулларыңа,*
*Рәхмәт синең нурлы йөзеңә.*
*Рәхмәт синең олы йөрәгеңә,*
*Рәхмәт синең җылы сүзеңә.*

Сезнең хактагы әлеге шигъри юлларда аның сезгә булган мәхәббәте дә, дүрт баласының әнисе булган өчен ихтирамы да, барысын да аңлап, кабул итеп яшәвегезгә рәхмәте дә чагыла. Бу

шигырь Газиз Кашапов үзе мәңгелеккә күчкәннән соң нәшер ителгән «Мәхәббәт сүрәләре» дигән китабына кергән. Әлеге китап кем булышлыгы белән дөнья күрде?!

**Фәһимә апа:** Бу китапны Тәлгат белән ике арада күп йөрттек инде. Мин җибәрәм Сабага, ул илтә Казанга. Тәлгат Нәҗмиев Саба районы газетасы редакторы. Алар бергә университетта укыганнар иде. Гаиләләр белән дә дуслашып киттек. Ул безне ташламады. Тәлгат, йөри-йөри, Туфан абый аша бу китапны чыгара алды.

**Әлфия Ситдыйкова:** Фәһимә апа! Ә язучының калган мирасы кем кулында, нинди хәлдә саклана?!

**Фәһимә апа:** Кулъязмалар инде музеенда. Ул эшли башлаган эшне тәмамламый, башка нәрсәгә тотынмый иде. Шуңа күрә мирасы калды дип әйтә алмыйм. Башында иде, үзе белән китте.

**Әлфия Ситдыйкова:** Язучының туган авылында аның иҗатын барлап, чаралар үткәреләме? Үсеп килүче буын вәкилләре дә аны онытмыйдыр дип уйлыйм.

**Фәһимә апа:** Музей ачтык авылда. Укучы балалар һәр елны районнардан, авыллардан киләләр музейга. Язучылар да искә ала, киләләр инде.

**Әлфия Ситдыйкова:** Әйе, әдип үзе мәңгелеккә атласа да, аның гомеренең дәвамы балаларында, оныкларында, язган әсәрләрендә яши бирә. Сәмум җилләренә бирешми яшәгән, онытылмас әсәрләр иҗат итеп калдырган язучы Газиз Кашапов исән булса, үзенең 65 яшен билгеләп үткән булыр иде. Шагыйрь күңеле сизгерлеге белән аерылып тора. Үзенә бирелгән гомернең аз булуын белеп яшәсә дә, Газиз Кашапов киләчәккә өмет белән карый. Узган көннәрен кылган гамәлләре белән чагыштырып карап, үзеннән соң дәвам булып килгән яңа буын өчен таң атуына ышана ул.

*Гомер безгә бик аз билгеләнгән,*
*Бу, бәлки, бер олы ялгыштыр.*
*Тик син аны узган көннәр түгел,*
*Кылган эшләр белән чагыштыр.*
*Ярылса да йөрәк тамырлары,*
*Чатнаса да сабыр канаты.*
*Безнең дәвам булып җиргә килгән*
*Яңа буын өчен таң атар. –*

дип яза ул 1989 елның 29 маенда. Үзеннән соң килгән буыннар өчен таңнар атачагына ышанып яшәгән, иҗат иткән әдипнең исеме

онытылырга тиеш түгел. Якты дөньяга килеп, үткәннәрне барлап, киләчәкне кайгыртып яшәгәндә, мәңгелеккә исемен ялгаган әдипнең – Газиз Кашаповның безгә васыять итеп язып калдырган:

*Кешеләрдә ике гомер түгел,*
*Тик бер генә гомер, бары бер. –*

дигән сүзләрен истән чыгармасак иде.

*«Әдәби учак» тапшыруы мөхәррире Әлфия Ситдыйкова.*
*Аудиоязмадан алынды.*

# Сибелсә дә татар чит җиргә...

*2006 ел, 29 июль. Яр Чаллы. «Күңел» радиосы*

## *(Удмуртиядә яшәүче милләттәшләребез тормышыннан)*

**Әлфия Ситдыйкова:** Татар милләте бөтен дөнья буйлап сибелеп яши торган милләт дисәк тә дөреслеккә туры килер. Сибелеп яшәсә дә, татар үз телен, үз динен, үз гореф-гадәтен, үз әдәбиятын саклый һәм үстерә белә. Дөньяның кайсы гына төбәгендә яшәсә дә, ул аралашу чарасы итеп үз телен сайлый, мәдәниятен, сәнгатен барлый, киләчәк буыннар кулына тапшыра. Буыннар чылбыры җырларда, күңелдән тамган сүзләрдә ялгана.

Удмуртиянең Ижау каласындагы милләттәшләребез Республикадан читтә яшәсәләр дә, һәрвакыт аралашып, көрешеп яшәргә җаен да, вакытын да табалар.

Без сезне Удмуртиядә яшәүче милләттәшләребез тормышы һәм әдәбият-сәнгать торышы белән таныштырырбыз.

Беренче кунагыбыз – Удмуртия татар иҗтимагый үзәге рәисе Фнүн Габбас улы Мирзаянов.

– Фнүн Габбасович! Удмуртиядә татарлар күпме һәм аларга милләтне милләт итеп саклап калу өчен шартлар тудырылганмы?

**Фнүн Мирзаянов:** Соңгы халык саны алу буенча Удмуртиядә Ижау шәһәрендә һәм башка шәһәрләрдә яшәгән татарларның саны йөз дә тугыз мең исәпләнә. Һәм инде шушы халыкның җитмеш меңе үзенең туган теле итеп татар телен исәпли. Башкалары телен я «аз беләбез», я «белмибез» дип язалар. Кызганычка каршы, 1989 елларда, халык санын исәпкә алуга караганда, туган телен белүчеләрнең саны кими. Бу аяныч күренешне туктату һәм телебезне саклап калу өчен күп кенә чаралар башкарабыз. Һәм, әйтергә кирәк, Удмуртия татар иҗтимагый үзәге шушы елның беренче апрелендә үзенең унбиш еллык зур бәйрәмен билгеләп үтте. Ул бәйрәмгә Татарстан бөтендөнья конгрессында катнашкан вәкилләр дә, үзебезнең җөмһүриятебез җитәкчеләре дә кунак булып килгәннәр иде. Татар милләтенең Удмуртия җирлегендә икътисадый, мәдәни һәм сәяси тормышта тоткан урыны турында алар бик яхшы итеп бәяләрен бирделәр һәм теләкләрен белдерделәр.

Бүгенге көндә бездә татар теле тел буларак өйрәнелә торган утыз бер мәктәп, балалар бакчаларында татар теле төркемнәре бар. Һәм инде педагогик көллияттә, шушы елга кадәр Удмуртия дәүләт университетында татар теле өйрәнү буенча, балалар бакчалары һәм мәктәпләр өчен белгечләр өйрәтүне әзерләп килдек. Һәм инде массакүләм чаралар, мәдәни чаралар буенча бездә татар тапшырулары, радио-телевидение шушы унбиш ел дәверендә эшләп килде. Һәм татар газетасы чыгып килә. Ул Удмуртия татар иҗтимагый үзәге оештырган газета иде. Хәзерге вакытта ул дәүләтнеке һәм дотация тарафыннан алып барыла. Сан буенча егермедән артык татар телендә урындагы шагыйрьләрнең, язучыларның чыккан китапларын әйтеп китәргә мөмкин. Үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр дә телебезгә бәйләнгән. Һәм инде аларның үтеше турында бөтендөнья татар конгрессыннан, һәм Татарстан мәгариф министрлыгыннан килеп үткәргән чараларда, алар турында яхшы сүзләр әйтеп кителде.

**Әлфия Ситдыйкова:** Әдәби мираска сез ничек карыйсыз?

**Фнүн Мирзаянов:** Әлбәттә, Габделҗәббар Кандалыйдан, Кол Галидән башлап, бөтен халкыбызның милли эпослары, бөтен фольклор тарихы, ул безнең шушы шигъри юллар арасында исән калган дип саныйбыз. Һәм инде шигъриятнең үрнәге булган, Аллаһ тарафыннан бирелгән, Коръән Кәрим тарафыннан бирелгән

телебезне, әдәбиятны, шигъриятне бүгенге көндә дә үзебезнең милләтебезне саклап алып баручы бер зур гүзәл күренеш дип исәплибез. Чөнки, мең дә бер йөз елдан артык элек, үзенең миссиясе белән Болгар дәүләтенә килгән Ибн Фадлан язмаларында: «Бу Болгарстанда яшәгән халык гаҗәп халык, бер-берсе белән алар шигырь телендә сөйләшәләр. Һәм инде бөтен һөнәргә дә осталар, һәм бик кунакчыллар, тормышлары буенча бай тормышта торучаннар», – дип әйткән. Шушы әйткән тарихи искәрмәне искә алып, без бүгенге көндә халкыбыз өчен шушы нигезләрнең төзеклеген кайтаруны күз алдында тотабыз.

**Әлфия Ситдыйкова:** Диннең кире кайтуы да милләтебезне саклап калуда төп роль уйный дисәк, дөреслеккә туры киләдер. Телебезне саклап калуда дингә таянып эш итү сездә ничек куелган?

**Фнүн Мирзаянов:** Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм безнең республикабызның Президенты Волков 2003 елда очрашу вакытында сөйләшенгән сүз буенча, шәһәр уртасында зур «Җәмигъ» мәчете төзеп ятабыз. Бүгенге көндә аның ике каты барлыкка килерелде инде. Безнең шушы мәчетебез, бу инде бары тик намазлык урыны гына булмас, ә бәлки рухи, әхлакый һәм мәдәни халкыбызның алга барышы учагы булыр дип уйлыйбыз. Ул һәр көнне, һәр сәгатьтә, һәркемне, халыкларны көтеп ала торган һәм инде шушы теләкләрне үстерүдә ярдәм итүче учак булыр дибез. Шуңа күрә аның шушы урында булган базарлар һәм башка урыннары да булган җирдә төзелүе, милләттәшләребезнең анда керергә уңайлы булуы да бүгенге көндә безгә бик шатлыклы хәбәр.

**Әлфия Ситдыйкова:** Китапларны бастыру һәм тарату сездә ничек оештырылган?

**Фнүн Мирзаянов:** Китаплар тарату мәсьәләсендә болай: беренчедән, Татарстан меңъеллык алдыннан күрсәткән матур гадәт буенча, ул бөтендөнья татар конгрессы аркылы һәм шундый башка министрлыклар аркылы килә торган система бар. Икенчедән, урында чыгарылган китапларны таратуның төрле юлларын эзлибез. Ул китапларны чыгаруда ярдәм итү, хакимият органнары тарафыннан һәм эшкуарларыбыз, депутатларыбыз тарафыннан да матди нигез кую бездә җайга салынган. Бүгенге көндә ул китапларга ихтыяҗ булсын өчен, дефитцитка әйләндереп сатып алу өчен шартлар тудыру. Бу, әлбәттә, безнең эшләп килә башлаган әдәби бүлекчәбез, Татарстан Язучылар берлегенең бер фиркасе булып урнашуы, һәм инде һәрбер урында безнең кардәшләребезне, туганнарыбызны та-

бу моңа ярдәм итәр дип исәплибез. Чөнки кешегә китапны көчләп бирү түгел, аның ихтыяҗына әйләндерү – бүгенге көндә безнең бурычыбыз. Шуңа күрә, Удмуртиянең төрле районнарында, шәһәрләрендә безнең татар иҗтимагый үзәгенең бүлекләре эшләп килә. Без, унбиш ел буена, Бөтендөнья татар конгрессында даими коллектив әгъзасы. Шуңа күрә, бу эшебезне шушы тарафтан тарату юнәлешендә алып барабыз. Һәм инде, булдыралганча, акчаларны табып, чыккан китапларны сатып алып, сабантуйларда өләшәбез. Татар сыйныфларын ачкан чагында ата-аналарга һәм инде татар сыйныфларының чыгарылыш кичәсе вакытында, һәрбер татар телен өйрәнеп чыккан унынчы-унберенче класс балаларына бүләк итеп бирү, ул һәрвакыт безнең өстебездә булды. Һәм без моны эшләп киләбез.

Китапханәләрдә татар бүлекләрен булдыру өстендә дә эшлибез. Бүгенге көндә үзәк китапханәдә, Муса Җәлил китапханәсендә, башка китапханәләрдә татар китаплары бүлекләре бар. Һәм инде аларда без шагыйрьләребез белән очрашулар оештырабыз. Бүгенге көндә яңа «Ижмаш» мәдәният сараенда татар иҗтимагый үзәге белән татар китаплары бүлеген оештырып ятабыз.

**Әлфия Ситдыйкова:** Хәзер сүзебезне Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, күп китаплар авторы, шагыйрь Ринат Батталов белән дәвам итәбез.

Ринат әфәнде! Сездә, белүемчә, иҗади берләшмә эшли, һәм аны сез җитәклисез. Шул берләшмәнең эшчәнлеге белән таныштырып үтмәссезме?

**Ринат Батталов:** Безнең әдәби иҗат берләшмәсе 1991 елдан бирле эшләп килә. Без аның унбиш еллыгын үткәрдек. Иҗат берләшмәсе Риза Шәфи исемен йөртә. Ул 35 шагыйрьне, язучыны берләштерә. Шуларның дүртесе Татарстан Язучылар берлеге, икесе Удмуртия Язучылар берлеге әгъзасы. Без Әгерҗе белән тыгыз элемтәдә яшибез. Әле яңадан алты кешене үзебезнең утырышта тикшереп, Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим иттек. Аның икесе Әгерҗе районыннан: Исәнбай авылыннан Әлфирә Низамова, Шаршады авылыннан Асия Корбангалиева. Можгадан Илгиз абый Кадыйров, Гимран Сафин, Воткинскийдан Гүзәл һәм Гөлфия Исхаковалар. Соңгы ун ел эчендә генә дә утыздан артык китап бастырып чыгардык. Аларның унбише Казанда, өчесе Чаллыда, калганнары үзебезнең Ижау типографиясендә нәшер ителде. Күп кенә язучыларыбыз «Яңарыш» битләрендә үзләренең көчләрен

сыныйлар, каләмнәрен чарлыйлар. Без «Яңарыш»та махсус «Яшьләр бите», «Алтын йомгак» сәхифәсе алып барабыз. Анда мәктәп балаларын шигырь язарга өйрәтәбез, дәресләр алып барабыз. Удмуртиядә Татарстан Язучылар берлеге бүлекчәсен ачу турында да килешмәгә кул куелды.

**Әлфия Ситдыйкова:** Хөкүмәт тарафыннан нинди дә булса ярдәм күрсәтеләме?

**Ринат Батталов:** Мин әйтер идем, күбрәк үз хисабына чыгаралар дип. Соңгы вакытта Удмуртия дәүләт бюджетыннан акча бирелә башлады. Менә шушы көннәрдә безгә җитмеш мең акча бирелде яшьләр китабын, шигърият китабын чыгару өчен. Анда без иң яшь язучыларның, шагыйрьләрнең иҗатларын тупладык. Шушы арада ул китап дөнья күрәчәк.

**Әлфия Ситдыйкова:** Тагын бер кунагыбыз «Яңарыш» газетасының редактор урынбасары Закуан Фәттах улы Нуретдинов.

Закуан Фәттахович! Сезнең газета башлап язучылар өчен тәүге иҗат мәйданы да булып торадыр. Яңа әсәрләрне халыкка җиткерү чарасы булып торган газета күпме тираж белән чыга һәм кайсы төбәкләрдә таратыла?

**Закуан Нуретдинов:** Бүгенге көндә газета уналты бит белән атна саен чыга. Газетабызны мең ярымга якын Әгерҗелеләр яздырып ала. Шушы потенция белән безнең әдәби көчләребез дә арта барды, тематикасы да үзгәрде.

**Әлфия Ситдыйкова:** Ижау шәһәрендә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы белән танышып, чит төбәктә яшәүче милләттәшләребезнең телебезне, динебезне, әдәбият көчләрен саклау һәм үстерү өчен куйган хезмәтләрен бәяләгәннән соң, күңелегездә алар өчен горурлык хисләре тугандыр. Әйе, үз милләте өчен янып яшәүчеләр булганда татар милләте яши, яшәр һәм яшәячәк.

*«Әдәби учак» тапшыруы мөхәррире Әлфия Ситдыйкова.*
*Аудиоязмадан алынды.*

# Яралы халык
# җанын сүз белән бәйли...

*2007 ел, 28 август. Яр Чаллы. «Күңел» радиосы*

***(шагыйрь Харрас Әюпов иҗатына багышлана)***

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Безгә хәтер юкка бирелмәгән,*
*Яшәмәде халык хәтерсез.*
*Томаларга теләсә дә еллар,*
*Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.*

Әлеге шигъри юлларның авторы татарны татар итә торган, аның телен, моңын, йолаларын, гореф-гадәтләрен бозмыйча диярлек саклап торган, гүзәл табигатьле районнарның берсе, Мөслим төбәгендә туып үскән, күренекле шагыйребез Харрас Әюпның каләменнән тамган сүзләр. Харрас Әюпов 1946 елның 21 августында Түреш авылында дөньяга килә. Түрештә башлангыч белем алып, 1964 елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Беренче шигырьләре урта мәктәптә укыган чорда басыла башлый. «Ышаныч» дип аталган беренче китабы 1980 елда басылып чыга. Дистәләгән китаплар авторы Харрас Әюп шигърият сөючеләргә сүз тәмен белгән, халык рухын яхшы тойган җитди каләм иясе булып танылa. Шагыйрьнең күңеленнән халык хәтеренә кушылып аккан шигъри тәлгәшләре бетмәс Моң белән сугарылган. Шагыйрь иҗатында моң образы гаҗәеп күпкырлы. Анда чулпы чыңы да, тургай тавышы да, каеннар шавы, сагыну сагышы һәм гомер агышы да.

– Харрас абый!

*...Бүгенгесен, үткәндәген җуйса,*
*Киләчәктән мәхрүм ул халык... –*

дип язгансыз «Хәтер» дигән шигырегездә. Әлеге юллар хәзерге заман үзгәрешләреннән әрнеп туган юллардыр дип уйлыйм. Әхлак-

сызлык, битарафлык тамыр җәйгән чорда, чынлап та, киләчәгебездән мәхрүм калмабызмы дигән уйлар башка еш килә.

**Харрас Әюпов:** Хәзер милләт тә, акыл да, ничектер, бер буталганрак дәвергә килеп керде. Ләкин, минемчә, кешелек тормышында мондый вакытлар бер генә булмаган. Элек тә булган ул, буталып калулар. Ләкин яңадан кеше җаны, кеше акылы барыбер бер иманына кайта, үзенә кайта. Һәм мин, бүгенге көннән канәгать булмасам да, күңелем белән инанам, безнең кеше барыбер Кеше булып калачак.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Терсәк якын тешләп булмый,*
*Җитми икән буй терсәккә.*
*Үз балаңның авызыннан*
*Явыз Иван тел күрсәтә... –*

дип язуыгыздан күренгәнчә, сезнең дә милләтебезнең киләчәге өчен борчылуыгыз аңлашыла. Сезнең үзегезнең балаларыгыз татарча сөйләшәме?!

**Харрас Әюпов:** Әйе, тел мәсьәләсе барыбызны да борчый. Беребез дә аңа карата битараф түгел. Без үзебез авылда тәрбияләнеп үскән балалар. Телне шактый яхшы беләбез. Белемебез буенча да тел белгечләре. Ә инде безнең балалар шәһәрдә туып үстеләр. Аларның үсүләре, мәктәптә укулары шундый чорга туры килде, безгә мәктәптә ата-аналар җыелышына баргач: «Өйдә татарча сөйләшмәгез, балаларыгыз русча белми, русча өйрәтегез», – ди торганнар иде. Шуңа карамастан, балаларыбыз белән татарча сөйләштек. Һәм Аллага шөкер, бүгенге көндә минем улым да, кызым да иркенләп татарча сөйләшәләр.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Без түш белән шуып чыгып киттек*
*Бу тормышка капка аслатып...*

Мөслим төбәгендә туып үскән, түш белән капка астыннан шуышып чыгып киткән хыялый малайның барлык хыяллары да чынга аштымы?!

**Харрас Әюпов:** Әгәр барлык хыяллар да тормышка ашты дип әйтсәм, бу хата булыр иде. Кеше күңеле бик киң бит ул. Аның

хыяллары бик күп. Барсын да тормышка ашырып бетереп булмый. Иҗат мәсьәләсенә, моң мәсьәләсенә килгән чагында, мин күпмедер нәселдән, әнкәйдән килә торган моңны саклап кала алдым дип уйлыйм. Һәм шушы моңны беркадәр дәрәҗәдә кешеләргә дә җиткерә барам дип уйлыйм. Һәм шушысы сөендерә.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Кулларыма кабат гармун алдым*
*Көтмәгәндә, уйламаганда... –*

дип башланып китә «Көй эзләү» дигән поэмагыз. Гармунчы... Шагыйрь... Көйгә шигъри юллар кушылып агып тулы бер гармониягә әйләнмәсә, сезнең шигырьләрегезне укып илһамланып кулына каләм алган яшь шагыйрә Сирень Якупова:

*Бәйләр сүзләр җитмәгәндә*
*Өзелгән бәгырьләрне,*
*Кулларына гармун ала*
*Татарның шагыйрьләре.*
.........................................
*Аннан кинәт тынып кала*
*Читкә куела гармун.*
*Табылды!*
*Табылды, димәк, бәйләр сүз*
*Яралы халык җанын,*
*Яралы татар җанын –*

дип язмас иде. Чынлап та, Сез үз көегезне тапкан шагыйрь дип беләм.

**Харрас Әюпов:** Мин яшьтән үк көйгә-моңга тартылып үскән кеше. Күкрәктән, йөрәктән бер вакытта да моңның киткәне юк. Бу – халык моңы, халык бәгыре, халык уе. Ләкин минем үземнеке, үз моңым да халыкныкыннан аерылгысыз. Ул күпмедер дәрәҗәдә минем иҗатымда. Шулай булгач, мин күпмедер дәрәҗәдә үз юлымны таптым дип уйлыйм.

**Әлфия Ситдыйкова:** Сез китап нәшриятында күп еллар хезмәт куясыз. Сезгә, редактор буларак, яшь талантларның да китаплары, аларның әсәрләре белән танышып барырга туры киләдер. Өметле каләм ияләре күп киләме әдәбиятка?

**Харрас Әюпов:** Безнең татар әдәбияты бай әдәбият. Аның борынгыдан килгән хәзинәләре бар. Бүгенге көндә иҗат итә торган саллы-саллы каләм ияләребез бар. Һәм, әйтергә кирәк, яшьләр дә килә тора. Ләкин, нәшриятта эшләүче кеше буларак, мин соңгы елларда беркадәр игътибар итәм: хәзерге яшьләребез халыктан килә торган эчке бер көчне, эчке бер куәтне беркадәр тоемлау дәрәҗәсен югалттылар шикелле. Менә шушы әйбер мине борчый. Ничектер, заман шаукымына бирелеп, җиңелрәк әйберләр язып ташлау, ашыгып бастырырга тырышу, миңа калса, бер дә дөрес түгел. Яшьләр бераз уйлансыннар иде бу мәсьәләдә. Ә болай, өметле генә яшь каләмдәшләребез бар. Мин әлегә аларның исемнәрен атаудан тыелып торам. Чөнки кайвакытта без яшьләрне иртәрәк мактап бозып та ташлыйбыз. Эшләсеннәр, заман, вакыт күрсәтер.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Төшләремдә очканымны күрәм –*
*Карасана: мин бит канатлы!*
*Кеше заты шул канатлар өчен*
*Күпме гомер инде җан атты.*
*Мин уяндым:*
*Канатлар юк иңдә...*
*Тик түбәнгә инде төшмимен, –*
*Оча беләм,*
*Җирдә яшәсәм дә,*
*Күкрәгемдә барыбер кош минем!..*

Гасырлардан килгән Моңны күкрәгендә кош итеп йөртүче шагыйрь – Харрас Әюп бүгенге шигърияте белән яралы халык җанын бәйләп яшәвен дәвам итә. Күкрәгендә оялаган кош тавышы шигырь булып дөньяга тарала.

*«Әдәби учак» тапшыруы мөхәррире Әлфия Ситдыйкова.*
*Аудиоязмадан алынды.*

# Халкыбызның үз шагыйре

*2007 ел, 5 июль. Яр Чаллы. «Күңел» радиосы*

***(шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатына багышлана)***

**Әлфия Ситдыйкова:** Татар шигъриятенең тарихы Кол Галиләр, Мөхәмәдъяр, Мәүла Колый, Тукай, Такташ һәм Туфаннардан башланып киткән. Ерак дәверләрнең кайтавазы булган шигъри мирасны барлап, саклап киләчәккә илтү, һәр чор әдипләренең изге бурычы.

*Башың имә, җилләр*
*иссәләр дә каян!*
*Киләчәккә карап,*
*үткәнеңә таян!*

Җилләр кайсы яктан гына исмәсен, киләчәккә якты өмет белән карап, үткәннәргә таянып «үз иҗат омтылышларының дөреслегенә фанатларча ышанып» яшәүче, олы иҗат биеклегенә ирешкән олпат шагыйребез Равил Фәйзуллин 1943 елның 4 августында Балык Бистәсе районының Балтач авылында дөньяга килгән.

Егерме өч яшендә СССР Язучылар оешмасына кабул ителгән, Республиканың Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, Татарстанның Халык шагыйре, республикабызда нәшер ителүче иң мәртәбәле журналларыбызның берсе – «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин бүген бездә кунакта.

– Равил абый! Меңъеллык әдәбиятлы татар милләтенең вөҗдан көзгесе булган «Казан утлары» журналының узган ел 1000 нче саны дөнья күрде. Бу, әлбәттә, татар җанлы, милли аңлы һәрбер кеше өчен онтылмаслык мөһим вакыйга. Хөрмәтле Президентыбыз Минтимер Шәймиев белән булган әңгәмәгездә дә бу ачык чагылыш тапты. «Әдәби учак» җылысына җыелган дусларыбызга да «Казан утлары» журналының бүгенге катлаулы чор таләпләренә җавап бирерлек итеп эшли алуының серен бәянләп үтмәссезме?

**Равил Фәйзуллин:** Рәхмәт, сүзне комплименттан башладыгыз. Безнең журналга шулай зур бәһа бирүегез өчен рәхмәт. Әгәр дә телебезне, халкыбызның рухи хәзинәсен киләчәк буыннарга

җиткерергә телибез икән, без тырышып, максатчан эшләргә тиешбез. Без дигән сүзгә мин бөтен авторларыбызны, укучыларыбызны кертеп әйтәм. Әгәр дә язучыларыбыз, укучыларыбыз булмаса, никадәрле генә тырышсак та нәтиҗәләр бүтәнчә булыр иде.

Шушы меңенче санны чыгару горурлык хисе уята, мин яшермим. Чөнки бүтән әдәби журналлар арасында меңенче санын чыгарган журнал юк. Татар журналын беренче булып без чыгарып күрсәттек. Ул бит мең китап дигән сүз, җыйнама китап. Халкыбызның рухи елъязмасы дип санарга була. Әгәр дә әдәби журналларның башын «Шура», «Аң» журналлары белән бәйләсәк, без шул журналларның рухи варислары дип исәплибез инде.

Бу арада «Республика Татарстан» газетасында зур мәкалә чыкты. Профессор Булат Солтанбеков мәкаләсе. «Портрет времени» дип атала иде. Ул тикмәгә генә алай итеп язмаган. Чыннан да, елъязма.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Инешләрнең башы чишмә булыр.*
*Яхшылыкның асылы – тугрылык.*
*Яшәү – бәхет: илең синең өчен,*
*Син – ил өчен булсаң горурлык.*

Сез шушы шигырегездә язганча, ил казанышлары белән горурланып яшәүче шәхес. Сез моны үзегезнең кылган гамәлләрегез белән исбатлап яшисез. Шул ук вакытта ил таянырлык ир, хезмәтегез һәм иҗатыгыз белән «Халык шагыйре» исемен яулаган каләм иясе. Сезнең тормышка ашмый калган хыялларыгыз бармы?!

**Равил Фәйзуллин:** Ул бардыр инде. Адәм баласы бөтенесеннән дә канәгать булмый. Мин үзем шактый бәхетле язмышлы, Аллага шөкер дип уйлыйм. Чөнки байтак яшәдем һәм үзем теләгәнчә яшәдем бу дөньяда. Ул бик зур нәрсә: үзең теләгәнчә күңел теләгән эштә эшләп, үзеңчә яши алу. Бик яшьли иҗатка керелде. Илле елга якын әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнарга туры килде. Егерме дүрт яшьтә мин Әлмәт Язучылар оешмасы җитәкчесе булып эшли башлаган идем. Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары булып озак еллар эшләдем. Аннан соң егерме елга якын «Казан утлары»ның баш мөхәррире булып эшлим инде. Кыскасы: вөҗданым кушканча яздым. Иҗтимагый эшемдә дә үземнең инанган иманыма тугры калырга тырышам. Халык өчен эшлибез инде.

Минем ике улым бар. Бәлки күбрәк балалар кирәк булгандыр.

Биш-алты бала булган булса да, артык булмас иде дип уйлап куям кайчакта. Монысы инде Ходай эше.

**Әлфия Ситдыйкова:**

*Намус – җанның сакчысы.*
*Еллар – гомер баскычы.*
*Кылыч – күкрәк ачкычы.*
*Шигырь – йөрәк ачкычы.*

Фикер, хис, кичереш. Шуларның өчесен бергә берләштергәч кенә шигырьләр туа, минемчә. Сезнең тирән-фәлсәфи лирикагыз, төрле үлчәмдә, төрле жанрда, төрле темага язылган тирән мәгънәле шигырьләрегезне уку, кулына каләм алган яшь шагыйрьләр өчен шигъри остаханә дияр идем. Сезнең иҗат мәктәбегезне үтеп, сезнең хәер-фатихагызны алып, чын шагыйрь булып җитешкән шәкертләрегез күпме?

**Равил Фәйзуллин:** Аларны шәкерт дип әйтә алмыйм инде мин. Чөнки инде алар күпмедер тәҗрибә үткәннәр, остаханәләрне узган булалар. Беренче әсәрен генә күтәреп кергән кешеләр аз була. «Казан утлары»нда басылу һәм яшь, һәм өлкән язучыга булсын, дәрәҗә санала. Мин байтак еллар кабул итү комиссиясендә эшлим, коллегиянең рәисе булып. Анда «Казан утлары»нда басылдымы? – дип сорау бирәләр. Шушы «әдәби капканы» үтеп килгән кешене чын язучы дип саныйлар кайбер кешеләр. Бу инде мәҗбүри түгел. «Казан утлары»нда чыкмаса да, чын талант, язучы булырга мөмкин. Нигездә, журналда әсәрләре басылмаган авторлар юк дәрәҗәсендә дип әйтер идем.

Менә бер генә мисал: Тукай премиясенә лаек булганнарны алыйк. Бу премия 1958 елда бирелә башлаган иде. Хәзер илле елга якын. Мин исәпләп утырдым: иллегә якын язучыга бирелгән премия. Аларның инде күбесе вафатлар. Әдипләрнең: шагыйрьме ул, прозаик-язучымы, драматургмы, Тукай бүләген алган әсәрләре бездә басылган икән, бердәнбер күрсәткеч инде.

**Әлфия Ситдыйкова:** Сез безнең ак калабызда да һәрвакыт көтеп алынган кадерле кунак. Мәктәп укучылары, студентлар, әдәбият-сәнгатьне яратучылар сезнең ялкынланып шигырь уку мизгелләрен, сезнең иҗатны күңеленә сеңдереп кала дияр идем. Сезнең кебек олы шәхесләр белән очрашу әлбәттә иҗат дәрте уята. Сезнең карашка Чаллыдагы әдәби мохит Казандагы әдәби мохиттан аерыламы?

**Равил Фәйзуллин:** Чаллыда бик еш булмасам да, елына берике тапкыр барыла. Чаллыга бертөсле барасың, кайтканда – уйланып кайтасың. Чаллыда талантлы язучылар яши, сүз дә юк. Ләкин уртак максатка җигелеп тарту сизмим мин анда. Ниндидер аерылулар, төркем-төркемнәр... Ул бер дә файда китерми. Кешеләрнең энергиясе, егәре тиешле юнәлештә бармый. Һәм ул әсәрләрендә дә чагыла. Тормышны, әллә мәйданны бүлүме? Шул тынгы бирми. Бәлки Казанда да бардыр. Ләкин бит халык мәнфагәте, уртак максатлар бар. Без инде гомер-гомергә халыкта бердәмлек җитмәү хакында сөйләшәбез. Аның язмышы шулайдыр инде. Күрәсең дәүләтчелеге беткәч, күпмедер психологик каршылыкларга корылгандыр. Аны аңлатып та була. Ләкин язучы кешегә, әдип кешегә өстенрәк булырга кирәк дип уйлыйм мин. Чөнки хәзерге вакытта телебезне саклау иң мөһим мәсьәлә. Әгәр дә без телебезне югалтсак, милләт югала дигән сүз. Милләтне тотып торучы – тел. Без шуның сагында булгач, халыкка үрнәк булырга тиеш.

**Әлфия Ситдыйкова:** «Әдәби учак» тыңлаучыларына әйтер сүзләрегез бардыр дип беләм. Аларга үзегезнең теләкләрегезне җиткерсәгез иде!

**Равил Фәйзуллин:** Хәзерге глобальләштерү заманында үзүзеңне саклау көннән-көн авырлаша бара. Шуңа күрә халык аңларга тиеш: безнең төп байлыгыбыз – нәсел, ул – рухи ныклык, ул – тел, ул – әдәбият, ул – сәнгать, ул – җыр-моң, көй, ул – тел байлыгы. Безгә менә шуның төп байлык икәнен аңларга кирәк. Кеше мәхәббәтен аңлатканда да, васыятен әйткәндә дә иң кирәкле сүзне эзли. Иң кирәкле сүзләрне язучылар эзләргә, халыкка җиткерергә тиеш. Безнең көчебез – безнең тарихыбыз һәм безнең рухи мирасыбыз. Халык яшәргә тели икән, ул үз тарихын белергә тиеш.

**Әлфия Ситдыйкова:** Үз язмышын ил язмышы белән бәйләп яшәүче Халык шагыйре Равил Фәйзуллин киләчәккә карап, үткәненә таянып гомер баскычлары буйлап яңадан-яңа үрләргә күтәрелә. Үткен каләме, күңел кылларыннан өзелеп төшкән сүзләр белән, тарих битләренә яңа сурәт төшерә. Җуелмас хәтер сурәтен...

*«Әдәби учак» тапшыруы мөхәррире Әлфия Ситдыйкова. Аудиоязмадан алынды.*

# II

# ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ



**Хәниф ХӨСНУЛЛИН,**
*шагыйрь*

* * *

Әлфия Ситдыйкова җырга һәм табигать матурлыгына бай булган Актаныш ягында туып үскән. Мәктәптә уку елларында күңеленә кереп калган бу матурлык, Әлфия КамАЗ төзелешенә килеп двигательләр заводында эшли башлагач, шигъри юлларда чагыла башлый. Туган як кешеләрен, аның болын-суларын, үз авылының урам-тыкрыкларын изге санаган яшьлек шигырь язмыйча түзә алмыйдыр, мөгаен.

Әлфиянең шигырьләре әле камилләшеп җитмәгән. Кайчак инде әйтелгән фикерне кабатлау, ритм агышын абайламый калу сизелә. Ләкин ул шигырьләрдә хисләрнең эчкерсез булуын тоясың.

*1978 ел, 22 апрель.*

* * *

Әлфия Ситдыйкова – Чаллыдагы «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәсенә яңа йөри башлаган авторларның берсе. Ул, КамАЗ төзелешенә үзеннән өлеш кертү белән бергә, Алабуга педагогия институтында читтән торып белемен күтәрә.

Берләшмәнең соңгы утырышында Ә.Ситдыйкова шигырьләре турында да сүз булды: аларның техник яктан шактый камил эшләнүләре билгеләп үтелде, фикер тирәнлеген тагын да арттыра төшү кирәклеге әйтелде.

*1979 ел, 6 январь.*

**Рәшит БӘШӘР,**
*шагыйрь,*
*Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты*

# Сандугачлы таңнарга гашыйк...

*Гаҗәпләнеп карамагыз миңа,*
*Яшь талларга кулым изәсәм, –*

дип җырлый Әлфия Ситдыйкова. Яшьлеккә, сафлыкка гашыйк шагыйрә ул. Дөньяга шагыйрәнә күз белән бага торган шагыйрә. Күрегез әле, буяуларны рәссам кебек ничек нәфис итеп ап-ак кәгазьгә төшерә:

*Урман өсләренә томан төшә,*
*Яңа сауган сөттәй агарып.*

Әлфиягә табигатьтәге һәр бизәк кадерле: адашкан киек каз тавышын көз биргән сап-сары шәленә төренеп тыңлый ул, киселгән пар каеннарны күреп сызлана, сандугачсыз калган талларга карап, күңелендәге хисләрен түгә.

Әлфия талантлы Актаныш ягыннан, Күҗәкә дигән авылда тәүге авазын салган. Камыш түбәле өйнең моңын тыңлап, тимер чөйгә элгән бишектә тибрәлеп үскән җир кызы ул. Казакъстан якларында бәхет эзләгән, илен-җирен сагынып, Чаллыга әйләнеп кайткан, КАМАЗда эшләгән, сатучы булган, инде Чаллы телевидениесындә үз урынын тапкан...

Үзе әйткәнчә:

*Сагыш чишмәләре безнең*
*Күңелгә коя икән.*
*Йодрык кадәрле йөрәккә*
*Диңгезләр сыя икән.*

Аның биографиясе – шигырьләрендә. Шигырьләрен укып чыккач, мин Әлфиянең җанындагы тетрәнүләрне тулысынча аңладым диярлек. Шагыйрә хисләрендә ихлас, назга, яшәүгә сусаган

җанын кешеләргә ачып күрсәтә белә ул. Беренче карашка гади генә тоелган шигырь юлларында аның әрнүләре дә, сөенечләре дә көзгедәге кебек ачык чагыла.

*Күкләр күкри, җирләр тетри,*
*Ни булган бу җиһанга?!*
*Чәбәләнә, тынгы тапмый,*
*Җаным гуя зинданда.*

Икенче бер шигырендә:

*Үтеп бара гомер мизгелләре,*
*Маңгаема өстәп буразна.*
*Кемнәргәдер сыенасы килә,*
*Онытыласы килә беразга. –*

дип, зиндандагы җанын иреккә чыгарырга теләп үрсәләнә.

*Тибрәник, җаным, икәүләп,*
*Без бәхет сиртмәсендә! –*

дип, киләчәккә өмет белән бага.

Шагыйрәнең дөньяны җылытырлык наз тулы йөрәгенә хәтта күшекккән яфрак та килеп сыена.

Бала сыман саф җанлы шагыйрәгә без дә бәхетле көннәр, сандугачлы таңнар телик.

Җырлы таңнар телик!

*2003 ел, 21 февраль.*

## Тәкъдимнамә

Әлфия Ситдыйкова инде дистәгә якын китап авторы. Беренче «Йөрәгемә яфрак сыена» китабының кульязмасын алып килүгә, шигырьләрен укый башлагач мин сөенеп утырдым. Тагын бер үзенчәлекле шагыйрә килә икән әдәбиятка дип. Китапка сүз башы яздым. Аллага шөкер, Әлфия бу ышанычны аклап, иҗат итүен дәвам итә. Бу бик сөенечле хәл.

Әлфия талантлы Актаныш ягыннан, Күҗәкә дигән авылда тәүге авазын салган. Камыш төбәле өйнең моңын тыңлап, тимер чөйгә элгән бишектә тирбәлеп үскән җир кызы ул. Казакъстан якларында бәхет эзләгән, илен-җирен сагынып, Чаллыга әйләнеп кайткан, КамАЗда эшләгән, сатучы булган, инде Чаллы телевидениесында үз урынын тапкан...

Әлфия үзенең үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә соңгы елларда бик күп уңышларга иреште. Аның шигырьләре республика матбугатын яулап алды. Шигырьләре «Казан утлары», «Татарстан», «Мәйдан» журналларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарында дөнья күрде.

Әлфия хисле шагыйрә, уйлы шагыйрә. Аның үзенең язу стиле формалашып җитте, үзен шигъриятта тапты. Ул – мәхәббәт җырчысы. Аның шигырьләре мәхәббәт турында. Шигырьләреннән хатын-кызларга гына хас наз, җылылык, садәлек, сафлык бөркелеп тора. Әлфия шигърияте бүгенге авыр заманда кешеләр күңелендә өмет уята. Яшәүгә ышанычны ныгыта. Аның иҗатының иң кыйммәтле ягы шул.

Әлфиянең дәүләт нәшриятында яңа китабы басылып чыкты. Татарстан китап нәшриятында тагын бер китабы басылу көтеп ята.

Әлфия Ситдыйкова киләчәктә дә безнең ышанычны аклар, иҗат ачышлары белән күп мәртәбәләр куандырыр дип ышанам һәм аны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим итәм.

*2008 ел, январь.*

**Факил САФИН,**
*язучы, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре*

# Җанда шәмнәр янганда...

*«Нәни генә бер шәм яна безнең җанда...»*

Шушы шигырь юлларын укыгач, Шәехзадә Бабичның «Исте җил, сүнде бер ялган шәм» дигәне искә төште. Аң кисәк кабынып, кулга килеп кергән өр-яңа шигырьләр тупланмасын укый башладым. Кульязманың авторы – Әлфия Ситдыйкова. Исеме Чаллы матбугатында күренеп тора. Актив иҗат итә. Анда шигъри җегәр, дәрман бар. «Күңел» радиосы аша да аның теге яки бу кешегә багышлап язылган котлау, шигъри тәлгәшләрен тыңларга туры килә. Бер карасаң, мондый мәҗбүрият (ул радио аша яңгырый торган котлауларны шигъри юлларга салучы хезмәткәр вазыйфасын башкара) аның яктылыкка, шигърияткә омтылган җанын ваклап, күңелен чәрдәкләп бетерергә тиеш кебек. Бәлки шулайдыр да. Әмма шушы «вак» эшкә дә ул җитди карый, һәр текстка берәр үзенчәлекле табыш кертергә омтыла. Инде яңа китабы өчен сайлап алган шигырьләренә килгәндә, Әлфия үсештә, күтәрелештә. Шигырьләрендә яшәешнең төсмер-төсләре, ихласлылык, борчу-шатлыклар, тасвир-образлылык күзәтелә. Шагыйрәнең лирик герое көчле, авырлыкларга бирешмичә һаман алга бармакта.

*Тау-ташларны кайчак иңгә салып*
*Үргә менәр көчләр табыла.*

Кешене өмет, мәхәббәт яшәтә. Шагыйрь күңеле үзенә менә шундый көч бирә алырлык игелекле җаннарга тартыла. Шуларны раслаган шигъри юллар шактый. «Дөнья кинәт үзгәрепләр китте», «Тугайларым туйга әзерләнә», «Өмет учагының көле кайнар». Әлфия шундый табышларын тагын да тирәнәйтеп, хисси бөтенлеккә ирешкән шигырьләрне күбрәк язсын иде.

Хатын-кыз язмышына тигән яшәеш өчен җаваплылык, ялгызлык, туган як темасы еш күзәтелә шигырьләрдә. Аларда да Әлфия

Ситдыйкова традицион алымнарга таянып, үзенчәлекле яңгыраш тудырырга омтыла. Анда шигъри тоем, ритмик аһәң көчле. Әгәр дә шушы эзләнүләрен дәвам итсә, һичшиксез әле ул безне матур-матур шигырьләре белән күп сөендерер.

*2004 ел.*

## Тәкъдимнамә

Шигырь язган өчен шагыйрь булмыйлар, шагыйрь булган өчен шигырь язалар. Әлфия Ситдыйкованың шигырьләрен укыганда бу фикер башка еш килә. Әлфия шагыйрь – тумышы, булмышы белән шагыйрь. Ул дөньяны үзенчә, хисләр аша күрә. Хәзерге шыксыз заманда шигъри сүз әйтү өчен җанның әйбәт тынгысызлыгы, дөньяны, кешеләрне ничек бар шулай ярата белү сәләте, рухи ныклык кирәк булса, аны хискә төреп, башкаларның җанында сихри ялкын кабыза алырлык итеп яза алу өчен сирәк талант кирәк.

Әлфия Ситдыйкова Актаныш ягыннан. Ул яктан күп талант иялəрен беләм. Һәркайсының үз йөзе, үз шагыйрәнә сәерлеге. Әлфиянең «сәерлеге» шунда, ул иҗат итми, ул – иҗат белән яши. Чаллы әдәби мохитында Әлфия Ситдыйкованың үз урыны һәм, әйтергә кирәк, лаеклы урыны бар. Үткән гасырның җитмешенче елларында ук Чаллыга килеп, шигърияткә табынган яшьлек дәрте белән гомуми әдәби атмосферага кушылып киткән беренче карлыгачлардан ул. Чаллыдагы күп әдәбият әһелләре белән яхшы таныш, күпләгән әдәби чараларда, очрашуларда иңгә-иң торып катнашкан яшь шагыйрә. Үз чорында ук коллектив җыентыкларда бәйләм-бәйләм шигырьләрен бастырып, иҗатка хокукый юллама алган шагыйрь гаилә, тормыш мәшәкатьләре белән туксанынчы еллар башында әдәби хәрәкәттән читләшә төшкән иде. Әмма шагыйрь күңеле һаман янган, иҗатта булган икән, янәдән әдәби мәйданга Әлфия ашкынып, гаять көчле энергия, җегәр белән «кайтып төште». Бер-бер артлы китаплары чыга торды, бигрәк тә «Назга сусау», «Туган якның ике чишмәсе» дигән китаплары дөнья күргәч, аны Татарстан Язучылар берлегенә алу кирәклеге көн тәртибенә басты. Чөнки Әлфия Ситдыйкованың шагыйрьлеген томалап та, яшереп тә куеп булмый инде, ул үзе дә тик торуны белмәс зат, актив, гамьле, киң күңелле, башкаларны да иҗади өлгерлеккә өнди, үрнәк булып тора.

«Назга сусау» китабы икенче бер шагыйрьнең хиссиятенә ка-

рата хисси җавап рәвешендә язылган. Ул шигырьләрдә кеше күңеле бөтен тирәнлеге белән ачыла. Аларда никадәр очыну, илаһият, сөюгә дан җырлау, гыйшкый гыйсьянчылык бар!

*Гасыр кичеп килдем сиңа,*
*Пешеп, көеп, туңып та.*
*Яндыр әйдә сихерчедәй,*
*Яндыр син мине утта.*

«Туган якның ике чишмәсе» китабы үзе бер сенсация булды. Монда Әлфия инде тәрҗемәче буларак та шактый нык куллы икәнен күрсәтә. Шулай ук китапта урын алган «Буталган язмышлар» поэмасы авторның киң сулышлы шагыйрь булуын раслый. Темалар киңәя. Әлеге китапта җир, дөнья гамен хаклаган әсәрләр байтак.

*Тынып тормый гасырлардан*
*Гасырларга сугыш уты.*
*Яна-яна ярлылана*
*Бар халыкның уртак йорты.*

Әлфиянең шигырьләрен поэтик яктан күзәтсәң, каләменең төрле сурәтләү чараларына бай икәнен күрәсең. Бер үк темага язылган шигырьләрендә дә ул төрле аһәң, төсмерләр табуга ирешә. Лексик берәмлекләрнең мул булуы, ритмик төзеклек Әлфия Ситдыйкованың шигъриятен гадәти тезмәләр язучы күп санлы шигырь язучылардан нык аерып тора. Әйтергә теләгәнен кыска гына шигырьдә дә тулысынча әйтеп бирергә маһир, фәлсәфә, кичерешләрне чама белән куллана алу осталыгына ия. Шул ук вакытта Әлфия жанр кысаларын да киңәйтә бара. Вакытлы матбугатта нәсерләрен еш күрәбез, каләмдәшләре иҗатына күзәтүләр, мәкаләләр белән дә еш чыгыш ясый. Ул иҗат дөньясын дикъкать белән күзәтеп бара, битарафлык аннан ерак йөри. Менә болар барысы да Әлфия Ситдыйкованың җитлеккән каләм иясе икәнен раслыйлар.

Мин Әлфия Ситдыйкованы Татарстан Язучылар берлегенә алырга лаек дип саныйм һәм аны берлеккә тәкъдим итәм. Аның Татарстанның күренекле каләм ияләре сафына басачагына шигем юк.

*Билет саны – 257. Чаллы шәһәре,*
*14 гыйнвар,2008 ел*

# Игелекле каләм иясе

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкованың исеме әдәбият, шигърият сөючеләргә яхшы таныш. Озак еллар Яр Чаллы шәһәрендә эшләүче «Күңел» радиосында «Әдәби учак», «Илһам нуры» тапшыруларын оештыручы, күпләргә әдәби тормыш турында тирән эчтәлекле әңгәмәләре белән истә калган журналист, меңләгән милләттәшләребезнең иң матур гомер бәйрәмнәренә кабатланмас, ихлас шигырьләр юллаган тәбрикләмәләр, популяр җырлар авторы. Бу вазыйфаларның һәркайсына йөрәк җылысын сала, һәр эшенең мәгънәле булуына ирешә, кешеләргә, халкыбыз тормышына кирәкле итә. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасе Әлфия Ситдыйкова дистәләгән китаплар авторы да. Рухи мирасны өйрәнү төбәк фәнни-методик үзәге каршында эшләүче «Шәһәр һәм төбәк журналистикасы музее» җитәкчесе буларак та Чаллы һәм республиканың иҗтимагый тормышында билгеле эз калдырып килүче шәхес.

Әлфия Мирзанур кызы Ситдыйкова Татарстанның Актаныш районы Күҗәкә авылында 1957 елның 14 августында туган. 1974 елда Пучы урта мәктәбен тәмамлый һәм романтик күңелле кыз яшьлек каласы Чаллыга, зур төзелешләр мәйданына килә. Чаллы шәһәренә килү белән ул КамАЗ заводында йөк төягеч машина йөртүче булып эшли, «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә йөри башлый. Аның беренче әсәрләренә үк зур шагыйрьләр игътибар итәләр, аңа матур иҗади киләчәк юллыйлар. Әлфия Ситдыйкова ашыкмый гына иҗат итте, зур тормыш мәктәбе үтте, шигырьләре аерым китапларда дөнья күрде, республика матбугатында да аның әсәрләре еш басыла. Ул инде исеме яхшы билгеле киң колачлы лирик шагыйрь. Яшьлеге канатлы чорга туры килгән шагыйрә, инде әдәбиятта ныклы урын алгач, Чаллы педагогия институтын тәмамлап, югары белемле филолог булды. Бүгенге көндә армыйталмый иҗат итә, шәһәрнең иҗади мохитен җанландырып торучы игелекле каләм иясе.

Чын талант иясе беркайчан да балаларны читләтеп үтә алмый. Соңгы вакытта шагыйрә балаларга атап та шигырьләр яза башлады. Моңа сәбәпче – үзенең оныклары туу һәм күпләгән мәктәпләрдә, балалар бакчаларында очрашулардыр дип уйлыйм. Шагыйрәнең балаларны игелекле, мәрхәмәтле, туган илне, туган телне яратучы, эшсөярләр итеп күрәсе килә. Күп шигырьләре дөньяны танып бе-

лүгә корылган. Нәниләр өчен язган шигырьләрендә дә Әлфия Ситдыйкова ихласлылыгын саклап кала. Алар гади һәм йөгерек тел белән язылганнар. Бу шигырьләрне укыгач, аның балалар күңелен аңлап эш итүче педагог, чын шагыйрәнә җан икәнлеген тоясың. Киләчәктә Әлфия Ситдыйкованың балалар әдәбиятында да ныклы урын алачагына ышанам мин.

*2009 ел.*

## Офыгы киң, күге биек

Әлфия Ситдыйкова... Аның исеме кайберәүләргә Чаллыда башланган яңа төзелешләр чорыннан ук таныш, күпләр исә аны шигъриятькә соңгы унбиш-егерме елда килде дип исәпли. Әлфия Ситдыйкова тормышка, кешеләргә гашыйк, һәрчак елмаеп, балкып тора, бер нәрсәгә дә битараф түгел, башкаларның хәленә кереп, ярдәм кулы сузарга әзер кешелекле ханым. Ул – йөрәк җырчысы, мәхәббәт җырчысы. Шигърияттә заман болгануларыннан тәмам аптырап, чарасыз калган каләм ияләренең аһ-зарларын укып, шигъри зәвык зәгыйфьләнә башлаган чор иде. Мәхәббәт шигырьләрен яки мәхәббәткә багышланган (болар икесе ике нәрсә) шигырьләргә түбәнсетеп карау да сизелә башлаган чакта Әлфиянең шигъри юллары сискәндереп җибәрде:

*Минем җаным шигырь белән сулый,*
*Шигырь белән назга туена.*
*Килеп кердем ап-ак шигырь белән*
*Ак чәчәкле яшьлек туена.*

Күп кенә каләми затлар: «Безнең тормыш гел кара төсләрдән генә тора, без инде аякка баса алмаячакбыз, безне котылгысыз һәлакәт, юкка чыгу көтә», – дип, үзләрен дә, башкаларны да ышандырып бетерә язган бер вакытта, һәм, бәлки, иң кирәк вакыттадыр, Әлфия Ситдыйкованың аклык, сафлык, сөю тулы шигырьләрен укып, күңел түрендә җылылык сирпелде, «дөнья гел кара төсләрдән генә тормый лабаса, анда мәңгелек кыйммәтләрне бар иткән – мәхәббәт тә бар әле», – дигән уй сызылып үтте. Күңел офыклары яктыра, томаннар чигенә, күңелдә тансык хисләр уяна башлады.

*Гүзәл язлар бүләк иттең миңа,*
*Яктырта ул гомерем иртәсен.*
*Минем өчен җирдә иң кадерле*
*Синең караш – илһам чишмәсе.*

Мондый эчкерсез, тыенкы ашкыну, сөю-наз тулы юллар көй язарларны үзенә тиз җәлеп итте. «Синең караш – илһам чишмәсе» шигыренә Әлмәттә яшәп иҗат иткән, бик күп җырлар авторы Рәис Нәгыймов көй язды һәм ул күпләрнең күңелен яулап та алды. Альфред Якшимбетов, Мөдәррис Газетдинов, Илнур Фәйзуллин, Флүрә Талипова, Фәрит Миңлебаев, Факил Сафиннарны да дистәләгән көй язарга илһамландырган иҗат бу!

Иҗатта Әлфия Ситдыйкованың үз юлы, үз укучысы бар. Ул шигырьдә, беренче карашка гади, әмма күңелнең нечкә кылларын тибрәтерлек сүзләр тезә, кеше күңеленә сак кына шакып, пышылдап кына үз җанындагы иң яшерен серләрне дә ачып бирә. Ул – үз укучысын фикердәшенә әйләндерә алырлык серле шагыйрә. Чәчрәп чыкмый, кабаланмый, тота-каба башкаларны үз язганнарына ышануларын таләп тә итми, аның дөньяны сөю призмасы аша кабул итүе төгәл, анык. Мондый поэзияне ничек үз итмисең ди! Шул ук вакытта укучы тоя: шагыйрәнең күңел капчыгында яшерен хисләре төрелгән шигырьләр дә шактый кебек, күңелендәге шәхси яра-әрнүләрне башкалар белән уртаклашасы урынга ул аларны һаман эчкәрәк бикләргә омтыла...

*Кем ярасын кем дәвалар,*
*Җанга тоташ моң тулгач.*
*Җиргә килгән һәрбер кеше*
*Ул – яралы сандугач.*

Һәркем тормышын үзе яза. Әлфия Ситдыйкованың иҗат язмышы хакында уйланганда, мин аның үзем белгән кадәрле тормыш юлын да күздән кичерәм һәм, шактый сынаулар үтеп тә, күңел байлыгын, хисләр муллыгын югалтмавына гаҗәпләнәм, нечкә сүз-хисләрдән тезелгән зәвыклы шигырьләр язуына сокланам.

Актаныш районы Күҗәкә авылында туып-үскән, югары белем алырга хыялланган кызны язмыш, Пучы урта мәктәбен тәмамлагач, Чаллы якларына алып килә. Әти-әни куенынннан аерылган мизгелләр һәркемгә таныш. Чит-ят җирдә сине беркем дә көтеп тормый.

Туганың да, дустың да... Беренче мәлләрдә синең үз күңелең, үз уйларың гына. Кем хәленә кем керә? Синең белемгә омтылышың, әдәбиятка мөкиббән булуың, башкалар күзеннән яшереп кенә шигырьләр язуың кемгә хаҗәт? Ил башка уйлар, башка мәшәкатьләр белән яши. «Син, яшь кеше, алга партия куйган максатларны күтәрешергә тиешсең. Маяк – Павка Корчагиннар! Үзеңне шушы токымнан икәнеңне расларга тиешсең, бәбкәем», – дип, совет иле күзеңә тутырып карап тора бит. Шушы чакырулар, шушы тәрбия, гомумсовет тормышының бер винтигы буласы килү тойгысы күпләрне Чулман буендагы яшь калага китерә. Чаллы кайный, кая бакма – төзелеш, илнең бөтен тарафыннан җыелган бер-берсенә чит, әмма беренче очрашудан ук иң якын кешеңә әйләнеп куйган яшьтәшләрең, чордашларың, гамьдәшләрең барлыкка килә. Чордашларың – КамАЗ төзүчеләр, «кешеләргә яңа кала төзеп бүләк итүче» иң юмарт, иң тырыш буын вәкилләре. Дөнья кырыс, дөнья чуар. Аңлаешсыз омтылышлы сәер дөнья үзенә суыра, аң-зиһенне шигырьләр түгел, шигарьләр биләп ала. Диварларда язылган сүзләр керфекләрне каерып ача, күңелгә бәреп тора: «Даешь.... Даешь... Даешь». Яңа шәһәр, яңа заводлар комплексы, яңа йортлар, яңа машиналар... Боларның һәммәсен яшьләр бирергә тиеш. Әлфия менә шушы мохитка килеп эләгә – тиз арада дизель төягече йөртүчесе һөнәрен үзләштереп, егерме елдан артык автомобильләр төзү заводында эшли. Эшен яратып, тел-теш тидертмәслек итеп башкара. Мин үзем шушы заводта гади эшчедән участок башлыгы вазыйфаларын башкаручы дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше буларак әйтәм: эшчеләр телендә «погрузчик» дип аталган бу машиналарда эшләүче кызларның КАМАЗ дигән машиналар чыгаруда хезмәте бик зур.

Күңелеңә Аллаһ Тәгалә иҗат очкыны салган икән, аны үзең дә сүндерә алмыйсың, башкаларның да кулы җитми. Әлфия, эшли башлап тулай торакка урнашканнан соң ук, Чаллыда танылган «Ләйсән» әдәби берләшмәсе барлыгын ишетеп ала. Бәлки тулай торакның «Кызыл почмагына» Чаллыда яшәп, иҗат итүче шагыйрьләр килгән булгандыр. Аларны күреп тыңлагач ук, кызның күңел түрен янә иҗат очкыннары яктырта башлагандыр. Шунысын беләм: 1975 елның көзендә Әлфия Ситдыйкова ул чакта әсәрләре газета-журнал битләреннән төшмәгән Мәхмүт Газизов, Хәниф Хөснуллин, Әхәт Гайнуллин, Ямаш Игәнәй, Рәйсә Фәхразиева, Фирая Хәлиуллина, Шәүкәт Гаделша, Венера Хәбибрахманова, Нәсыйх Таҗиев һәм башка бик күпләрнең тавышлары белән шаулап-гөрләп

торган «ләйсәнчеләр» сафына килеп кушыла. 1978 елда шәһәргә Кадыйр Сибгатуллин килгәч, әдәби мохит яңа биеклеккә күтәрелә. Шигърияткә, каләм иясенә булган караш та тамырдан үзгәрә. 1979 елда Татарстан китап нәшриятында «Яшьлегем Чаллы» исемле җыентык басылып чыга. Әлфия Ситдыйкованың берничә шигыре дә урын ала әлеге җыентыкта.

*Мин һаман да шул авылча инде,*
*Тел-сөйләмем һаман шул көе.*
*Үзгәрмәгән шул ук елмаюым,*
*Шул ук икән моңнар сөюем.*

Күренгәнчә, тәүге иҗат җимешләре үк «без Әлфия Ситдыйкова каләменнән өзелеп төштек» дип яктырып торалар. Ихлас, табигый, укучы белән күзгә-күз карап, тыныч, әмма хисси сөйләшү.

Әлфия Ситдыйкова шактый еллар әдәби мохиттән югалып торды. Кияүгә чыгу, балалар үстерү мәшәкатьләре, тормыш көйсезлекләре... Туксанынчы еллар... Завод эшчеләренә, төзүчеләргә бу елларда җиңел булмады.

Яңадан шигърияткә кайту авыр, һай авыр була. Әлфия Ситдыйкова каләмдәшләре сафына соңлап, бары ике меңенче еллар башында гына кабат килеп кушыла. Аны шагыйрь итеп таныган, үсендереп торган Кадыйр Сибгатуллиннар буыныннан инде беркем дә калмаган. Бакыйлыкка күчкәннәр. Яңалар ышанмыйчарак кабул итәләр шагыйрәне. Каләм ияләре арасындагы элеккеге самимилек, иҗади аңлашу, туганлык хисләре сүнгән, мин-минлек көчәйгән... Чаллының әдәби мохите хуҗасы ташлап киткән йортны хәтерләтә. Менә шундый шартларда иҗатта үзеңне танытып кара!..

Әлфия Ситдыйкова Чаллы телерадиокомпаниясенең «Күңел» радиосына эшкә килә, әдәби тапшырулар оештыра, аларны халык яратып тыңлый. Соңлабрак булса да, яшьлек хыялы тормышка аша – Чаллы педагогия институтының филология факультетын тәмамлый. Рәшит Бәшәр, Факил Әмәк имзалаган сүз башлары белән бер-бер артлы китаплары чыга башлый. 2006 елда Казанда дөнья күргән «Назга сусау» китабына кереш сүзне Рәдиф Гаташ язган. «Бу китап, минем уемча, – гадәти булмаган, яңа, бер тыннан язылган – шикләнмичә әйтәм – бер сулыштан укыла торган мәхәббәт китабы, җан эзләнүләре китабы... Бу китап... ниндидер бер реаль яшәү, җир чынлыгы яки конкрет мәхәббәт тарихы түгел, ә бәлки нәкъ менә идеал булырлык Сөю эзләгән хатын-кыз җанының гаҗә-

еп серле, без белмәгән сихри көче чагылышы ул...» Халык шагыйре әйткәнчә, без Әлфия Ситдыйкова шигырьләрен укыганда, иң беренче нәүбәттә аның әсәрләрендә күңелне тетрәндереп җибәрүче шушы «сихри көч чагылышына» игътибар итәбез дә инде. Әлфия Ситдыйкованың бер карасаң, сагышлы, моңсу, икенче карасаң, ашкынулы, ниндидер серле дөньяга омтылышлы шигырьләренә игътибар итми мөмкин түгел. Алар – югары уку йортында шигырь теориясен өйрәнеп хисси ясалган, техник яктан бик оста үрелгән шигырьләр түгел, ә тормыш яздырган шигырьләр, кулына Ходай биргән каләм тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр.

*Әллә син адаштың, әллә мин адаштым,*
*Нигә соң очраштыра язмышлар?*
*Синең дә йөрәктә, минем дә йөрәктә*
*Гомергә җитәрлек сагыш бар.*

Бу юллар «Язмышлар» шигыреннән, Флүрә Талипова аны көйгә салган. Җыр радио, телевидение аша еш яңгырый.

*Яраттырган һәм яраткан өчен*
*Хөкем итеп карар чыгарма.*
*Көлеп яшим, керфекләрем генә*
*Таң чыгыдай яшькә чылана...*

Күпләр игътибар иткәндер, Әлфия – мәхәббәт шигырьләре язучы сирәк каләм ияләреннән. Мондый шигырьләрдә шагыйрәнең күңеле тулысынча ачыла, тартылу, наз, сөюдән баш югалту, оялчанлык... Ул интим хисләрне матур итеп, укучы күңелендә хисләр бураны кузгатырлык дәрәҗәдә оста итеп тасвирлый. Монда талымсызлык юк, монда кайнарлык, кеше табигатенең сөюдән илаһи биеклеккә чөелүе генә бар. Кешене мәхәббәт, ярату бар итә, ярату, сөю булганда гына кеше тормышы мәгънәгә ия. Ә сөю үзе – каршылыклы хисләр өермәсе. «Язмышлардан узмыш», «Җиде төн», «Назга сусау», «Сөю кошы» кебек күләмле шигырьләре, «Язмышлар ярында» поэмасы Әлфия Ситдыйкованың шигъри куәсе тирән һәм саллы, егәрле булуын, иркен сулышлы каләм иясе икәнлеген раслыйлар. Әлфия Ситдыйкованы мәхәббәт лирикасында үз тавышын ишеттергән, аны яңа биеклеккә күтәргән, башка төсмерләрдә ача алган лирик шагыйрь дип атарга тулы хакыбыз бар.

*Бүләк-җәза язмышымнан миңа –*
*Бүген сөйдем, кичә сөелдем.*
*Боз-ялкынга төреп җылыттың да*
*Болыт булып алга түгелдең.*

Мәхәббәткә табыну бер нәрсә, ә чын хисләрне зурлый белү, Рәдиф Гаташ әйткәнчә, «мәхәббәтне олылый» белү икенче нәрсә. Әлфия – чын сөю барлыгына ышандыра алган самими шагыйрә. Мәхәббәт хакында язарга дип кулга каләм алганчы, сорау туа торгандыр: бу гаҗәеп төгәллек таләп иткән темага ничек якын килергә? Күпләр моңа анык кына җавап бирә алмыйлар. Әлфия Ситдыйкова исә беләдер кебек. Юкка гына ул «Язмышлар ярында» поэмасына эпиграф итеп Онаре де Бальзак сүзләрен китермәгәндер: «Кешене бәяләр һәм хәлен аңлар өчен, ким дигәндә аның бәхетсезлегенә, кичерешләренә, аның серләренә үтеп керергә кирәк». «Буталган язмышлар» поэмасында Әлфия Ситдыйкова чын сөю үрнәген сурәтли. Үзәктә – Мирхәйдәр белән Сәйдәнең мәхәббәте. Бу әсәр нигезендә фильм төшерәсе иде. «Ак чәчәкләр»дән ким булмас иде ул.

Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Утлы җимеш» (2011), «Тансык бәхет» (2012) китаплары Әлфиянең инде өлгереп җиткән шагыйрь булуын расладылар.

Шагыйрь күңеле һәрчак эзләнүдә. Әлфия Ситдыйкова гади колхозчы гаиләсендә туган, ул – гади авыл кызы. Әтисе Мирзанур ага балта остасы да, тирә-якта яшәүче якташларына кырыкка якын йорт төзеп биргән кеше. Ул, 1943 ел башыннан Совет Армиясенә алынып, автоматчы, соңрак пулемётчы-артиллериячеләр батальонында радиотелеграфчы булып 6 ел солдат хезмәтен үтәгән, Япония милитаристларына каршы сугышта катнашып, илен яклаган ветеран. Тик, ни сәбәптер, аңа ветеран исеме бирелми. Авыл советында «архив янган» дип җавап бирәләр. Аның күкрәгендә чыңларга тиешле II дәрәҗә Ватан Сугышы орденын Мирзанур ага үлгәннең икенче көнендә өйгә китереп тапшыралар. Ә ул шактый яшьли вафат була, гаделсезлекләргә әрнегән йөрәге түзми. Әнисенең бу орденны күкрәгенә кысып елавы Әлфиянең бүген дә күз алдында.

Тормышның төрле ягын күргән шагыйрәнең торган саен иҗаты киңәя, күтәргән темалары саллылана бара.

*Көянтәләп сулар ташыганда,*
*Иңсәләрем шундый арый иде.*

*Бүген инде иңнәремә Каләм*
*Халык гамен, дөнья йөген өйде...*

Иҗат кешесе кулына каләм алган икән, димәк, аның үзенә генә бирелгән вазифасы – ул гына башкарырга тиешле илаһи мәҗбүрияте – миссиясе бар. Каләм иясе шушы мәҗбүрияттән кача икән, димәк, ул шәхес буларак өлгереп җитмәгән. Әлфия Ситдыйкова дөнья күзенә туры карап яза: *«Яңа көнгә аяк басам, / мең төрле уйлар уйлап»*. Туган җир язмышы да, ил, халык, милләт язмышы, туган телебезнең юкка чыгу чигенә җитеп баруы, читтә яшәүче милләттәшләребез тормышы – аны һәммә нәрсә борчый, болар хакында башкаларның җанына үтеп керерлек әсәрләр яза. Шагыйрь Туфан әйткәнчә «әйбәт тынгысызлыкта» яши, иҗат итә. Әмма шагыйрә каләмен өметсезлек чигенә китереп терәми. Киләчәккә, халкына булган ышаныч-иман – шигырьдә аның төп кредосы.

*Егылсам да, туган туфрагымнан*
*Дәрман алып торып басармын.*
*Үги түгел, үз баласы бит мин*
*Сынмый яши торган татарның.*

«Бетәбез» дип йөргәннәргә Әлфия рухи сабак бирә. Без бетмибез, «без яшәргә хөкем ителгән» (Равил Фәйзуллин). Бу фикер – аның иҗатының лейтмотивы. Күңелендәге яктылыкны замананың җил-давыллары сүндерерлек түгел, ул – көчле шәхес: *«Тәрәзләрне җилләр каккан чакта, / Ябылмасын күңел капкагыз»*. Яки *«Кешелекне саклап, Кеше булып / Кичик шаулы тормыш елгасын»... «Без бүгеннән уянырга тиеш, / Уятырга тиеш күршене...»* Маңкортлашу тирәнгә төшсә дә, милләтнең үзәге исән: *«Җаның әле саның эчендә»*. Санны сыйфатка әверелдерү бүгенге вазгыятьтә авыр мәсьәлә, әмма мөмкин булмаган эш юк. Милләткә бердәмлек кирәк. Бу яктан без нык сынатабыз шул әлегә.

*Менәселәр килә тау башына,*
*Бөркет кебек канат кагынып.*
*Әйткән сүзем калсын кешеләрнең*
*Күңеленә балдай ягылып.*

Тормышны кабул итәргә өйрәнергә кирәк. *«Сүнми янган гомер учагының / Көле дә бит шундый кадерле»*. Бүгенге кайбер уңышсызлыклар, күңелсезлекләрне төзәтеп булмас дип уйласак,

үл дә кит. Егылмаска, яшәргә кирәк. Үзе дә уяныргa, башкаларны да уятырга тиеш каләм иясе. Татарда үрнәк алырлык батырлар, көчле затлар күп: «Көчлеләргә карап алга атлыйм, / Көчлеләрдә – халык хәтере!» Әлфия Ситдыйкова да – көчлеләр токымыннан. Тик ул – шагыйрь, аның җаны үтә нәзберек, табигате үтә нечкә: *«Мин бу юлда адашканнар өчен / Юл күрсәтеп үскән бер гөлең». «Ишетерләр беркөн, аклык теләп / Күз яшьләрем аша дәшүне»...*

Әлфия Ситдыйкованың туган авылы Күҗәкә – борынгы авыл. Ул зур мәдрәсәле, укыту-белем бирү үзәге буларак тирә-якта дан тоткан. Күҗәкә мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләр, Уфага барып, имамлыкка имтихан бирү хокукына ия булганнар. Шушы якның суын эчеп үскән шагыйрәнең туган ягына ихтирамы чиксез:

*...Белмәгәнмен кайда туасымны,*
*Кайчан туасымны, кем булып.*
*Тик мин тоям, тамырлардан ага*
*Бабамнардан калган моң, тулып.*

Әнкәсе Гөлсем апага атап язган шигырьләрендә дә Әлфиянең күңеленә салынган моңнарның чыганагына тап булабыз. «Авылның Акъәбие» дип йөрткәннәр Гөлсем апаны. Авыл кырыс, әмма гадел хөкем йөртә. Бу изге исемне һәркемгә дә бирми ул.

*Халык җырын җырладың син безгә,*
*Атап түгел, тик эш арасында.*
*Боекканда юатты да ул җыр,*
*Дәвалады йөрәк ярасын да.*
*Рәхмәт, Әнкәй, сиңа барысы өчен...*

Туган якта каты җил исеп китсә дә, Шагыйрәнең күңелен кузгата. Туган ягы – Актаныш төбәге өчен Әлфия җан атып яши. Туган ягына багышланган шигырьләре, җырлары байтак аның. Бернинди ясалмалылык, ярарга тырышу юк аларда. 2007 елда Актаныш өстеннән гарасат үтә. Давыл иген басуларын, агачларны актарып ташлый. Шагыйрә, давылның юктан купмавын әйтеп, сәбәпчесе битарафлык булуын, халыкның, дөнья мәшәкатьләренә чумып, милләт гамен югалтуын күрсәтә, мәхшәр аша халкына эндәшә («Давыл тавышы»). Бу давыл кисәтү булып кабул ителә. Битараф яшәүне дәвам итсәк, тагын да аянычлырак хәлләргә тап булуыбыз бар. Бу кисәтү һәркемгә кагыла:

*Туфан купмас борын уян, халкым,*
*Ач күзеңне, берүк соңлама!*
*Ишетәсеңме, агач тамырын кочып,*
*Җир-анакай үкси, сызлана.*

Бүгенге авылның хәле аяныч. Шагыйрә кабат-кабат авыл темасына әйләнеп кайта. «Үлмә, авыл!» балладасы авылның гөрләп торган чакларын искә төшерә. Лирик герой берәм-берәм авылдашларын барлый. Кино кадрларыннан үткән төсле, Кендек әби, Хатыйп абыйлар, Сәгыйдә апа, Гариф абыйларны күреп калабыз. Инде алар мәңгелеккә күчкәннәр. Онытылып баралар. Һәркайсының язмышы – үзе бер тарих. Авыл кешеләрен җуя, моңнарын оныта. Яңа, ят көйләр урамнарны кыйнап үтә:

*Дөмбер-дөмбер итеп, заман көе*
*Бәреп үтә безнең чигәгә.*
*Таныш моңнар түгел, чит-ят аваз*
*Килеп керә җансыз өйләргә.*

Авылдан яшьләр киткән, киләчәккә өмет какшый. Авылны чолгап алган ямьле табигатен барлап йөри шагыйрә, басу-кырларны иңли, эш осталарын хәтерендә яңарта. Боларны авылдан бизгән яшь буынга ничек тапшырырга?

*Барла, хәтер, барла үткәнеңне,*
*Ялга аны килер буынга.*
*Чайка аңны, чистарынып китсен,*
*Чайка көмеш чишмә суында.*

Шушы ук тема «Киләчәгең кайда, Кешелек?», «Күмер базы» поэмаларында тагын да үстерелә. Авылның бетү сәбәпләре тирәнтен ачыла, аны саклап калу, кешеләрен барлау, аларны авыл хәтеренә беркетеп калу зарурлыгы искәртелә. Авыл бетү – милләтнең, телнең юкка чыгуы түгелме?..

*Үз телендә дәшә алмый күпләр*
*Үзе гомер биргән балага.*
*Бүген кайсы татарны син алма –*
*Мескенлеккә барып ялгана.*

Үткән гасырның илленче елларында яшь парларга, өйләнешү белән, налог салына торган булган. Ит, йон, йомырка, сөт салу, хәт-

та акчалата да түләүләр булган... Әмма яшьләр өйләнешә торалар... һәм читкә чыгып китәләр. Барысының да теләге бер: еллар яхшыргач, акча туплап, туган якларга кайтырбыз. Әмма чынбарлык икенче шул.... Әлфия Ситдыйкованың «Күмер базы» поэмасын укыганда сискәнеп куясың... Балалар туа, руслашып үсәләр. Шахталар төзелеше көрчеккә терәлгән, инде мондагы шәһәрләр дә үлеп бара. Мәңгелеккә киткәннәр гомуми зиратка күмелә... мөселманча күмелгәннәрнең дә рухлары тыныч түгелдер...

*Зират бер дә, кыйблалары башка –*
*Татар, урыс кабере рәттән.*
*Ярымайга каршы, мәрмәр ташка*
*Урыс побы тәре терәткән...*

Шулай да авылларны кайбер фидакарь затлар саклап кала әле. Яңа йортлар салына, аларга карап өмет уяна.: «Күрәсезме! Ирексөяр бүген / Яңа йортлар сала авылында»... Авылны яшәтү өчен көрәшкә күтәрелүчеләргә рәхмәтебез чиксез.

Әлфия Ситдыйкова – үзен поэма жанрында сынап караган һәм бу өлкәдә уңышларга ирешкән, бүгенге күзлектән караганда, сирәк шагыйрьләрнең берсе. Шигырь язучылар күп дибез, аларның язганнары, шигырь булудан бигрәк, шигъри парчаны хәтерләтәләр. Поэма кебек фикер киңлеген сораучы, күп көч таләп итә торган, чиксез иҗат потенциалы барлыкны раслаучы жанрга егетләр эше дип караучылар бар иде. Инде хәзер андыйлар да сирәгәя. Әлфия Ситдыйкова – дистәдән артык поэма язган шагыйрә. Лирик-фәлсәфи стильдә, озын тезмәләр түгел, ә конкрет сюжетлы, гомумиләштерүләр белән, образ-персонажларның эш-гамәлләрен күрсәтеп, төрле символ, сурәтлелектә лирик накалны югалтмыйча, тасвирда эздән чыкмыйча, нык кул белән эпик планда язылган әсәрләр алар. Шагыйрә сәяхәт итәргә ярата. Шуның нәтиҗәсе буларак, татар поэзиясенең офыгын киңәйтерлек яңа әсәрләр туган. «Абай илендә», «Кырым көндәлекләре» кебек әсәрләрен күз алдымда тотып әйтүем. Ул һәр әсәрендә укучыны күз уңында тота, һәр шигыре, поэма, балладасы укучы белән сөйләшү төсмерен ала. Шуңа күрә дә шагыйрәнең күңел дулкыны укучыныкы белән тәңгәл киләдер. Төрле очрашуларда аның шигырьләрен яратып тыңлыйлар, китапларын сорыйлар. Иҗат кешесенең бәхете менә шул инде.

*2016 ел.*

**Фәйрүзә ХӘЙДӘРОВА-ҖАББАРОВА,**
*китапханәче*

# «Йөрәгемә яфрак сыена»

Әле менә шушы көннәрдә генә кулыма бер шигырьләр җыентыгы килеп керде. «Йөрәгемә яфрак сыена». Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова үзенең китабын әнә шулай исемләгән. Китапның тышлыгыннан дустанә, мөлаем, җылы карашлы көләч Әлфия үзе елмаеп карап тора.

Китапның бизәлеше үк күңелдә матур, җылы хисләр уята. Яшел фон, төсләр гаммасы уңышлы гына кебек... Укучыны шунда ук үзенә җәлеп итә һәм китапның башка битләрен дә ачып карыйсы килә, ниндидер серле дөнья үзенә дәшә кебек. Менә китапның титул бите... Рәсеме матур гына, бик романтик. Күңелдә матур уйлар артканнан-арта. Китапның алдагы битенә дә бармагымны куям, ачам, укыйм. Рәшит абый Бәшәр аңа бик эчтәлекле итеп сүз башы язган.

Кем ничек укыйдыр китапны? Ә мин, китапханәче гадәтем беләнме, башта китапның соңгы битләрен ачам... Бу матур китапны эшләүдә тагы кемнәр көч куйды икән, нинди осталар, рәссамнар кулыннан үтте икән? – дим.

Макет остасы һәм рәссам-бизәүче Наил Хөрмәтов китапны бөртекләп, җиренә җиткереп, тырышып эшләгән.

Китап дүрт бүлектән тора. Бүлек рәсемнәре дә бик уңышлы гына килеп чыккан.

Китап «Хисләрем канаты» дигән шигырь белән башланып китә. Бу шигырь юллары үзеннән-үзе мине көйгә салыгыз әле дигәндәй җырлап тора. Гомумән, Әлфиянең күп кенә шигырьләре – җыр текстлары дип әйтер идем мин. Аның кайбер шигырьләренә көйләр язылган да инде – Флүрә Талипова аның шигырьләрен көйгә салып, аларга икенче сулыш өргән.

Әлфиянең тематикасы күптөрле. Бер тема да аны читләтеп үтмәгән. Күңелендә берәмтекләп җыелган моңнарын, сагышларын, шатлыкларын ул шигырь итеп ак кәгазь битенә күчерә барган. Әниләр темасы... Үзенең әнисенә багышланган «Тимә, сагыш» шигыре әнә шундыйлардан берсе. Ул бит әле үзе дә әни – бер кыз, бер ул үстерә. «Кызым Зөлфиягә», «Улыма хат» шигырьләре үзенең кадерле кешеләренә багышлап язылганнар.

Бу дөньяда барган мәгънәсез сугыш хакында, барлык аналарның йөрәген сызлаткан, улларын-газизләрен югалткан аналарга багышлап язылган «Җавап эзлим» шигыре дә бик эчтәлекле, гыйбрәтле. Шулай да мин Әлфияне мәхәббәт шагыйрәсе дип әйтер идем, чөнки аның бик күп шигырьләре мәхәббәт турында. Әлфиянең лирик герое – дөньяга, кешеләргә, табигатькә, җир-анага гашыйк кеше. Аның шигырьләре гади тел белән, аңлаешлы, көйле, җылы, эчкерсез язылган. Купшылык, ясалмалылык юк аларда.

Менә шулай бик җылы тәэсирләр калдырды Әлфиянең шигырьләре. Тагы да матур-матур шигырьләр, җырлар көтәбез.

*2003 ел.*

**Рәдиф ГАТАШ,**
*шагыйрь, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

## Шигырь күзләрендә сөю һәм наз...

Шигырь язучы хатын-кызлар күп, ә шагыйрәләр – аз, диләр.

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкованы исә мин тиз кабул иттем: бөтенләе белән җаныма якын иттем дип тә әйтә алам. Нигәме? Үзем дә аңлата алмаслык бер ышаныч, ягымлылык, наз тулы дөньяга теләктәшлек, иш күреп үз итү, шагыйрәнең ихлас хисләренә, табигатьнең үзе кебек саф, садә сүзләренә кушыласы килү, туган җиргә, кешеләргә һич бетмәс-үтмәс мәхәббәте белән күңелдә кабат үзем дә яңару кебек кичереш-халәт белән очраштым мин. «Җанда кабынган учак» та, «Йөрәгемә яфрак сыена» (китап исемнәре дә нинди ягымлы, җанга ятышлы бит!) исемлесе дә минем әйбәт шигырьдән һич тә туймаган, гел сусаган җаныма бер тансык сусын – сут булып ятты, дия алам.

«Бер җылы сүз» һәм «Өр-яңа котлаулар» кебек, «специфик» характердагы «массаларга аталган» китаплары да шагыйрәнең тулаем күңелдә туган матур сурәтен һич тә үзгәртмәде; юк, киресенчә, тормышчан бер нечкә аһәң-наз, нәкъ менә хатын-кызга гына хас бер яктылык, кайгыртучан җылылык, ярату белән өретелгән ак күңел, дога-фатихалар тулы милли җан-калеб иясен тулыландырып күрсәтте бугай.

«Вөждан күзләре» дип аталган кульязмасында да Әлфия ханымның мөлаем портреты шулай җанлана: кешеләргә ак теләкләр белән җылы сүз иясе – шагыйрә биредә дә үзенә тугры: шигыренең күзләре мөлдерәмә, алар – сөю белән тулы, алар наз, вәгъдә, бәхет көтүдән аз гына сагыш белән каймаланган, әмма анда – мәхәббәт, сүрелмәс, кимемәс ялкын, мәңгелек Сөю уты... Йә, шул күзләр карашы алдында эчендә шагыйрь җаны – вөҗданы булган кеше ничек тыныч калыр? Уйландыра, уята, уйда яндырып «уйдыра» мине бу «вөждан күзләре»; билләһи, бу шулай...

Әлфия – Актаныш төбәге, Күҗәкә авылы кызы. Пучы мәктәбен тәмамлаган. Аннан соңгы тормышы Чаллы белән бәйләнгән. Һәм, «Күңел» радиосы белән! Табигый да: шагыйрәнең күңеле язганнарында шәрран яра ачык бит, һәм, шунда аның хисләр, хыяллар биографиясе... Һәм, шулай дип әйтергә яраса, язмышлар яры, «мәхәббәт географиясе» дә! Барсы да үзен үстергән матур табигатьле, бик күп талантлы кешеләр бишеге – Актаныш белән бәйләнгән. Аның авыллары, елга-чишмәләре, урман-кырлары белән... Шул як Кояшы, ае белән туган аның шигырьләре, аларда – гөлләрнең хуш исе, әрем тәме катнаш моң һәм бабайлар васыять иткән туган туфракка тугрылык, нигезне изге санау кебек әдәп-әхлак иманы, мәңгелек Моң... Менә нинди ул Актаныш ягында канатланган шигъри күңел тәрбиясе! Һәм мин, бу якларның күптәнге гашыйгы, һәр яңа талантка хәерхаһ булган якташ шагыйрь – яңадан бу дөнья белән очрашып әсәрләндем, гүяки хисләремдә яшәрдем. Ихласлыкның әнә шундый көче бар, туган телнең шулай тетрәндерә торган сихри тибрәнешләре, моң-аһәңнәре бар. Көен генә боза күрмәсеннәр, тупас куллар белән генә кагылмасыннар. Яшермим, Әлфиябездә тормышның – «быт»ка якын күренешләрен шигырь итәсе килеп, проза белән очрашкан моментлары да очрый, кабатланулар да... Бөтен авыл атамаларын да җыр итү теләге дә сизелеп куя... Әмма тулаем күңел эзләнүләрендә ул әнә шул ихлас җыр-моң белән еш кавыша.., үзе дә сизмәстән, канатлана, оча, яңача яңгырый ала. Димәк, шагыйрәдә – җырга якынлык табигый рәвеш тә бар, ул – көй сорап яши, дәвам итә. Шул юлга тугры булуын теләргә генә кала. Тумыштан ярату, мәхәббәтне олылау сәләтенә ия Әлфия бу изге хискә ышанычын мәңге югалтмас дип уйлыйм. Ышаныч – шигырьнең һәрчак Вөжданлы, Сөю уты янган күзләре... Якты күзләр ул!

Яз, шагыйрә, ян, үзең булып кал!

*2005 ел, декабрь.*

# Ләйләләр телгә килсә...

Бу китап – минем уемча, гадәти булмаган, яңа, бер тыннан язылган – шикләнми әйтәм – бер сулыштан укыла торган мәхәббәт китабы, җан эзләнүләре китабы. Әйе, назга сусаган нәфис җанның ихлас якты хисләрен, хыялларын каләм-кәгазьгә ышанып тапшыруы ул! Ә каләм инде, Кандалый бабабыз язганча, «фаш итсә бөтен галәмгә?». Шулай, ихтыярсыз сокланып, исең китеп карыйсың эчкерсез, яшерен хисләрен бар дөньяга, курыкмыйча, шәрран-яра белдерерлек көчләр тапкан олуг хисләр иясенә, алдаусыз күңел эзләнүләренә... «Гадәти булмаган», дигәнебезне дә бераз шәрехләп үтик. Чыннан да, бу китап (ә ул шигъри юнәлеше буенча тәкълид китабы бугай) ниндидер бер реаль яшәү, җир чынлыгы яки конкрет мәхәббәт тарихы түгел, ә бәлки нәкъ менә идеал булырлык сөю эзләгән хатын-кыз җанының гаҗәеп серле, без белмәгән сихри, чиксез көче чагылышы ул. Аңлатыбрак әйтсәк, китап – бер замандаш чал шагыйрьнең «яшь» мәхәббәтнамәсенә – сайланма хисләр романына юлыгып, аны тирән кичереп укып, лирик геройны чын хатын-кызларча, йөрәк белән аңлап, иш итеп, аның лирик герое – «Мәҗнүн»енә яңа «Ләйлә»нең читтән язган хатлары, каләмдәшенә үз җенесе исеменнән еллар аша җавабы...

Башкалар җанына тирән үтеп кереп, аңлап, кушылып яну һәм эчкерсез саф хисләрдән матур тәкълид китабы тудыру өчен Шигъриятне, Кешеләрне, башка Каләм ияләрен югары кимәлдә ярату талантың булу кирәктер, мөгаен. Бу – сирәк йөрәкләр бәхете.

Шигырь тарихында шагыйрьләрнең шагыйрәләргә багышлап сөюнамәләр язуы табигый хәл булган. Яки, киресенчә, шагыйрәләрнең бу мәсьәләдә «активлыгы» (Ахматова, Цветаева исемнәре хәтергә килә). Ә бездә? Ләйләләр авазы күптәнме әле яңгыраш алган? Уйлыйк... Үз замандашларыбыздан бик әйбәт шагыйрәләребезнең, әйтик, С. Сөләйманова, К. Булатова, Л. Шагыйрьҗан, яшьләребездән Л. Янсуарларның мәгълүм цикллары, мәхәббәт шәлкемнәре (поэмалары) уемда җанлана. Әйе, андый ихлас йөрәк дәфтәрләренә бүген дә еш юлыгабыз! Ләйләләр күптән безгә тиң бу бабта...

Әй, хатын-кыз атлы илаһи да һәм җир баласы да булган, мәңгелек сер, и үзең үк шигырь – җырдай тетрәндергән нәфислек, гүзәллек дөньясы!

Син – халкың өчен тарихи әрнүләрне милли гамь касәсеннән даими эчеп тә барыбер горур исемеңне саклап киләсең. Өстәвенә ир-атларның (шагыйрьләрне әйтүем) чуар йөрәген дә аңлап, хәтта аңа кушылып, бер җанга әверелеп, үз булып яши алу халәтенә ия бит син, Хауабыз таифәсе! Бу үзе үк, хатын-кыз дигән олуг затның матурлык белән бергә дөньяны саклау, яшәтү, дәвам итү миссиясе түгелмени?

Чаллыда яшәүче шагыйрәбез, инде берничә җыентыгы булган Әлфия ханым Ситдыйкова да моны яхшы беләдер. «Назга сусау» исемле бу яңа китабы кулъязмасы әнә шундый сөенечле хисләр уятты. Башкалар да моңа кушылыр дип ышанам мин.

*2006 ел.*

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,**
*язучы, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе*

# Иҗатында язмыш бар

## *(«Туган якның ике чишмәсе» – «Два родника родной земли» китабына сүз башы)*

Миңа үз гомеремдә бик күп шагыйрьләрнең олы әдәбият мәйданына чыккан мизгелләрен күрергә туры килде. Әмма араларында: *«Мин бәхетне эчәм бүген / Кушып кыргый балга»*, – дип, кайнап торган тормыш, дөресрәге, язмыш эченнән калыккан каләм ияләре сирәк булгандыр. Әлфия Ситдыйкова – әнә шундый шагыйрьләрдән. Аның өчен иҗат язмыш кебек, мәхәббәт кебек – бер ачы да бер татлы:

*Учымда төн. Ак кәгазьгә*
*Тама илһам тамчысы.*
*Бөтен җанны айкап ала*
*И бу илһам ачысы!*

Билгеле инде: шагыйрь каяндыр көч алып яшәргә тиеш. Аның бу көч-егәрлекне бирердәй табигый һәм рухи чыганаклары булыр-

га тиеш. Әлфия Ситдыйкова өчен ТУГАН ЯК – шундый чыганакларның берсе:

*Әрем исе, татлы сагыш булып,*
*Күңелемә кереп урын ала.*
*Бертуктамый бәллүр бишегеңдә*
*Тирбәләм мин – һаман сабый бала.*

Туган җир – шагыйрә өчен матур сүз яки хатирә генә түгел. Аның өчен туган җир – сихри көч тә: *«Һавадагы сөт исеннән / Күк исереп йолдыз ата»*, кендек әбиләрнең изге догасы да, аналарның таң җиледәй йомшак кулы да, кояш яктысын капларга тырышкан *«кара хәбәр»* дә, *«күңел түреннән шытып чыгып, хәтер каберенә тамган гөлләр»* дә, *«йөрәк тулы зәңгәр моңнар»* да, *«канатларын кагып, мәңгелеккә таулар ягына очып киткән бөркет»* тә, су баса дип күчерелгән күрше авыл шәүләсе дә...

Яшәү өчен, димәк, иҗат өчен дә, иң күп көчне шагыйрь СӨЮ-МӘХӘББӘТтән ала. Шулкадәрле үк аңа бирә дә. Дөресен генә әйткәндә, аның бөтен яшәеше мәхәббәттән, иҗаты сөюдән тора. Ул мәхәббәттә яшәми дә кебек, ул анда яна, дөрли... Аның бу халәтендә мәхәббәт белән иҗат, кавышу белән аерылышу, бәхет белән сагыш бергә яши:

*Тезелде сүзләр кәгазьгә,*
*Киткәндә синең яннан.*
*Үзем китеп барсам да бит,*
*Җан белән синдә калам!..*

Әлфия – шагыйрәнең сөюе чын шагыйрьләрчә. Ул язмыш ихтыярына буйсынып яшәүче, бары тик яздан, наздан гына торган җан түгел. Аның тынгысызлыгына һәм дуамал дәртенә бер генә сөю дә аз, ләкин ул һәр сөю саен сафлана, яктыра гына бара. Шуңа күрәдерме, аның гыйшкы бүтән беркемнекенә дә охшамаган:

*Кыргый идем, тансык идем,*
*Көткәнеңне белдем.*
*Үз-үземнән оялсам да,*
*Бүген сиңа килдем.*

Шагыйрәнең яшәеше, иҗаты өчен тагын бер чыганак – тирәяктагы кешеләр. Ул кешеләр тудырган дөнья. Бу дөньяда шатлык

та, сагыш та гаять күп, өмет белән өметсезлек тә җитәрлек... Боларның барысы да бер сүз белән МОҢ дип атала:

*Кем ярасын кем дәвалар,*
*Җанга тоташ моң тулгач?*
*Җиргә килгән һәрбер кеше*
*Ул – яралы сандугач...*

Шагыйрә яши, иҗат итә. Ул шулай язмыш тудыра. Бу язмыш юлы көзгә якынлашып килсә дә, ул яшьлек дәртен, хыял-омтылышларын саклап кала белә. Бу яклап Әлфия Ситдыйкованың шагыйрьлеге тагын бер мәртәбә сынала кебек:

*Гомер үткән, көзгә кереп барам,*
*Чык тамчысы минем күзләрдә.*
*Бала чакның якты ал кояшы,*
*Төсле күбәләкле ямьле җәе*
*Озата бара алтын көзләргә...*

Әйе, чын шагыйрьлекне сынап карауның бер генә юлы мәгълүм: бу каләм иясенең әсәрләрендә тормыш гаме, яшәү мәгънәсе бармы? Һич икеләнмичә әйтергә мөмкин: Әлфия Ситдыйкованың шигырьләрендә чын мәгънәсендә гомер һәм язмыш кичерәсең, яшисең. Чөнки тоясың: гүя аларда кешелекнең бөтен борчу-гаме, хыял-омтылышлары, иң мөһиме, олы мәхәббәте тупланган.

Әлбәттә инде, камиллекнең чиге юк. Шигъри осталыкка, образлылыкка, поэтик тоемчанлыкка өйрәнәсе дә, өйрәнәсе әле. Камиллеккә омтылу да чын шагыйрьләр халәте. Әлфия Ситдыйкова иҗатында бу үсеш күзгә күренеп тора: шигырьдән-шигырьгә, фикердән-фикергә, хистән-хискә ул өлгерә бара. Үсә, камилләшә, әмма беренче шигырьләреннән үк тапкан төп хисне – шигърияtne шигърият иткән тойгыны югалтмый, аның бер тамчысын да түкми-чәчми саклап кала белә:

*Инәдән җеп үткәргәндәй,*
*Сагышларда җанны сыныйм!*

Әйдәгез, тормышка, яшәешкә үтә дә сизгер шагыйрә иҗатына ак юл, якты сагыш телик! Калганы – язмыш мәсьәләсе...

*2007 ел.*

**Сирень ЯКУПОВА,**
*шагыйрә, Саҗидә Сөләйманова*
*исемендәге әдәби премия лауреаты*

# Тугандыр ул моңга уралып

*Хушлаштың да китеп бардың,*
*Аерылу авыр бит...*
*Күзләреңнең нурын*
*Йөрәгемә салыйм,*
*Тукта, дустым, сабыр ит!*

Шау-шулы, ис-төтеннән зәп-зәңгәр завод цехында минем, егерме яшьлек авыл кызының, йотлыгып, әсәрләнеп шушы искиткеч моңлы җырны тыңлап утыруым хәтеремдә. Җырлаучысы – хезмәттәшем, үзем кебек гади авыл егете Мирзаһит. Хәер, үзәкләрне өзәрлек моңы күпме вакыттан соң да колагымда яңгырап торырлык булгач, бу илаһи тавыш иясен гади егет кенә дип атау дөрес булмастыр. Ул – туган җире чишмәләренең чыңын, кырлар-урманнарының шавын, чәчәкле болыннарының хуш исен түкми-чәчми күңелендә йөртүче һәм дә аларны, моңга төреп, минем кебек олы калага килеп адашкан җаннарның сагынудан саргайган йөрәкләренә шифалы бәлзәм итеп ягучы тылсымчы булгандыр, мөгаен...

Кем уйлаган, чирек гасырдан соң язмыш мине шул тылсымчының бертуган апасы белән очраштырыр да кабат, яшь чагымдагыдай, моң чоңгылында бөтерелергә мәҗбүр итәр дип? Чыннан да, шагыйрә Әлфия Ситдыйкова белән танышкан көннән алып, минем күңел иксез-чиксез шигърият диңгезендә йөзүче корабны хәтерләтә. Моң, хис, наз тулы сүз-дулкыннар уйнап торган ул диңгезгә карап, ирексездән, бу могҗизаның чишмә башы кайда икән, дип уйлыйсың. Уйлап та өлгермисең, серле дулкынннар, күңеләңә сак кына кагылып, соравыңа җавап та пышылдый:

*Мин дөньяга туган чагымда ук*
*Туганмындыр моңга уралып...*

*Сандугачлар моңы сеңгән талдан*
*Әткәй үргән миңа бишекне...*

*Кичке уен, Сабантуйлар күрке,*
*Моң чишмәсе әнкәй тавышы...*

Әйе, шулайдыр. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Тик Әлфия шигъриятенең ярсып дулаган, давыллы чакларын да күргәнем бар минем. Бу халәте нидән икән соң?

Бу юлы дулкыннар җавапны пышылдап түгел, ә замана ярларына кага-кага, күкләргә аша-аша, бар галәм ишетерлек итеп кычкыра:

*Кешелекнең кулларында*
*Җир-ананың җаны көйри!*

*Сулар һава җитми, оя тузган,*
*Ничек түзсен бөркет кайгыга?..*

*Илен, динен, үз милләтен саткан*
*Аңлыймы соң?!*

...Күңел корабым сабыр гына гамь дәрьясының тынычланганын көтә. Һәм шәфәкъ нурларында алсу мәрҗәндәй җемелдәгән дулкын-бишектә янәдән дә җай гына тирбәлә башлый. Инде мәңгелек Сөю көенә:

*Сызылып аткан таңга охшап җанда*
*Сөю туып килә...*

*...Юк, тезләнмә минем алларымда,*
*Мин тезләнеп үбим җаныңны...*

*...Үлемне дә җиңеп, йолдыз булып,*
*Кабынырмын кабат синең өчен...*

Синең өчен... Синең өчен... Сөю өчен... Колакларда, әй лә, йөрәкләрдә татлы кайтаваз булып яңгырап торган бу аһәңнән бар дөнья яктыра. Өмет җилкәннәрен киереп искән бәхет җиле кагылудан, йөзләрдә серле елмаю уйный...

Бу әле минем Әлфия Ситдыйкова тудырган шигърият диңгезендә үткәргән берничә мизгелем генә. Ә ул диңгез, әйткәнемчә,

иксез-чиксез, гаҗәеп бай һәм тирән. Иң сөендергәне – һәр күңелгә, һәр татар җанына аның киңлекләре ачык. Дөрестән дә:

*Йодрык кадәрле йөрәккә*
*Диңгезләр сыя икән.*

Шагыйрә йөрәгенә бигрәк тә...

*2007 ел, август.*

**Мансур САФИН,**
*писатель, лауреат премии имени*
*Шайхи Маннура, Эдуарда Касимова*

# Рекомендация

Талантливую татарскую поэтессу Альфию Ситдикову знаю с 1970-1980-х годов по совместным занятиям в городском литературном объединении «Лейсан» и участию в камазовских литературно-музыкальных вечерах. Я, будучи руководителем Набережночелнинского Бюро пропаганды художественной литературы Союза писателей ТАССР, всегда находил понимание с её стороны и радовался её активному участию в творческих встречах, проводимых с горожанами и жителями сельских районов Нижнего Прикамья. Уже тогда её стихи с любовью воспринимались читателями и слушателями.

Первые стихотворения А.Ситдиковой были опубликованы в ноябре 1977 года в газете «Кама таңнары» («Камские зори»), а затем и в других изданиях Набережных Челнов и Казани. Именно в те годы я обратил внимание на её стихи и, став первым их переводчиком на русский язык, сделал первые подборки произведений Альфии.

Первая книга стихотворений поэтессы «Йөрәгемә яфрак сыена» («Листок льнёт к сердцу моему») увидела свет в 2003 году в Автограде и пришлось по душе татарским читателям. Ныне она – автор десяти книг стихов и поэм. Стихи глубоко лиричны и полны философского содержания:

*Соловью – гнездо, любовь – поэту*
*Надобны, чтоб жизнь была светла.*
*Воду родниковую пьёт ветер*
*Из ладоней вешнего тепла.*
*Кто кого поймёт, да кто излечит?*
*Чаша грусти всё полней...больней...*
*Каждый человек на этом свете –*
*Раненный судьбою соловей.*

*(Здесь и далее переводы М. Сафина)*

Стихам А. Ситдиковой характерна яркая метафоричность, которая завораживает и влюбляет в себя читателя:

*Ты, любимый – неспетая песня.*
*Вместе ль музыку к ней писать?*
*Полюби меня бабочкой вечной,*
*Сев на вешнего сердца цветок.*

Поэтесса, как и положено ей, живёт тревогами и заботами, надеждами и радостями своих современников:

*От нежности жаркой тает душа.*
*Солнца камче, мир, доверься! –*
*Жемчугом Счастья блеснув, чуть дрожа,*
*Капля любви вошла в сердце.*

Альфия Мирзануровна не толко лирик, но и поэт-песенник, автор более двадцати песен, многие их которых стали популярными.

Учитывая то, что Альфия Ситдикова постоянно работает над совершенствованием своего творческого мастерства и занимает активную жизненную позицию, считаю, что она достойна быть членом профессионального Союза писателей.

*Для вступления в профессиональный Союз писателей.*
*2007 года, 11 сентября.*

**Николай АЛЕШКОВ,**
*поэт, лауреат республиканской*
*литературной премии имени Г. Державина*

# Где живёт счастье

Со страниц этой книги две женщины, две поэтессы проникновенно говорят нам о том, что счастье живёт в душе. И не надо спрашивать, из чего складывается женское счастье. Конечно, из любви. Но легко ли душа обретает любовь?

*Я пришла к тебе, прошагала века,*
*Я заблудилась в тебе... –*

говорит Лейла Меджнуну.

*В глаза твои взглянув, я забредаю*
*В глубь моря... –*

продолжает она. Какой же должна быть жажда любви, чтобы прошагать века? И оцените смелость женского сердца, его способность к самопожертвованию, ведь забрести в любовь, как в глубь моря, рискованно, ибо на море случаются девятибальные штормы.

Но все страдания и муки искупляются божественным светом взаимности, и тогда возникают признания, от которых суровому мужскому началу не устоять:

*Ты – мой светлый сегодняшний день,*
*Моё прошлое и грядущее..*

*Твой взгляд – душа, как факел, возгорит,*
*И в сердце вспыхнет отсыревший порох...*

Ох, уж эти обворожительные восточные мотивы! Хочется читать, не останавливаясь, хочется слушать и слушать признания из желанных уст – порох-то ведь и в тебе не отсырел, добытчик, защитник, муж и отец! Ответь огнём на огонь, видя:

*А по плечам тихо платье стекает,*
*Освобождая прекрасное тело!..*

Обо всём этом рассказывает своим читателям Альфия Ситдикова? Не менее страстно и взволнованно вторит ей Вера Хамидуллина? Она прослеживает женскую судьбу с момента рождения? Детство – это «край, где счастье безмятежно». Но в безмятежность и природа, и Творец вносят томление духа, ноту тревоги и смутного ожидания, постепенно подготавливая девочку к подвигу слияния с мужским началом, к подвигу материнства, к пониманию того, что «любовь – красивая мелодия!» Но не только это. К сожалению, и юная принцесса рано или поздно, но неизбежно переступит тот порог, за которым

*Осень раздевается красиво,*
*Сбрасывая золотой наряд!*
*Почему ж убого и тоскливо*
*Рощи обнажённые стоят?*

Быть готовой к этому – подвиг не меньший. Любовь иногда покидает своё жилище, и это – трагедия:

*Где-то там далеко-далеко,*
*Где-то там за дождями, снегами*
*Было сердцу тепло и легко,*
*Мы любви нашей песни слагали.*
*Но ушла в никуда чистота.*
*В закоулках ушедшего лета*
*Заблудилась любовь... А душа,*
*Словно нищий, в лохмотья одета.*

Но как катарсис, как очищение, есть и преодоление трагедии. И женщина, красивая, всё познавшая, уверенно завершает исповедь:

*Я судьбу благодарю,*
*Не ругаю, не корю.*
*У других бывает хуже.*
*Что, неправду говорю?..*

*Я друзей домой впущу,*
*Хлебом-солью угощу,*
*И, как нитку сквоз иголку,*
*Все печали протащу.*

*Будет светлой жизнь моя,*
*Как в ажуре кисея,*
*Дом мой будет полной чашей.*
*Будем вместе: ты и я...*

И несколько слов в заключение. Анна Ахматова когда-то воскликнула: «Я научила женщин говорить, // Но, Боже, как их замолчать заставить?» Конечно, в этих строках – добрая, лукавая ирония. Дескать, ничто не заставить! И – слава Богу! В женской поэзии есть особая мудрость – мудрость примирения двух основополагающих начал. Женская поэзия – это тот белый платок, которым жена или мать останавливают распрю, междоусобицу. Замечательно, что в нашем конкретном случае это понимают не только Вера Хамидуллина и Альфия Ситдикова, которых озарила прекрасная идея перевести стихи друг друга, но и издатели, выпустившие их замечательную книгу на двух государственных языках Республики Татарстан. Бик зур рахмат!

*2007 год.*

**Вахит ИМАМОВ,**
*язучы, Габдулла Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

# Тәкъдимнамә

Әлфия Ситдыйкованың исеме Чаллыдагы матбугат битләрендә әле 1980 еллар башында ук күренә башлаган иде. Әлфиянең тәүге шигырьләренә Кадыйр Сибгатуллинның да гашыйк булып йөргәнен, аңа киңәш-уңыш иткәннәрен хәтерлим. Ләкин, әллә шул гаилә мәшәкатьләре беләнме, әллә кыюлык-әрсезлек җитмәгәнме, Әлфия байтак еллар буена үзенең шигырьләрен мөстәкыйль җыентык итеп туплый алмый йөрде. Ниһаять, фәкать 2003 елда гына Әлфия Ситдыйкова Чаллыдагы КамАЗ типографиясе базасында төзелгән «Газета-китап нәшрияты»на үзенең тәүге җыентыгының кульъязмасын китереп бирде. Күренекле балалар язучысы Рәшит Бәшәр редакторлаган «Йөрәгемә яфрак сыена» дигән тәүге китабы шулай дөнья күрде.

*Сагыш чишмәләре безнең*
*Күңелгә коя икән.*
*Йодрык кадәрле йөрәккә*
*Диңгезләр сыя икән, –*

дип язган шигырь юллары әле үзләре үк Әлфиянең иҗат мөмкинлекләрен һәм иҗатының дәвамлы буласын кычкырып тора иде. Һич ялгышмаганбыз, озак көттермәстән, Әлфиянең «Җанда кабынган учак», «Хисләрем канаты – Күҗәкә», «Назга сусау» шикелле яңадан-яңа шигырьләр җыентыклары пәйда булды. Рәдиф Гаташ, Лилия Газизова, Сергей Малышев кебек шагыйрьләр дә Әлфия әсәрләренә, аның иҗатына мәхәббәтләрен белдерә башладылар.

2007 елда, кыюланып китеп, Әлфия үзе кебек үк Чаллы каласында яшәп рус телендә иҗат итүче Вера Хәмидуллина атлы шагыйрәнең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп каләмен чарлап күрсәтте. Әлфиянең Вера тарафыннан русчага, Вераның Әлфия тарафыннан татарчага тәрҗемә ителгән шигырьләре шул ук 2007

елда Татарстан китап нәшриятында «Туган якның ике чишмәсе» дигән исем астында аерым китап булып нәшер ителде. Сүз дә юк, һәр ике шагыйрәне дә илһам чишмәсе, шигърият чишмәсе дип тану иде бу.

Әлфиянең соңгы еллардагы иҗат активлыгы бик тә сокландыра. Шигъриятен әүвәл күбесенчә мәхәббәт шигырьләре һәм лирик хисләр белән генә башлап китсә, Аллага шөкер, Әлфия соңгы елларда милләтебезнең җиһандагы урыны, аналарга явыз сугыш китергән бәхетсезлек, яшь буынның киләчәк язмышы турында кайгырту-уфтану биеклегенә дә менеп җитте. Әлфиянең татар шигъриятендә Саҗидә Сөләйманова, Эльмира Шәрифуллина кебек шагыйрәләр биеклегенә җитүен һәм әдәбиятта фәкать ул үзе генә салган авазын ишетәсе килә. Алдагы шигърияте белән ул иҗат мөмкинлекләрен раслады. Киләчәгенә дә ышанам. Шуңа күрә, рәхәтләнеп, Әлфия якташыма Татарстан Язучылар берлегенә керү өчен тәкъдимнамә бирәм.

*2008 ел.*

**Нәҗибә САФИНА,**
*шагыйрә*

# Каршылык көчен буйсындыр!

«Җиргә килгән һәрбер татар ул – яралы сандугач», дип татарның инде ничә гасырлар буе читлектә әрнүенә ишарә ясыйсым килә. «Туган якның ике чишмәсе» китабын кулымнан төшермәгән идем әле, «Казан утлары»нда бер уч шигырьләрең килеп чыкты. Аларын да укып чыктым да уйларга чумдым. Алай гына да түгел, җаным туктаусыз бәргәләнә, хис вә акыл бәхәсләшә башлады. Ошбу халәтемнән качар өчен шигырьләреңне кабат-кабат укыдым да күңелемдә «каршылык көче» дигән фикер шытып чыгуын тойдым. Инде шушы фикерне ни тудырганын аңларга тырышам: бу очракта каршылык көче нидә? Кинәт күз алдыма шаулап аккан елганың каршылыкка очрап аягүрә чорына басуы дигән манзара пәйда була. Күпме еллар, гасырлар буе тыючы көч булып торган ярлар бер

мизгелдә җимерелеп төшә. Көчле агым юлына кешеләр тагы каршылыклар куя – тегермән, электр станцияләре. Кеше шулай каршылык көчен файдалана, үзенә хезмәт иттерә һәм... яши. Табигатьтә шулай. Ә без, безнең шигърият кайда, нинди көч чыганагы хисабына яши? Табигать кануннары колы булганга гына шигърият җанга мунча түгелмени? Димәк, һәр шагыйрь каршылык көчен үз файдасына эшләтә, хезмәт иттерә белергә тиеш.

Әлфия Ситдыйкова! Син бәлки: «Ни әйтергә тели соң бу Нәҗибә апа, кай тарафка борырга тырыша уй агымын?» – дип сәерсенеп тә калырсың. Тик мин әлегә синең шигъри дәрьяңда, шул дәрья дулкыны ихтыярында йөзеп йөрим. Шушы дулкын тәэсире тудырган уйларымны кәгазьгә генә төшерә барам. Тик синең шушы хатны укырга тиешле миннән яшьрәк шагыйрә икәнеңне истә тотып, шуны искәртеп куюны кирәк таптым: «Сезне тиргиләрме, мактыйлармы – сез моңа тулаем битараф булырга тиеш... Сездә язучы өчен иң мөһиме – талант, оригиналь фикерләү бар, бу сезгә үзегезне өйрәтүчеләрдән дә, хурлаучылардан да азат булып, бар рухи көчегезне иҗатка гына бирү өчен бик тә җиткән. Бернигә карамый, нинди бар, шундый булып калыгыз, һәм – ышаныгыз! – мактый башлаячаклар, әгәр сез үзегез теләсәгез, мактаячаклар». Болар заманында Максим Горькийның Вениамин Каверинга язган сүзләре. Күрәсең, алар миңа да тәэсир иткәннәр, мактау-хурлауларга, исемданга мин тулысы белән битараф. Минем өчен иң зур бүләк – җан агымының каршылыклардан да көч алып алга омтылуы. Әдәбиятта шундый көч чыганакларының иң зурысы – тәнкыйть. Тик шагыйрь өчен шундый көч чыганагы була алыр тәнкыйть бик тә нечкә тоемлауга нигезләнгән булырга тиеш. Өстәвенә, әдәби тәнкыйть (гади укучы мине гафу итсен) ул киң катлау укучы өчен түгел, ә әзерлекле әдәбият белгечләре, әдәбиятчылар өчен. Бүгенге көндә исә бездә популистик тәнкыйть чәчәк ата. Әзерлексез укучылар һәм гыйлеме җитмәгән, әдәбиятка үтеп барышлый гына күз салган галим язмалары чын әдәби тәнкыйтьне тәшкил итә алмый, һәм, әзерлексез укучы критерие дә чын бәя була алмый язучы әсәренә. Шуңа күрә «Иң күп укыла торган әсәр» бәйгеләрендә билгеләнгән әсәрләргә дә чын тәнкыйть үз бәясен бирергә тиеш.

Чү! Каршылык көчем, мине тиешле уй юлыма кайтар! Юкса мин әдәби әсәрне укыр өчен башта укучыны әзерләргә, бүгенге яшьләр буыныңың безнең әсәрләрне уку, аңлау мөмкинлегеннән мәхрүм икәнлеге турында сөйләп, без кем өчен язабыз соң, дип

тә сорарга мөмкинмен. Әлфия! Син әле андый сорауны куймыйсың. Син мәңгелек ямь эзлисең. Минем күңелдә каршылык көче фикер вулканын кузгата: булса иде шундый ямь – җанга әзер маяк. Мәңгелек ямь… Ай астында ачылмаган ни бар? Кул җитмәгән, уй җитмәгән йолдызлар һәм… шагыйрь җаны… Менә шундый уйлар синең «Рухи дөньям» шигыреңдәге соңгы куплетны алып ташлады да кул да, уй да җитмәс рухи дөнья, галәм шагыйрь күңеленә сокланып та, тетрәнеп тә бага. Шулай, без йолдызлы галәмгә баккан кеби. Бәхәсле уй агымыннан тагы бер тамчыны тотып алам да шул тамчы эчендәге дөньяга багам. Монысы – «Тормыш кырыслыгын тоеп» шигырендә: Сүзсез генә әрнеп, сызлап, Кайчак елый ирләр дә... Сыгылмыйлар: дөнья йөген Илтәсе бар үрләргә. Әйе. Шагыйрь, фәлсәфәче дә үзе ничек яшәве турында түгел, ә башкалар ничек яшәргә тиешлеге турында яза икән, үз заманы өчен генә түгел, мәңгелек өчен яза, мәңгелек юлыннан атлый икән, шулай – сыгылмыйлар. Яратканнар, яраталар. Яратырлар... Ә минем Йосыф-Зөләйха, Ләйлә-Мәҗнүннәрдән дә көчлерәк сөюне тоясым килә. Кеше белән бергә аның олы хисләре дә үсәргә, камилләшергә, көчлерәк булырга тиештер ич!? Андый гүзәллекнең хет чаткысын гына тотып алса да, шагыйрь җан кояшы белән яктыртып бар дөньяга күрсәтер иде. Ә Мөдәррис Әгъләм кебек: Бирегез миңа толпар, Кешеләр, ник дәшмисез?! Мәхәббәтне аңларга Әллә артык картмы сез, Әллә артык яшьме сез!? – дип өзгәләнер иде микән? Һәм син дә, заманаң да сине аңлар зат таба алсаң, Бары Дәрдмәнд аңлармыни минем хәлне? – дияр идеңме икән? «Татар даны» дип башланган шигырең дә әллә күпме уйлар агымын кузгатты. Әллә күпме шик, ачу купты сиңа. Юкса бары сабан туе турында гына язасың да бит... «Көрәшчеләр белән данлы илем», дисең. Ә минем җаным бу хыялның чигенүеннән әрнеп елый. Бил бирми ул татар көрәштә, – тагы шик, тагы шөбһә җанда. Җанымда тагы Мөдәррис Әгъләмнең: «Бирмә билеңне, бирмә билеңне», – дигән кисәтү өне яңгырый. Беләсеңме, Әлфия, бу шигырең чынлап та җанымны челпәрәмә китерде. Хакыйкать һәм хөрлек, Гаделлек, Моң Мәйдан тота татар илендә, – дисең. Ә минем: «Илеңдәме, әллә җаныңда гынамы? Мәйдан тотамы, әллә елап ятамы?» – дип сорыйсым килә. Син бит бүген яшисең, шагыйрә! Җан бәргәләнә дә, нидер җитми. Нидер алай түгел. Инде килеп, шулкадәр дә камил, һәр ике юлы әйтем булып китәрдәй «Сандугач» шигыренә дә бәйләнәм бит. Җиргә килгән һәрбер кеше Ул яралы сандугач... Аңладым, аңладым ник

бәргәләнүемне: мин каршылык көчен арттырырга омтылам, ахры. Җан шул максаттан агымның әле ярларын үзгәртергә, әле каршылыклар китереп куярга тырыша. Шул рәвешчә синең шигыреңне үзенә хезмәт иттерергә тели. Минем исә: Җиргә килгән һәрбер татар Ул – яралы сандугач, дип, татарның инде ничә гасырлар буе читлектә әрнүенә ишарә ясыйсым килә шул. Чөнки сусыз йөзәргә өйрәнү, йөзү бәйгеләрендә узулар бигрәкләр катлаулы бит...

Дөнья әдәбияты тарихында теоретиклар, әдәбият белгечләре гел көнкүрештән аерылып, әдәбиятны югары күтәрергә, фантастика-хыял ярдәмендә кешегә канат куярга омтылуны алга сөрәләр. Шулай булмыйча, без бит үләр өчен түгел, яшәр өчен, киләчәккә, мәңгелеккә барыр өчен кешегә, хыялга канат үстерер өчен язабыз ла. Тик язмыш озак еллар дәвамында минем янымда сәер «Сүзлек» китабы йөрткән икән. 1994 ел булса кирәк, Төркиядән шигырь бәйрәменә Көнуглы атлы шагыйрь килгән иде. Тукай-Кырлайда безнең белән бергә бәйрәм табынында утырды. Мөдәррис Әгъләм нәкь шул шагыйрьдән соң бәйрәм тосты әйтте һәм... мине гел-гел конкретлыкта тәнкыйтьләп торучы Мөдәррис үтә конкрет һәм һич кенә дә бәйрәмчә булмаган тост әйтте: «Синең белән минем арада бик мөһим аерма бар – сез дәүләтле шагыйрь, ә мин – дәүләтсез... ничек очыныйм. Бер генә нәрсәгә шөкер итәбез – җанны зинданга ябып булмый». Әлфия, син канат кую теориясен хәтта кирәгеннән артык та үзләштергәнсең, ахры. Милләтеңне хыял канаты җиленә ияртергә теләү – бу шагыйрь өчен төп сыйфаттыр.Үз укучыңа бару юлларын да икеләтә көч куеп эзләү юлына баскансың. Рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләрең дә җаннарга юл алса иде. Шулай дим дә, Равил Фәйзуллинның инде яшьлегендә үк әйткән һәм җаныма бер дә чыкмаска дип кереп урнашкан сүзләре мине көйдереп ала: «...Җанны тәрҗемә итеп булмый...». Тагы уй агымы... кеше башта кемлеген үз-үзенә, аннары үзен тудырган, телле иткән милләтенә исбат итәргә тиештер. Танысалар да, сине шул кеше, шул милләт баласы дип таныячаклар бит. Юкса мәңгелеккә бер үзеңне генә алып китә торган шагыйрь кемгә кирәк!» Теге яки бу милләт, аның теле түбән, кирәкми, диләр икән, моннан да түбән фикер була алмый. Алтынны ни тирәндә, ни түбәндә ятса да, эзләп табалар. Йолдызлар ни биектә, ни еракта булса да, аларга багалар. Омтылалар. Туган телебезне тел шомартып ялтыратыйк, кояш итеп балкытыйк. Шулай булса, тарих та эзләп табачак. Мәңгелек күзләре дә багачак аңа. Безнең уй-хис, рухи дәрьябыз ярлары төрки

дөнья бит. Дөньяга шул ярлар буйлап та агып чыгуның табигый юл булуын кем инкяр итәр? Шул дәрьяга керү, аларны уку, белү, кушылу кирәк безгә. Әлфия, син мин теләгән теләкләрне үзең үк шигырь юлларыңда әйтеп бирәсең бит: Урын тапмый шашкын җаным, (шашкан түгел. – Н.С.) Очса читлегеннән, Рухым табар сине танып Тарих битләреннән. Ә тәрҗемәсе ничек яңгырый: И места не найдет душа, Из клетки улетая. Найду следы твои, судьбы Историю листая. Әйе, киләчәк сине танысын дисәң, үзең булып яшәргә кирәк шул. Әнә бит без Идегәйләрне таныйбыз: Гасырларны кичеп Идегәйләр Идел-йортны барлап эндәшә, – син шуны ишетәсең. Тик ни өчендер «Җир пакьлеге, ил аклыгы өчен» дигән билгесез, адрессыз сүзләр белән шигъри сүзне бозып куясың. Бәлки алар башкача язылган булгандыр, бәлки «Җан пакьлеге һәм хакыйкать өчен» булгандыр? Бәлки, бәлки. Тик ничек кенә булмасын, шигърияткә бер генә әдәби жанрның да үрелеп сугары юк. Шигъри сүз гадилеге белән – җирдә, галилеге белән – галәмдә. Аны иелә белмәгәннәр дә, оча алмаганнар да танымас. Шигырь – ул һәрчак кешегә бәхет юлламасы. Җирдә бәхетлеләр арткан саен иҗатчылар да арта барачак. Әлфия! Синең шигырьләрең дә сөю бәхетеннән шытканнар. Тик минем җан бәргәләнүем дә шуны аңлаудан икәненә төшендем: милләтеңне бәхетле итми торып, сиңа чын бәхет тәтемәячәк шул. Бәхет, чын иҗат бәхете – милләтеңне киләчәккә илтүче шагыйрә булуыңны телим.

*2008 ел, 16 май.*

**Айдар ХӘЛИМ,**
*язучы, Гаяз Исхакый исемендәге*
*әдәби премия лауреаты*

# Сабантуйга кайткач...

Нигә кайткач, дидем мин үз-үземә, нигә «кайткач?» Китмичә калып булмый идемени соң?

Әлфия Ситдыйкованың «Яшәр өчен килдем» дигән парчалар җыентыгының кулъязмасын укып чыккач, мин шушы гыйбарәне кабатладым. «Яшәргә килдем» «яшәргә кайттым»га тиң булмаса да, бу җыентык миндә бүгенге авыл, аның бәрәкәтле туфрагы, эчкерсез, тырыш, җырлы-моңлы халкының киләчәге өчен өмет уятты. Их, сагынып җырлар җырлаганчы, «бәпкә үләнен сагынып, кемнәр юклар, кемнәр бар икәнен барлап», атна саен кайтып-китеп йөргәнче, без, авыл үстергән балалар, барыбыз да бердәм кузгалып, туган төякләребезгә кире кайтсак, тәрәзәләрдәге аркылы-торкылы кадакланган такталарны каерып җиргә орсак һәм алар белән мичләрне ягып җибәреп, ялт итеп утлар кабызсак, татар милләте җәһәт кенә терелеп китәр иде дә бит... Менә шундый моңсу сагыну, әрнеш минутлары бүләк итте миңа мондагы әсәрләр. Мин авторны моңа кадәр бик нечкә шагыйрә дип белә идем, баксаң, ул үзенчәлекле чәчмә әсәрләр дә яза икән. Хәер монда, жанр ягыннан чыгып караганда, вакыт-вакыт кайсының парча, кайсының нәсер, кайсының шигырь икәнен ачыклау да кыенга килә-дер. Миңа аларны аеру кирәкми дә. «Мин ышанам, әгәр дә җаны туңган кеше ул шигырьләрне кулына алып укыса, тансык назны табып, юаначак», – ди бит автор үзе дә нәкъ мине күз алдында тоткан кебек. Мин дә алардан наз алдым. Шуңа күрә дә барысын бербөтен сулыш итеп кабул иттем. Алар иҗтиһатта бергә үрелеп, авыл туфрагында тере тал булып яралган, кискән саен үсә торган бер гаҗәеп тал-җан булып тамыр җибәргән, «авыл белән җаны тоташкан», нииндидер нечкә хисле сабый кыз-бала, җиткән кыз, бала анасында гына була торган хиссияти аң белән сугарылган халәттә яшиләр.

«Инде балалар буйга үсеп җиткәч, ананың карашы үзгәрә. Сабырлык бөркелеп торган төпсез күзләрдә акыл, түземлелек, бор-

чылу белән бергә шатлык һәм бәхет нурлары уйный... («Күзләр»); «Хатын-кыз көзгедәге чагылышы белән гомер буе сөйләшә, киңәшә, бәхәсләшә...» («Көзге»); «Шәһәр җирендә биек-биек йортларда меңәрләгән тәрәзә, меңәрләгән язмыш пыяла аша дөнья белән сөйләшә. Авылдан килеп, туган җирне сагынып яшәүчеләр тәрәзәдән күзен алмый: танышын, авылдашын эзлиме, аңламассың...» («Тәрәзәләр»); «Кулына каурый каләм тотып дөнья буйлап сәфәр чыккан шагыйрь йөрәгендә мизгел саен вулкан тетрәмәсә, халык күңеленә тоташучы шигъри юллар тумас иде. Тетрәү көче йөрәк каны белән бизәп язган шигырь күзләрендә чагыла. Туган илен, үз милләтен җил-давылдан саклар өчен шигъри күңелен җилкән итеп, Гамь дәрьясын кичеп офыкка таба баручы шагыйрь җанын аңлыйбызмы соң без? Шагыйрь күңелен аңлар өчен шигырь күзендәге Моңны укый алу сәләтенә ия булырга кирәктер ул...» («Шагыйрь җаны»); «Яралы күңелдән җыр агыла. Әлеге җырның сүзләрен син яздырдың. Дөресен әйткәндә, синең хыянәтең белән очрашканнан соң туган җыр бу...» («Соң»); «Җәмгыятьтә барган үзгәрешләрнең җиле беренче булып авылларның җанына килеп кагылды. Су баса дип күчерелгән авылларның язмышы бүгенге көндә бетеп килгән авылларның язмышына тоташкан. Өстән килгән карарга буйсынып, төбе-тамыры белән урыныннан йолкынды авыллар. Нигезләре белән авыл җаны, зират җаны бергә кубарылды. Әйтерсең лә, авыл кыямәт көненә аяк басты...» («Аккош җырын илтик киләчәккә»).

Менә шундый сурәти ачышлар, тетрәткеч нәтиҗәләр тулып ята бу әдәбият фәнендә иң нечкә жанр атамасын алган алтмышлап парча-нәсер кергән кечкенә китапта. Теле бай, сыгылмалы, стиль дә табигатьнең үзе һәм кеше табигатенә тәңгәл килеп гади һәм катлаулы; ул кан агышына карап кына түгел, җил исешенә карап үзгәрә дә үзгәрә; лирик герой бик нечкә кичерүчән шәхес, ул тиз нәфрәтләнә, яралана һәм кичерә белә. Бер караганда, парча кебек «нәзекәй бил»нең бу кадәр гомумиләштерү авырлыгыннан биле дә сыгыладыр кебек. Аның көянтәсенә сөю генә кирәк, ә монда нәфрәт тә бар. Аңа гөлбакчалар гына кирәк, ә биредә, ясалма уңыш артыннан куып химик ашламадан корыган-кипкән, игенсез калган басулар да бар. Әйе, укучының, бу җәһәттән минем, тагын да тирәнгәрәк төшәсем, без югалткан югалтуларның социаль чирләрен ачасым, сәбәпләренә төшенәсем, гаделлекне кире кайтару өчен хәлиткеч көрәшкә чыгасым килә, әмма көянтә сыгыла-сыгы-

ла, аңа ун гына грамм йөк салсаң да, ул шартлап сынар сымак... Әмма хатын-кызның нәфис иңнәре болай да кирәгеннән артыгын күтәргән бит! Калганы безгә, ирләргә, калсын!.. Тукта, әгәр ирләребез дә сыекланып бөршәйгән булса, бу чакта нишләргә? Ирләрне бит, ничек кенә сәер тоелмасын, ир итеп үзләре түгел, аналар тәрбияли...

Менә шушы бугай инде минем бу китаптагы иң зур табышым. Нәфис, өрфия сынлы Әлфия сеңлем бу парчалар китабы белән киң үлчәмле, катлаулы прозага килеп, ирләр күтәрә алмас темаларны күтәрәчәгенә миндә зур ышаныч тудырды. Шигъриятеңне түкмичәчми, «чәчмә әсәрләргә» – прозага килүең белән котлыйм сине, Сеңлем!..

Моның өчен синдә кирәк булган бар байлыгың бар. Шул исәптән, проза тирәнлекләренә бораулап төшә ала торган алмаз бораулары бар. Иң мөһиме – милләтеңә булган үлемсез мәхәббәтең бар. Саф һәм тигез мәхәббәт барда татар авылы бетмәячәк. Ул инде беркая да китмәячәк, Алла боерса.

*2008 ел, 24 сентябрь.*

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
*Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең бүлек мөдире,*
*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре*

# «Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә...»

Әлфия Ситдыйкованың «Утлы җимеш» шигъри җыентыгы чын-чынлап яндыра, сихерләндерә, уйландыра. Китапны бер дулкында укып чыктым, бүленеп укысам, нәрсәсендер югалтырмын, җимешләрнең тәмен онытырмын кебек тоелды. Әгәр дә шагыйрәнең күңеле белән шигырь яратучы бер дулкында тирбәлеш алып, бер агымда йөзә икән, бу шигырьләр бәхетле. Аңа ул «утлы җимеш»ләрне татыйсы гына кала.

Шигырь кәгазь юлларына шагыйрәнең күңел халәте җимеше булып тама. Ул шул халәт агымында туа, үсә, үз укучысын таба. Шагыйрәнең күңеле моң, сөю, мәхәббәт белән тулы серле дөньядан безгә дәшә. Алай гына да түгел, күңеле аның гел чабышта:

*...Җитәкләшеп уздык бүген*
*Балачак урамыннан.*
*Күңел чапты бездән алда,*
*Бушанып тышавыннан.*

*«Җитәкләшеп уздык бүген...»*

Шуларга өстәп, һәр җанның мәхәббәт җимеше булып тууы хакында белдерә, дөньяга килүенең төп вазифасын искәрткән шигъри юллар тезә:

*...Мин сөюдән яралганмын,*
*Сөелер һәм сөяр өчен.*

*«Үлчәп булмый микъдарларда»*

Һәм ул, бу төшенчәне янәдән үстереп бара, сөю-назга сусап яшәвен дәлилли:

*...Мин сусаудан яралганмын, ахры,*
*Сусап яшим туган мизгелдән.*

*...Мин сөюдән яралганмын, ахры,*
*Сөю-назга сусый күңелем.*

*...Мин – мәңгелек сәфәрдәге юлчы,*
*Сөю эзләп үтә гомерем.*

*«Юлчы»*

Күңел эзләнүләре, уйлануларыннан шигъри тәлгәшләр булып тулыша:

*...Тели – кояш элеп куя*
*Яктыртырга күңел күген.*

*«Барыбыз да язмыш колы»*

Шигъри җан алдануын да аңлый, кайтып-кайтып үз-үзенә үкенү катыш сорауларын бирә. Менә ничекләр итеп:

*...Иеләм дә утлы күмер алам,*
*Алданасың нигә, әй, күңел?!*

*«Кызыктырып яна, дөрли учак»*

Шагыйрә күңеленең үзгәрүчәнлеген аңлап эш итә. Ул, күңел түрләренә үтәчәк сүзләрне «вак иләк» аша үткәреп, төрледән-төрле чагыштырулар китерә:

*Минем күңел көзге көнгә охшаш*
*Кояш, бер карасаң, елмая,*
*Минем күңел көзге урман төсле –*
*Яфрак коя җилләр искәндә.*
*Минем күңел тирән күлгә охшаш –*
*Тигез түгел күлнең өсләре.*

*«Минем күңел»*

Шул ук вакытта ул, матур чагыштырулар табып, назлы карашын яктылыкка юнәлтә:

*...Җылы назлар күңелемдә*
*Тыпыр-тыпыр кайта биеп.*

*«Йомшак куллар...»*

Шагыйрәнең күңеле чиста, самими, бер дә яшерми ачыктан-ачык, һәрбер нәрсәне ничек бар шулай әйтеп, шигъри юллар аша укучысы белән серләшә:

*...Күңел сандыгымны ачтым сезгә,*
*Йөрәгемдә ничә яра бар?*
*Сез хөкемдар бүген иҗатыма,*
*Бер җылы сүз бәлки дәвалар.*

*«Күңел»*

Күңеле сизгер, ул үзенең иҗатына булган җылы мөнәсәбәтне сизеп яши, шигъри сүзләр белән төгәл итеп җавабын да кайтара:

*...Күпме яраланган күңел*
*Төзәлде җылы сүздән.*

*«Күпме яраланган күңел...»*

Бу шигырьне укуны дәвам иткәндә шагыйрәнә күңелнең арфадан да нечкә булуын тоясың:

*...Күңел – арфа. Киерелеп-чыңлап*
*Өзелергә әзер һәр кылы.*

Шулай итеп, хөрмәтле укучым, шигъри күңелнең арфадай – нечкә кыллы булуын белеп сак кына, үз фикеремне җиткерергә теләп язмамны дәвам итәм.

«Утлы җимеш» җыентыгының кереш сүзендә мәртәбәле шагыйребез Рәдиф Гаташ болай яза: «Әлфия ханымның мөлаем портреты шулай җанлана: кешеләргә ак теләкләр белән җылы сүз иясе – шагыйрә биредә дә үзенә тугры: һәр шигыре сөю белән тулы, алар наз, вәгъдә, бәхет, бәхет көтүдән аз гына сагыш белән каймаланган, әмма анда – мәхәббәт, сүрелмәс, кимемәс ялкын, мәңгелек Сөю уты...» Ә үз чиратында, шагыйрә рәхмәт сүзләрен шигъри юлларга салып җиткерә:

*...Сүзләреңдә хаклык күрәм,*
*Рәхмәт сиңа, и Гашыйк җан!*
*Рәхмәт сиңа, Рәдиф Гаташ! –*

*«Мин дә күрдем сине, Шагыйрь»*

Мәхәббәт, Сөю уты. Инде аңлашыла, менә ни өчен шагыйрәнең күңеле әзләнүдә, чабышта икән. Сөю-мәхәббәт хисләре гади генә башланып китә, аннан, төрле төсмерләр алып үсә, баетыла, катлаулана бару белән дә очрашабыз. Мәсәлән, шагыйрәнең «Бала елый» шигырендә мәхәббәт җимеше булып туган баласыннан ваз кичкән ананың соңыннан шашынуы, акылдан язуы белән күзгә-күз очрашабыз. Мәхәббәт, Сөю уты яшәешебезнең асылын тәшкил итә. Әлфия бу шигъри җыентыгы ярдәмендә дөньяга, яшәешебезгә булган карашыбызны үзгәртергә, мәхәббәтле күзләр белән карарга дәшә. Ул, барыбыз өчен дә бик кирәкле, бәһале мөнәсәбәт турында кайгыртып, шигъри юллар тезә:

*Сөюем бар җанны җылытырга,*
*Җырларым бар халык өчен дә.*
*Сыенам мин асыл хакыйкатькә,*
*Бар бәхетем яшәү көчендә.*

*«Мин дөньям...»*

Әлфия, бер дә шикләнмичә, яшәү үзе бәхет икәнен дәлилли. Шул ук вакытта бик оста гына иттереп, укучы алдында үзенең гади генә теләген дә белдереп, акланып алу чарасын таба.

*...Мин үземне танытырга түгел*
*Таныр өчен өчен яшим дөньяда.*

*«Үз-үземне табар өчен күпме»*

Ул үзенең язмышка рәхмәтле булуын да әйтергә онытмый:

*...Рәхмәт, язмыш, каршылыклар белән*
*Сыныйсың син минем ныклыкны.*
*Җиңелү һәм җиңү барын аңлап*
*Чыныктырып яшим холыкны.*

*«Чыныгу»*

Җиңелүне аңлау, каршылыкларны сизү бәхете һәркемгә дә бирелми әле ул.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы шагыйрә Әлфия Мирзанур кызы Ситдыйкованың «Утлы җимеш» шигъри җыентыгында туган җиргә мәхәббәт, ил язмышы, яшәү мәгънәсе турында уйланулардан торган шигырьләре дә байтак.

*...Илен, динен, үз милләтен саткан*
*Аңлыймы соң күңел халәтен?!*
*Ә мин тиле, көтеп яшим җирдә*
*Сугар диеп шагыйрь сәгате.*

*«Бурычларым бик күп...»*

Шагыйрә Мәхәббәт илендә, Сөю диңгезендә тирбәлүен шигъри образлар аша сурәтли:

*...Син – тоташ наз, мин – тоташ моң,*
*Кабатланмый торган җыр.*
*...Син – тоташ наз, мин – тоташ моң,*
*Тирбәләм кочагыңда.*

*«Яныйк әле»*

Мәхәббәт, Сөю уты... Шигъри күңел генә шулай яна, дөрли, тирбәлә ала бугай.

*...Шагыйрь йөрәгендә мизгел саен*
*Тетрәп тора вулкан. –*

дип, тикмәгә язмый шагыйрә. Һәр шигырендә ташып чыккан күңел халәте яшәвен раслый:

*...Ак каләме язган шигырьләрендә*
*Яши шагыйрь җаны.*

*«Шагыйрь җаны»*

Кадерле укучым! Мәхәббәт, Сөю утына янәдән керәсең килә икән, йөз генә!

*Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә,*
*Әле ярый яңа сөю кошы*
*Дәвалады йөрәк ярамны.*

*«Әле ярый»*

Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә! Сине «Утлы җимеш» шигъри җыентыгы битләренә дәшәм. Рәхим ит!!!

*2014 ел.*

**Зәбир ХӘЛИМОВ,**
*ветеран укытучы*

# Утлы җимешләрдән авыз иттем

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкованы күптәннән беләм мин. Күҗәкә авылыннан ул. Аны белмәгәннәр Чаллыда сирәктер. «Күңел» радиосында эшләгәндә үк аны йомшак тавышыннан күпләр таный идек. Шул чорларда чыккан «Бер җылы сүз» дип аталган котлаулар китабын кулга да тигезми алып бетерделәр. Анда язылган шигырьләрне кемнәр генә үзенә багышланган дип уйламады микән? Нинди генә мәҗлесләрдә укылмагандыр алар?!

Шактый иртә әтисез калган, ике баласын ялгыз кеше иткән шагыйрәнең укучыларына әйтер мәгүзләре байтактыр. «Утлы җимеш» китабы тышлыгында сәйлән шикелле тезелгән миләш бөртекләре дә Әлфиянең язмышына ишарәдер сыман.

*Кызыктырып, ымсындырып*
*Торса да тәлгәшләре,*
*Әчесе җанга тия шул,*
*Әйтерсең күз яшьләре...*

Татарстан китап нәшриятында басылган бу җыентыктагы шигырьләрне кабат-кабат укыдым мин. Беренче итеп куелган «Мин дә каен» шигырендә генә дә күпме сурәтләү чаралары! Сынландыру, метафора, чагыштырулар...

*Көзгә керсәм, каен сыман*
*Сагышланам, моңланам.*
*Яфрак-яфрак көннәремне*
*Җилләр өзә еллардан...*

Әлфиянең 80нче елларда язылган иҗат җимешләрен дә укыганым бар. Аерма шактый. Бүгенгеләрендә инде шагыйрәнең сүз тәмен, дөнья гамен тирәнтен тоемлавы сизелеп тора. Авторның галәме киңәйгән, хисләре тирәнәйгән, күзләре үткенләнгән, теле

чарланган. Күңел күзе ачылган шагыйрә инде бар нәрсәне аңлый, маңгай күзе күреп бетермәгәнне дә күрә, тормышны вөҗдан күзләре бизмәненә салып үлчи. Ул шигърият дөньясын олы елга белән тиңли, ә үзен шул елгага коючы саф сулы инешкә охшата.

Шигърият дөньясында лаеклы урын алу өчен байтак гомер-йомгагын сүтәргә туры килгән аңа. Такташ күк «тал чыбыклары» да ашаган ул, көчекләр өрү-тешләвенә дә түзгән, йөрәгендәге яра-әрнүләрне җылы сүз белән дәваларга тырышкан.

*Күңел сандыгымны ачтым сезгә,*
*Йөрәгемдә ничә яра бар?*
*Сез хөкемдар бүген иҗатыма.*
*Бер җылы сүз, бәлки, дәвалар...*

Тормышның ачы-төчеләрен татып, очы-кырые күренмәгән каршылыкларны үтеп, үзенең ныклыгын сынаган өчен Илаһыга рәхмәтле булып сөенеп яши Әлфия. Кайнар утларда, салкын суларда чыныктырган язмышына да үпкәләми ул. Үзендә булган акылны, җылыны, изгелек-шәфкатьне ваклап-ваклап кешеләргә өләшә якташым. Юлчы булып бу җирдәге кешеләрнең хәлен белә, моңлыларның башыннан сыйпый, зарлыларны кочып юата... Яшен булып яшьни, давыл кошына әйләнеп сөйгәне күңеленә керә, аны җылытыйм дип ялкынга әверелә, ялгыз каен булып сагышлана, кораб булып тормыш диңгезендә йөзә. Әле сабый бала чагына кайтып туган якның бәллүр бишегендә тирбәлә, әле мәңге өзелмәс җыр булып кешеләр хәтерендә калырга тели Әлфия. Аңа барча хыялларның чынга ашуын гына телисе кала. Иҗат чишмәң саекмасын, дустым!

*2015 ел, февраль.*

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы*

# Чаллы шагыйрьләренең иҗат үзенчәлекләре

Әлфия Ситдыйкованың соңгы елларда проза өлкәсендә матур-матур әсәрләре дөнья күрде. Ике ел рәттән шигырь җыентыклары бастырып чыгаруы исә тиз, җиңел язуы турында сөйлидер, мөгаен. Дөрес, җыентыклар сыйфат ягыннан бер-берсеннән шактый аерыла. Беренче җыентыкта («Утлы җимеш» 2011) «өйрәнчек» шигырьләр күбрәк кебек тәэсир кала. Монда хатын-кыз шигъриятенең тематик байлыгы чагылыш тапкан.

Бер елдан соң дөнья күргән икенче җыентык «Тансык бәхет» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 222 б.) яңалыгы белән дә, шигъри табышлары белән дә игътибарны күбрәк җәлеп итә. Әйтик, «Туган чакта һәркем көчсез сабый...», «Җан сакчысы иттем йөрәгемне...», «Йөрәкләрдә шигырь уты яна...», «Ничәмә кат янган утка кердем...» кебек сәхнәләрдән укый торган, кешенең ныклыгы, иҗатның көче белән горурланып язылган патриотик шигырьләр дә, кеше язмышы, яшәеш фәлсәфәсе матур чагылыш тапкан әсәрләр дә («Ак җилкән», «Хәтер елгасында, әнкәй, кат-кат...», «Иксез-чиксез зәңгәр киңлек...» һ.б.), саф мәхәббәт шигырьләре дә бар. Алар традицион кимәлдә, техник яктан камил эшләнгән, ләкин бу шигырьләрне яңалыгы белән гаҗәпләндерә дип бәяләү дөрес булмас иде. Еш кына хисләрнең сәбәбен әйтеп, ачыклап бетермәү күзәтелә. Лирик герой да – романтик, ярата белгән, дөньяга шагыйрь күзе белән караучы, туган җирен яратучы, ләкин анда шушы сыйфатлардан тыш нindидер шәхси, үзенчәлекле сызыкларны күрү мөмкин түгел. Әйтерсең, Әлфия хис-кичерешен сөйләп бара, ләкин тулысынча җанын ачып бетерергә шикләнә – шуңа күрә моны гомумиләштереп, образлы бәяләми. Дөрес, хисләрне детальләштереп, җентекләп сөйләп бару гаять тәэсирле, ул күңелнең төрле мизгелләрен, кеше уй-эмоцияләренең тирәнле-

ген, байлыгын күрсәтә. Шигырьләр укыла. Ләкин яңалыгы белән сискәндереп хәтергә кереп урнашырлык шигъри юллар күп дип әйтмәс идем. Бәлки, шуңадыр да, яңалык ягыннан гражданлык лирикасына караган шигырьләр шәхси, интим, мәхәббәт хисләрен белдергән шигырьләргә караганда көчлерәк бу иҗатта.

Гадәттә, олы шагыйрьләр иҗаты дөньяга караш концепциясенең үзенчәлеге һәм шуны чагылдырырлык әдәби алымнарның яңалыгы белән гаҗәпләндерә, аларның беркемне дә кабатламый торган стиль үзенчәлеге шуңа бәйле була. Әлфия иҗатының камилләшү юлы танылырлык үз шәхси образларын, дөньяга шәхси карашны белдерерлек шигырь техникасы алымнарын табуда, күрәсең.

Күп кенә шигырьләр эшләнеп бетмәгән, фикер формалашып җитмәгән дигән тәэсир калдыра («Мин хисләрдән яралганмын...», «Җир сулышы, чор сулышы»). Традиционлык гел бер силлабик формага өстенлек бирүдә дә, танылa торган рифмалар белән эш итүдә дә аермачык. «Тавышы-агышы», «җанымны-данымны», «тирәгемә-йөрәгемә», «алда-ялга» кебек рифмаларны үзгәртәсе килә башлый. Халык җырларын хәтерләткән вәзен, төзек булса да, шигъри орлыкка чәчәк булып ачылырга ирек бирми, укучыга образны-күренешне уйлап бетерергә мөмкинлек калдырмый. Әйтик, «Сөләйман балдагы» шигырендә мәхәббәтнең юкка чыгуы әйтеп бетерелгән, шушы күренешне укучыга хыялында төзеп карарга, үз язмышына үлчәп чагыштырырга мөмкинлек калмаган.

*2016 ел.*

**Мөҗәһит ӘХМӘТҖАНОВ,**
*балалар шагыйре, Абдулла Алиш*
*һәм Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты*

# Өзелмәсен хәтер җепләре

Күптән түгел Яр Чаллы Язучылар оешмасының 35 еллык бәйрәмендә катнашырга туры килде. Кичә башланып китте. Берничә йөз тамашачы сыйдырырлык зур мәдәният сараенда кичәнең эчтәлегенә туры китереп, тавыш көчәйткеч колонкалардан Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе, мәрхүм авылдашым Харрас Әюповның үзе укуында чип-чиста яңгыраште «Татар җыры» шигыре яңгырады. Зал искиткеч зур игътибар белән, тын да алмый тыңлады бу чыгышны. Әйтерсең лә, бөек шагыйрь Харрас үзе сәхнәгә басып, безнең каршыда өзгәләнеп, татар җыры турында сөйли. Кичә тәмам булганчы, шушы вакыйга мине тетрәндереп торды. Бу чыгыш бит минем сайттагы Харрас өлешенә бер дигән материал булыр иде. Ә быел, җитмәсә, Харрасның юбилей елы да. Исән булса, аңа тиздән 70 яшь тулган булыр иде... Якташларым, әдәбият сөючеләрнең күбесе бит бу ялкынлы чыгышны ишетми калдылар. Ничек итеп шуны сайтыма урнаштырырга? Бу турыда Чаллы Язучылар оешмасы рәисе якташым Факил Сафинга да җиткердем. Гадәттәгечә, минем сорауны ул бер дә авырыксынмыйча кабул итте. Берничә көннән мин Харрас язмасының инде танылган шагыйрә, шулай ук якташым, Актаныш кызы Әлфия Ситдыйковада булуын ишеттем. Аның белән элемтәгә кердем. Ул, кешегә ярдәм итә алуына куаныпмы, бер-бер артлы, Мөслимдә туып үскән язучыларга багышланган, Чаллыда «Күңел» радиосы журналисты булып эшләгән чордагы язмаларын минем электрон почтама җибәрде. Күзләремә яшьләр килде. Һич тә көтмәгәндә, уйламаганда, шушы кадәр мирас, байлык килеп төшсен әле... Мин аларны шундук үземнең сайтка урнаштырдым. Теләгән укытучылар яки башка һөнәр ияләре әзер материалга кинәнсеннәр, онытылып барган мизгелләр шушы хәтер җепләре аша кабат яңарсын әле, дидем.

Шул вакыйгадан соң күп тә үтмәде, Әлфия Ситдыйкованың «Хәтер җебе» (2015) исемле шигырьләр һәм нәсерләр китабы кулыма килеп эләкте. Әлеге китапта шагыйрәнең төрле елларда иҗат иткән лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм нәсерләре татар һәм урыс телләрендә матур итеп туплап бирелгән. Әсәрләрне рус теленә Вера Хәмидуллина тәрҗемә иткән.

Китап «Моңлы язмыш» шигыре белән башланып китә. Шигырьләрнең алдагылары белән танышуга күчкәнче үк белдем: Әлфиянең бөтен тормышы, үткәне моңнан тора. Ә кеше моңнан башка яши алмый икән, аның җанында инде матур шигырьләр тумыйча калмас, дип, алдагы шигырьләрне укырга керештем. Әйе, дөрес уйлаганмын. Шигырьләрнең төрлесе бар: мәхәббәт турындагылары да, халык, тел, язмыш турындагылары да... Иң тәүдә мин шигырьләрнең шомалыгына, аларның җиңел укылышына игътибар юнәлттем. Шагыйрә нинди генә теманы ачарга тотынса да, безнең борынгы төрки классик шигъри калыпларның ритмик, рифма төгәллекләренә хыянәт итми. Шуларны истән чыгармый гына, үзенең фәлсәфәсен үткәрә. Ә бит кайбер шагыйрьләр фәлсәфәгә күчтеме, аларны аңлау бик авырлаша. Бу шигыре белән нәрсә әйтергә теләде икән, дип баш ватасың. Әлфиянең фәлсәфәсе гади, аңлаешлы, шул ук вакытта тирән дә. Аның әйтәсе килгән фикерен аңлау өчен, югары курсларда уку, филология буенча махсус белем дә кирәк түгел. Шуңа күрәдер, Әлфиянең шигырьләренә композиторлар мөрәҗәгать итә, аның байтак кына шигырьләре күптәннән җыр булып яңгырый.

Әлфиянең мәхәббәт, сөю турында язган шигырьләре гадәти генә түгел. Ул үзенә бертөрле ярату, сөю газабы, югалту ачысы белән сугарылган илаһи шигырьләр. Аларны укыгач, үзең дә әлегә кадәр билгеле булмаган мәхәббәт кануннары белән танышкан кебек буласың. Шигырьләрдәге матур образлылык сине тагын да башка шигырьләрне укырга тартып, кызыктырып тора. Ул башкаларны кабатламый, һәр очракта яңа сурәтләр табарга омтыла.

*Мин, сагынсам, болытларга карыйм,*
*Сәлам юллап, синең тарафка.*
*...Синнән килгән болыт эленеп калган*
*Өй янында үскән наратка.*

яки:

*Иңнәреңә баскан сөю йөген*
*Бүлешергә килдем.*
*Күзләреңдә йолдыз төсле янган*
*Шигырь утын күрдем.*

Ә инде нәсерләргә килгәндә, алар барсы да шигъри тел белән язылган. Шагыйрә аларны, мөгаен, үзенең хисләрен шигырь калыпларына гына сыйдырып бетерә алмаганга, шул алымны кулланганлыр. Аннан соң бит әле ул бертөрлелектән качу да булып тора. Укучыларга рәхәтлек, ял бирә, уйландыра торган нәсерләр алар. Шушы нәсерләр аша син авторның күңелендә ниләр ятканын, аның эчке дөньясын күрәсең, алар белән танышасың, үзең яңа дөнья ачкан кебек буласың.

Китаптагы шигырьләр һәм нәсерләрнең русчага тәрҗемә ителеп бирелүе дә отышлы дияр идем. Татарча белмәгән, ә татар шигъриятен аңларга теләгән рус телле укучылар шагыйрәнең эчке дөньясы белән азмы-күпме таныша алалар. Азмы-күпме, диюем шуңа, чөнки нинди генә яхшы тәрҗемәче булмасын, ул бер телне икенче телгә бөтен матурлыгы, аһәңе белән биреп бетерә алмый. Ә Әлфия шигырьләренең тәрҗемәләре уңышлы гына. Чаллы язучылары бу өлкәдә матур гына эшләп киләләр.

Язмамны төгәлләр алдыннан кабат башлаган сүземә әйләнеп кайтасым килә.Үзенең кешегә булган игътибарлылыгы, ярдәмчеллеге, кыйммәтле әдәби мираска, кеше хәтеренә булган үтә дә җаваплы сакчыллыгы Әлфияне чын шагыйрә иткән дә куйган. Әлфия Ситдыйкова үзенең бөтен барлыгы, эчке дөньясы белән кешеләрне, бигрәк тә яшь буынны агартырга, аларга дөрес тәрбия бирергә тугандыр. Киләчәктә аңа тагын да зуррак иҗат уңышлары, кылган һәр гамәленең хәтер җепләре булып озак еллар буе өзелмичә саклануын телим.

*2016 ел.*

# Төрле әдәби очрашулардан

*(Аудио-видео язмаларда)*

**Мирһади РАЗОВ,**
*шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы*

Әлфия – минем якташым, соңгы елларда бик күп иҗат итә. Ул өлгереп җиткән, зур талантлы шагыйрә. Аның котлау шигырьләрен бөтен Башкортстанда, бөтен Татарстанда радио-телевидение аша сөйлиләр.

Аны лирик шигырьләре буенча да бик яхшы беләләр. Әсәрләре «Казан утлары» журналында басылды. «Ватаным Татарстан» газетасында, «Мәйдан» журналында дөнья күрде. Китаплары күп таралды. Һәм безнең Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ кебек шагыйрьләребез дә аның иҗатына зур бәя бирделәр.

Әлфиянең бу иҗат кичәсе быелгы «Әдәбият-сәнгать елы»нда иң күркәм кичәләрнең берсе. Һәм тагын шуны өстисем килә: соңгы вакытларда шигырьнең тәме бетте, поэзия аскарак күчте, – диләр. Мин моның белән килешмәс идем. Шигъриятебезгә бик күп талантлы шагыйрьләр, шагыйрәләр килә. Әлфия менә шуларның бер ачык мисалы.

Аның китапларын, телевидениедә бергә эшләгәч, иң беренче мин күрәмдер инде. Һәр китабын укып чыгам. Хатын-кызлар нәфис итеп язалар, үзләренең фәлсәфәсе була. Әлфия хәтта ирләр яза алмый торган шигырьләрне ирләр күзлегеннән карап яза ала. Аның диапазоны киң. Әлфия, сиңа иҗат уңышлары телим, бәхетле бул!

*«Шатлык» яшьләр үзәге,*
*2006 ел, 3 май.*

**Рәшит БӘШӘР,**
*шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы,*
*Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты*

Әдәбиятка һәркем үзенчә килә, һәркем үзенчә яза, һәркем үзенчә җырлый. Һәркем үзенчә җырламаса, ул шагыйрь дә булмас иде.

Әлфиянең дә шигырьләрен мин күптәннән беләм. Беренче китапларын чыгарганда һәрбер шигъри юлы белән танышырга туры килде. Ул менә чынлап та үсештә. Әлфия эзләнә, яңадан яңа табышларга байый. Дөньяны үзенчә күрә. Менә аның «Бала елый» поэмасы шуның ачык мисалы. Заман трагедиясе, заман фаҗигасе килеп керә шигырьгә. Чөнки шагыйрь җаны һәрвакыт уйда, һәрвакыт шомлы уйлар белән тулы. Заманы шундый.

Чаллы талантларга бай. Шунысы сөенечле: Әлфия Ситдыйкова «Казан утлары» битләренә үтеп керә алды. «Казан утлары» кебек дәрәҗәле журналда чыгу бик катлаулы. «Мәйдан» журналында чыгу шулай ук бик катлаулы. «Мәйдан»да да Әлфиянең әсәрләре басылып тора.

Ул китап нәшрияты өчен яңа китабын әзерләде. Китапка бик могтәбәр, күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташ сүз башы язды. Ул китап та тиздән чыксын иде дигән теләктә калабыз.

Әлфиянең әле иҗат итәр чагы. Әле ул тулысынча ачылып кына килә. Ул зур, тату коллективта эшли. Аның да тәэсире бар. Һәр язган шигырен ул миңа телефоннан булса да укый. Әлбәттә, мактыйсы җирдә мактыйм, тәнкыйтлисе җирдә тәнкыйтлим. Шунсыз булмый.

Шигъри фәрештәләре һәрвакыт иңнәрендә утырсын. Шагыйрь кешенең фәрештәләре, уйлавымча, аның яхшылыкларын гына санап баралар. Чөнки шагыйрь күңелендә кер булмый. Аларның күңелләре чиста, матур. Алар кешеләргә игелек кенә телиләр. Кешеләргә яхшылык теләмәсә, менә шундый шигырьләр язалмаслар иде. Иҗат уңышлары сиңа, Әлфия! Бәхетле иҗат язмышы. Иҗат язмышы ул бәхетле дә һәм бик авыр да. Чөнки йөрәк гел яраланып

тора. Яралы йөрәк белән иҗат итү бик катлаулы нәрсә. Рәхмәт, Әлфия, иҗатың өчен.

*«Шатлык» яшьләр үзәгендә узган иҗат кичәсеннән, 2006 ел, 3 май.*

* * *

Әлфия – салкын замананы җылытырга, кешеләр күңелендә өмет чаткыларын терелтергә тырышып, киләчәккә булган ышанычны ныгытып иҗат итә торган шагыйрәләребезнең берсе.

Халык мәнфәгатен кайгыртмаган, халык шатлыгы белән сөенмәгән кеше шагыйрь була алмый. Ул мәңге шулай булган, хәзер дә шулай. Әлфиябез инде дистәгә якын китап чыгарды. Аның беренче китабын – «Йөрәгемә яфрак сыена»ның кулъязмасын алып килгәч, шигырьләрен укый башлагач, сөенеп утырдым. Тагын бер үзенчәлекле шагыйрә килә икән әдәбиятка дип. Китапка сүз башы да яздым. Аллага шөкер, Әлфия бу ышанычны аклап, иҗат итүен дәвам итә. Бу – бик сөенечле хәл. Язучылар берлегендә 300дән артык язучы исәпләнә. Әмма алар арасында чын язучылар бик күп түгел. Бер-ике-өч дистә генәдер. Менә шулар арасына, әлбәттә, мин Әлфияне дә кертер идем. Ул – уйлы шагыйрә. Аның үзенең язу стиле формалашып җитте. Ул үзен шигърияттә тапты. Ул – мәхәббәт җырчысы. Аның шигырьләре мәхәббәт турында. Шигырьләре назлы, эчкерсез, садә.

*Үзәк китапханәдә узган юбилей кичәсеннән, 2007 ел, 13 сентябрь.*

* * *

Бер-бер артлы китаплары чыкты. Ул – дистәгә якын китап авторы. Безнең яшьләргә киң мәйданга чыгу җиңел түгел хәзерге заманда. Шулай да, Әлфия үзенең үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә, соңгы елларда бик күп уңышларга иреште. Аның шигырьләре Республиканың бөтен матбугатын яулап алды. «Казан утлары»нда чыгу ул бик зур дәрәҗә язучы өчен. Аны, димәк, бөтен республика

таныган дигән сүз. Аннан әле аның «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталарында, «Мәйдан» журналында гел күренеп килә шигырьләре. Китап нәшриятында аның өр-яңа шигырьләр китабы дөнья күреп килә. Тәрҗемә китабы. Ул да укучыларга бик зур бүләк булыр дип уйлыйм мин. Шигырьләрендә хатын-кызларга гына хас наз, җылылык, садәлек, сафлык бөркелеп тора. Аның иҗаты шуның белән кыйммәт. Әлфия шигърияте бүгенге авыр заманда кешеләр күңелендә өмет уята. Яшәүгә ышанычны ныгыта. Иҗатының иң кыйммәтле ягы шул.

*Яр Чаллы телевидениесы өчен биргән интервьюдан.*

* * *

**Фәйрүзә МОСТАФИНА,**
*Яр Чаллы педагогия институты ректоры*

Хатын-кыз җир шарына матур сүзләр сөйләү өчен түгел, ә якын тирәдә булган әйберләрне гармонияләштерү өчен туа. Аның беренче бурычы шул. Әлфия шуның белән шөгыльләнә дә инде. Мин аның иҗатын бик яратып, укып барам. Аның китаплары да үзе кебек матур, җыйнак, нәзек. Биюдә – балет югары нокта. Аның шигырьләре – поэзиядә балет.

*Үзәк китапханәдә узган юбилей кичәсе,*
*2007 ел, 13 сентябрь.*

* * *

**Айдар ХАЛИМ,**
*писатель*

Секрет поэзии – в образах. Альфия Ситдикова, мне кажется, последнее время выделяется особым видением мира. Она открывает, подбирая именно свои краски, характерные только для неё. И мне видится, что у неё большое будущее.

Мало еще писать стихи. Не зря говорил поэт Некрасов: «Поэтом можешь и не быть, гражданином быть обязан!» И вот, за Аль-

фией просматривается высшая культура общения с людьми. Это понимание той жизни, в которой мы живем. И соучастливое отношение к людям. Гражданский подход к жизни. Она замечает в людях, особенно в людях искусства то, что порою не замечают многие. Возможно, в том числе и я.

*Интервью на «Чаллы-ТВ».*

* * *

**Венера САФИНА,**
*ветеран укытучы*

Хөрмәтле милләттәшләр! Мин татар халкының талантлы баласы Әлфия Ситдыйкованың иҗат кичәсенә шатланып килдем. Чөнки шигырьләрен яратам. Анда шулкадәр җылылык. Безнең халыкта шундый әйтем бар: «Җылы сүз – җан азыгы». Ә инде олыгая төшкәч, һәр кешенең җылы сүзгә, җылы мөнәсәбәткә ихтыяҗы арта икән.

Әлфия ханымның шигырьләрендә олы кешеләргә карата да, яшьләргә, балаларга карата да җылы сүзләр җитәрлек. Аларның җылылыгы Татарстан чикләрен узып, башка төбәкләргә дә барып җиткән. Менә мин үзем Самарадан. Быел апрель аенда кайттым туганнар янына. Утырабыз мәҗлестә. Шул вакытта берсе шартлатып укып җибәрмәсенме, болай диеп:

*Еракларга алып китеп язмыш*
*Яшәтсә дә сезне чит җирдә.*
*Җан тартмаса, кан тартадыр ахры,*
*Җыелгансыз тагын сез бергә.*
*Бер атадан, бер анадан бит сез,*
*Барыгыз да яхшы күңелле.*
*Насыйп итсен иде Раббым сезгә*
*Күрешеп яши торган гомерне.*

Ай Алла, мәйтәм, бу бит безнең Әлфия Ситдыйкова сүзләре.

Кырык мең татар яши Самарада. Телевидениедан, радиодан бер минут вакыт бирелми. Анда чыга бердәнбер газета. Кайткач-

тын мин укыштыргалыйм. Әлфия Ситдыйкованың сүзләре еш очрый. Менә никадәр кешеләргә өләшә ул җылы сүзләр. Никадәр кешеләрне сөендерә. Мин әйтәм: «Ул монда ничек килеп эләкте!» – дип. «Үзең кайтардың бит китапларын, күчереп-күчереп алабыз инде!» – диләр. КамАЗга төяп кайтарасы иде менә бу Чаллы шагыйрьләренең китапларын, Әлфиянекен генә түгел. Шундый ихтыяҗ зур, шундый җан әрни. Халык аптырап яши җырга, моңга, татар сүзенә.

Сеңлем! Сез үзегез кешеләргә күпме җылылык өләшәсез, үзегез дә олыгайган көннәрегездә якыннарыгыз, дусларыгыз, гаиләгез тарафыннан гел җылылык тоеп кына яшәсәгез иде. Бик зур рәхмәт сезгә!

*«Шатлык» яшьләр үзәгендә узган иҗат кичәсе,*
*2006 ел, 3 май.*

* * *

**Рахман ШӘФИГУЛЛИН,**
*«Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясе директоры,*
*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре*

Әлфия Ситдыйкова шагыйрә буларак соңгы җиде-сигез ел эчендә танылды. Тематикасы да үзгәрде. Бу уңышларда беренчедән: аның таланты, икенчедән: шушы талантны тормышка ашыру өчен шартлар булуы. Безнең телерадиокомпания чыннан да – әдәби учак, кешеләргә рух бирүче чыганак. Әлфия шагыйрә генә түгел, бу төбәктә: Мамадыштан алып Актанышка кадәр булган арада, башлап язучыларны, шагыйрь-шагыйрәләрне эзләп йөреп, аларны халыкка тәкъдим итә. Ул зур, саваплы эш башкара. Әлфия иҗат итә. Әле ул Язучылар Берлеге әгъзасы гына түгел, Халык шагыйрәсе дә булыр. Мин аңа ышанам.

*Муса Җәлил исемендәге шәһәр Үзәк китапханәсендә узган*
*юбилей кичәсе, 2007 ел, 13 сентябрь.*

* * *

**Альхат ЗАЙНУТДИНОВ,**
*генеральный директор ЗАО «КамАЗжилбыт»*

Произведение вышла на двух языках. Это радует. Это – дружба, это – любовь.

Санаторий Набережные Челны. Приходят две поэтессы. И проводят встречу с отдыхающими. Это – новость: зал полный. Сидят татары, русские. Все первый раз пришли на это уникальное собрание. Звучат стихи на русском, звучат стихи на татарском. Зал молчит. Снова стихи на русском, стихи на татарском..., на русском... Аплодисменты... И вдруг из зала: «А можно я тоже свои?» ...Второй: «А можно я тоже свои?!» ...Третий: «А можно я тоже свои стихи прочитаю?!»

Зал ожил. Народ стал сочинять стихи, выражать свои мысли стихами. Это говорит о том, что впереди у нас – хорошее будущее. Это – традиции наших великих людей.

Сегодня в газете прочитал интересную мысль Армена Джигарханяна. Он назвал Пушкина и Моцарта инопланетянами. Вы тоже те же инопланетяне, которые пришли на нашу землю, чтоб обогатить ее своими, не побоюсь этого слова – великими произведениями.

*Вечер презентации книги*
*«Два родника родной земли» / «Туган якның ике чишмәсе»,*
*2008 год, 16 января.*

* * *

**Рамиль МАЗИТОВ,**
*начальник управления культуры*

На мой взгляд, как и картины, так и поэзия, в первую очередь, сначала будит чувства, ощущения, а потом – мысли. Сегодня я расскажу о своих чувствах, ощущениях, о своем видении. Я увидел абсолютно двух разных поэтесс. Они абсолютно великолепны. Но при этом абсолютно разные.

Одна – очень мягкая, очень нежная, очень тонкая, живущая и в жизни и на сцене, и в своих строках книг в мире чувств и переживаний. Иногда, наверное, в поиске самой себя в этом мире, смысла жизни. Другая – яркая, экспрессивная, знающая где она находится. Знающая и себе цену, видящая мир очень широкими, широко открытыми глазами. Я думаю, здесь не надо говорить кому относятся первые мои слова, и, кому относятся вторые. И, при этом, они обе великолепны и романтичны. Но романтичны по-разному. У одной – романтика через внутренний мир, через собственные ощущения, через переживания. А у второй – это, я бы сравнил с романтизмом путешественника, человека познающего мир и рассказывающего о мире другим людям. Это очень здорово, очень красиво!

Удивительно, что они действительно нашли друг друга. И самое удивительное: когда перевод ничуть не хуже оригинала. Наверное, это получилось именно оттого, что это тандем. Это по-настоящему дружба двух людей, которые по-настоящему друг-друга уважают и любят. И стараются донести мысли и чувства каждому из нас, до читателей, до слушателей. За это огромное спасибо!

*Вечер презентации книги*
*«Два родника родной земли» / «Туган якның ике чишмәсе»,*
*2008 год, 16 января.*

* * *

**Нурулла НУРЛЫЕВ,**
*«Актаныш таңнары» газетасының баш мөхәррире*

Уважаемая Вера Петровна! С вашим творчеством я познакомился только сегодня. Но я скажу, что она меня ошеломила. И благодаря вашей книге, ваше творчество будет звучать и в Актаныше. В этом виновата наша Альфия, в хорошем смысле слова.

Әлфия! Сүз дә юк, сезнең иҗат җимешегезгә бүгенге зур тантанада шундый зур бәя бирелү, бездә зур горурлык хисләре уята.

һәм инде, хөрмәтле Илбашыбыз Минтимер Шәрипович әйткәнчә, «Без булдырабыз!» дип эшлисез һәм булдырасыз. Шуңа күрә без сезнең белән нык горурланабыз. Шигырьләрегез, Такташ әйткәнчә, киләчәккә хатлар. Шигырьләрегез, иҗатыгыз меңъяшәр дип уйлыйбыз.

*«Два родника родной земли» / «Туган якның ике чишмәсе»,*
*китабын тәкъдир итү кичәсе, 2008 ел, 16 гыйнвар.*

* * *

**Энгель ФӘТТАХОВ**
*Актаныш муниципаль район башлыгы*

Әлфия Ситдыйкова – Чаллыда яшәүче чын Актаныш патриоты ул. Һәрвакыт элемтәдә, һәрвакыт безнең белән аралашып эшли. Чаллыда Актанышны алга этәрүче, Актаныш данын яклап баручы, бик матур иҗат итүче якташыбыз.

*Актанышта китап презентациясе.*
*2011 ел, 27 май.*

* * *

**Мәдәния ИЛЬЯСОВА**
*РСФСРның халык мәгарифе отличнигы,*
*ТР атказанган сәүдә хезмәткәре,*
*Чаллы шәһәренең почетлы гражданины*

Әлфия! Бу китап («Утлы җимеш») шундый зур хөрмәткә ия. Халыкны тәрбияләүгә зур ярдәм бирсен. Китапны мәктәп балаларына җиткерергә иде. Татар теле укытучылары үзләренең дәресләрендә шушы китаптагы шигырьләрне балаларга җиткерә алсалар һәм аларны тәрбияләүдә зур роль уйнавына басым ясасалар, мондагы язылган сүзләр балаларның тормыш юлларында матур ызаннар булып сызылып калырлар иде. Бигрәк тә, «Бала

елый» дигән шигырьне мин поэма дип атар идем. Бу – Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»ндәге кебек бер кыз баланың язмышы бит.

Мин тәкъдим итәр идем Сезгә: мәктәп директорлары аша, үзебезнең мәгариф идарәсендәге тел буенча кем шөгыльләнә, шулар аша китапка дөнья күрсәтергә кирәк.

*2011 ел, 10 февраль.*

# Китап укучыларыннан хатлар

**Әнвәр ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ,**
*III дәрәҗә «Шахтер даны» кавалеры*

Әлфия матурым! Син минем бу хатымны алгач, бераз каушап та, бераз гаҗәпләнеп тә калырсың.

Миңа бүләк итеп калдырган «Җанда кабынган учак» дигән китабыңны әле менә шушы көннәрдә укып бетердем. «Теләмичә генә укыган ахыры» димә, бүген менә 26 июль, миңа бүләк иткән көнең 1 июль. Нәкъ 25 көн буе укыдым, чөнки мин аны һәр көнне үземә рухи азык алыр өчен, беренче мәхәббәтем белән очрашу мизгелләрен күз алдына китерә-китерә, озаклап укыдым. Бер-ике бит укыйм да уйга калам. Бу бит минем тормышымнан, зәңгәр томаннар артында калган мәңге кире кайтмас яшьлегем елларыннан алып язылган. Хәер, бу хисләр барысы да яшьлеккә хас, яшьлек шушы матур хисләр аша үтеп, йөрәкләребездә мәңге җуелмаслык эзләр калдыра.

Әлфия! Синең (Сез димим, үз итеп эндәшәм) бу китабыңны бик хискә бирелеп, ләззәтләнеп укыдым. Һәрбер шигыреңне ике кат һәм сокланып укыдым. Минем күзаллавымча, син рифма төңгәллеге өчен уйлап утырмагансың, шигырьгә салынган мәгънәгә басым ясагансың. Минем, үз гомеремдә, бик күп ир-атлар һәм хатын-кыз шагыйрьләр-шагыйрәләрнең иҗатлары белән танышлыгым булды. Ә менә хатын-кыз шагыйрәләр арасыннан минем күңелемне яулаган, уйланырга-хисләнергә мәҗбүр иткәннәре: Саҗидә апа Сөләйманова, Шәмсия Җиһангирова иҗатлары иде. Менә инде көтмәгәндә-уйламаганда синең иҗатың – шигъриятең белән очраштым. Бу иҗатың синең искиткеч сихри серләр дөньясы икән бит! Монда табигать матурлыгы, мәхәббәт дөньясы, беренче тапкыр күзләр очрашуы, хисләр дәрьясы, искиткеч матур чагыштырулар-метафоралар.

*Ике күңел – алтын күпер,*
*Кушылды уйларыбыз...*

Мин шигърият өлкәсендәге белгеч-тәнкыйтьче түгел (хәер, хәзер алар юк та бугай инде), синең шигырьләреңне анализларга җыенмыйм, ә менә укучы буларак фикерләремне әйтәсем килгәнгә, шушы хатымны сиңа язып калдырырга уйладым.

Белгәнеңчә, шагыйрьләр укучылар өчен язалар бит, һәр шагыйрьнең үз укучысы була. Менә, Әлфия, 75 яшьлек Әнвәр абыеңны яисә бабаңны дип әйтимме, үзеңнең укучың дип санарсың! Син мине иҗатың белән йөрәгемне дә, акылымны да әсирлеккә алдың. Рәхмәт үзеңә, яшьләрне дә, олы яшьтәгеләрне дә иҗатың аша үзеңә табындырганың өчен. Талант та бар икән үзегездә! Инде киләчәктә яңа гына яратып, үз итеп өлгергән шагыйрәмне җуймасам иде.

Иҗатыгызга килгәндә, инде үз каланчамнан торып шуны әйтим: лирикага, хискә, матур чагыштыруларга бик бай бит шигырьләрегез. Мисаллар китермим, китабыгыз – матур хисләр чишмәсе. Олы яшькә җитеп татар теленең чиксез матурлыгын тоеп яшәсәм дә, мин синең иҗатың аша татар теленең бөеклегенә тагын бер кат сокландым. Алда әйткәнемчә, нинди олы, җылы хисләр дөньясында йөрттең Син мине! Ул рифмалар тәңгәллеге, фикер тирәнлеге гаҗәеп дәрәҗәдә. Болай бары тик хатын-кыз шагыйрәсе генә әйтә ала булыр! Әле киләчәктә тәнкыйтьчеләр синең иҗатыңа карата үз фикерләрен әйтерләр, һәм, бары тик яхшы, уңай бәя генә бирә күрсеннәр иде.

Бу кыска гына очрашу минем үземдә бик тә матур истәлекләр калдырды.

Синең иҗатыңны русчага тәрҗемә иткән ханым Вера Хәмидуллинаның синең шигырьләреңне пафос белән укуына сокланып утырдым, бер-берегезне тулыландырып укыдыгыз. Мин аның образга кереп очкынланган күзләрендә Такташ укуын күз алдымда тоттым. Аңарга да рәхмәтемне җиткерерсез! Бу хатымны бик теләп яздым, укучылар белән очрашуыгыз эзсез үтмәде, йөрәктә ниндидер тирән хисләр кузгатты. Тагын очрашулар насыйп булсын! Сиңа тагын бер кат олы рәхмәтем, тирән ихтирам һәм хөрмәт белән.

*«Ижминводы» санаториесы,*
*2007 ел, 26 июль.*

**Сания ГАЛИЕВА,**
*Казахстан республикасы, Алматы шәһәре, китапханәче-библиограф, татар, татар-башкорт үзәкләренең «Идел» Ассоциясе берлеге, Алматы Дуслык йортында татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

# Актаныш таңнары!.. Кем генә белми бу җырны, кем генә эченнән көйләми?!

*Туган ягым – яшел бишек – Актаныш!*

Бу сүзләр һәркемгә таныш. Ә кичен, әсәрләнеп күккә карасаң, күк йөзендә күпме йолдызлар җемелди. Әйе, Актаныш күге йолдызларга бик бай. Болар – Татарстан Республикасының халык артисткасы Әлфия Авзалова, җырчы Газинур Фарукшин, Асаф Вәлиев, Лилия Муллагалиева, Илгиз Закиров, Татарстан Республикасының халык артисты Кирам Сатиев һ.б.

Күп алар, йолдызлар. Алар күктә балкыйлар, ә җирдә халыкка күпме җыр-моң бүләк итәләр, сәхнә хезмәте күрсәтәләр. Шулар арасында Актаныш йолдызы – олы шагыйрә Әлфия Ситдыйкова.

Без Әлфия ханым белән күптән таныш. Тыйнак, гел елмаеп кына тора. Беренче карашка бу хәтле шигърият дөньясы кайда сыйган дип уйларлык. Кечкенә буйлы, мөлаем, күзләре гел көлемсерәп тора. Сөйләме белән үзенә гашыйк итә. Күп китаплары басылып чыккан. Бу китаплар буенча без Алматы шәһәрендә Әлфия Сабитова белән берничә тапшырулар ясадык. Мин Әлфия Ситдыйкованың «Бер җылы сүз», «Йөрәгемә яфрак сыена», «Җанда кабынган учак», «Хисләрем канаты – Күҗәкә», «Җаннар назга төренә» дип исемләнгән китаплары белән радиотыңлаучыларны таныштырдым һәм шигырьләрен укып уздым.

Әлфия Ситдыйкованың китаплары, язган шигырьләре, поэмалары, нәсерләре тормыш, язмышы белән сугарылган, бай, тирән эчтәлекле. Әлфия Ситдыйковага саулык-сәламәтлек, зур иҗади уңышларга ирешеп, хөкүмәт аның эшен зур бәяләп, «Татарстанның халык шагыйре» дигән дәрәҗә алуын теләп калам.

*2006 ел, 17 октябрь – 28 ноябрь.*

# Әлфия Ситдыйковага багышланган шигырьләр

**Айрат СУФИЯНОВ,**
*шагыйрь*

## Синең дөньяң

Синең дөньяң шундый якын җанга,
Саф мәхәббәт чәчкән гөлләмә.
Берүк, мине, нәфрәт җырчысы, – дип,
Исеп узган җилгә сөйләмә.

Нәфрәттән дә мин мәхәббәт эзлим,
Ямьсезлектән эзлим гүзәллек.
Һәр мизгелдә яңа ярам арта,
Искеләре бетми төзәлеп.

Мин бер сөеп дөрләп янган идем,
Калган иде миннән көл генә.
Тыеп торам, тия күрмәсен лә
Салкын кулым сөю гөленә.

Күңелеңнең иркә гөлләренә
Кырау булып куркам төшүдән.
Ходай сине үзе саклый күрсен
Башта пешеп, аннан өшүдән.

...Җавап бирче, гөлләреңне ничек
Саклый алдың янып, сөеп тә...
Дөньяң якын җанга, бер аерма:
Мин бәйләнгән... Ә син иректә...

*2004 ел.*

**Рәзинә МӨХИЯР,**
*шагыйрә*

* * *

Теләкләрнең телисең син
Иң яхшысын, изгесен.
Кешеләрне шатландыру
Савап эше – изге син.

«Йөрәк сүзе йөрәккә» дип,
Күпме йөрәк җылыта.
Күпме кеше якынына
Аның аша җан ата.

Үзенә дә телик бүген
Теләкләрнең изгесен.
Шигырьләре яктыртсыннар
Аның күңел көзгесен.

Теләгән бар теләкләре
Кабул булсын, уң булсын!
Бездән күчкән матур сүзләр
Илһам, нур булып тулсын!

*2006 ел, 3 май.*

**Наил НӘҖМИ,**
*«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы*

* * *

Укыдым да хатларыңны,
Читкә алып куйдым.
Ни әйтергә белми, менә,
Уй-диңгезгә чумдым.

Хатлар тулган хискә, хәтта
Тулып, ташып аккан.
Һәр сүзенә Сөю үзе
Дулкын булып яткан.

Кайбер сүзләр менә-менә
Ялкынланыр төсле.
Бирсә-биргән Ходай сиңа
Вулкандагы көчне.

Сокланам да сиңа, бераз
Көнләшеп тә куям.
Күптән үткән давыл шавын
Әллә кабат тоям?!

Соңга калган мәхәббәтең
Янсын гомер бакый.
...Ачы җилләр нечкә җаның
Һәркөн килеп талкый.

*2006 ел, 8 декабрь.*

* * *

Бу януың, дөрләп кабынуың –
Көздә чәчәк аткан алмагач.
Суык җилдә, шәрә бер яланда
Торасыңдай шып-шыр ялангач.

Әле ярый аңлыйм синең хисне,
Калганым бар синең халәттә.
Берни күрми, тик янасың инде
Сөю килгән изге сәгатьтә.

Чиксез назың, җылы моңнар белән
Җирнең үзен килә төрәсе.
Ах-зарлары булган һәр кешегә
Шул чак бәхет килә бирәсе.

Какмасын да, сукмасын да җилләр
Шау чәчәктән торган хисләргә.
Һәм дә бирсен уртак мәхәббәтне
Йолдыз сүнгән көзге кичләрдә.

Көзге мәлдә ачылган Чәчәк син,
Ак кышларга җитсен назларың.
Каршыларга насыйп булсын сиңа
Киләчәкнең нурлы язларын.

*2006 ел.*

**Гөлфия ФӘЙЗРАХМАНОВА,**
*Чаллы татар дәүләт драма театры артисты,*
*Татарстан Республикасының атказанган артисты*

* * *

Хисләр тулы шигырь китабыңны
Кат-кат алып укыйм, Әлфия.
Шагыйрь җанын аңлый шигъри күңел,
Таныш булыйк: исемем – Гөлфия.

Тәмле телле, назлы шагыйрә син,
Минем телем – әчкелт, борычлы.
Аллаһ каршысында үтибез без,
Икебез дә, берүк бурычны.

Җанны ярып туган шигыреңне
Мөмкинме соң ишетми калу!
Һәр шигырең, һәрбер татлы сүзең
Җан-бәгырьгә шифа һәм дару.

Нәфис җанда кабынган бу учак,
Дөрли-дөрли янсын, сүнмәсен!
Шигъриятнең биеклеге чиксез,
Ялкыннарың өскә үрләсен!

Күңелеңнән чыккан бар аһәңең
Затлы хушбуй кебек аңкысын!
Шигъриятнең серле күгендәге
Якты йолдыз булып балкы, син!

*2008 ел, 16 январь.*

# III

# МӨЛДЕРӘМӘ ТУЛЫ КҮҢЕЛДӘН...

*Әдәби-музыкаль кичә сценарийлары*



**Әлфия СИТДЫЙКОВА**

# Яңа ел курантлары

### *(«Яңа ел» бәйрәмен үткәрү буенча әдәби кичә)*

**Катнашалар:** Кыш бабай
Кар кызы
Алып баручы
Әтәч
Сыер
Елан,
Куян,
Аждаһа
Дуңгыз һәм башка исемдәге
еллар булып киенгән балалар.

*Матур итеп бизәлгән, чыршы куелган бүлмәгә Яңа ел бәйрәмен каршылар өчен алып баручы белән балалар һәм ел исемендәге җәнлекләр җыелган. Балаларның шаулашканын бүлеп, алып баручы сүз башлый:*

**Алып баручы:**

Саубуллашып безнең белән
Узып бара иске ел.
Ел белән ел арасында
Киң һәм якты, озын юл.

Нәрсә кылган иске елда
Безнең тырыш халкыбыз.
Сакланырмы чал тарихта
Татар дигән атыбыз?!

«Әдәбият-сәнгать елы»
Безгә кунакка килгән.
Милләт данын зурладык без
Быел бөтен ил белән.

**1 нче укучы:**

Күпме юбилейлар узды,
Кузгатып татар уен.
Чын сәнгатьле халык диеп
Әйтер киләчәк буын.

**2 нче укучы:**

Онытмадык Тукайны да,
Җәлилне һәм Сараны.
Шәхесләрне барлый-барлый
Уздык ике араны.

**3 нче укучы:**

Милләт хакын хаклаганда
Атлаганда ил белән,
Кыш бабай һәм Кар кызы да
Җәйде юлга ак келәм.

**Алып баручы:**

Беләсезме бу минутта
Алар кая йөргәнне?
Ерак котып илләреннән
Арып кайтып килгәнне?!

**4 нче укучы:**

Ни булды соң, нигә алар
Һаман килми, соңара?
Кар өйгәнме әллә җилләр
Алар килер юлларга?

**Барлык балалар бергә:**

Әй, Кыш бабай һәм Кар кызы!
Сез кайда соң, сез кайда?
Сезне көтеп без карыйбыз
Бер йолдызга, бер – айга.

**5 нче укучы:**

Йолдыз, күзен кысып-кысып,
Котып ягына карый.
Айдагы Зөһрә кызкай да
Сәгать, минутлар саный.

Юлын кем бүлеп җибәрми
Без көткән кунакларны?
Ишетелмәс алар килми
Яңа ел курантлары.

**Алып баручы:**

Сез беләсезме, балалар,
Җиһанда ни барлыгын,
Кем өчендер Яңа елга
Җанда урын тарлыгын?

Кешенең дусты дигән зур
Ышанычны какшатып,
Бер карт эт юлны бүлгән ди,
Таш кыяларны ватып.

Чана үтәр юлны каплап
Ята таш өемнәре.
Шул ташлар тоткарлап тора
Юлларда күренгәнне.

Ничек итеп булышырга,
Җибәрик икән кемне?
Кыш бабайсыз, Яңа елсыз
Ни көтә безнең илне?

**6 нчы укучы:**

Яңа ел да, яңа көн дә
Кирәк бит һәммәбезгә.
Игелекле вазифаны
Йөкләргә икән кемгә?

*Әтәч, сыер, елан, куян, аждаһа, дуңгыз һәм башка елларга карап:*

**Алып баручы:**

Я, кайсыгыз үзе теләп
Кыла бу батырлыкны?
Юлдаш итә изге эштә
Зиһен һәм тапкырлыкны?
Кем коткара явызлыктан
Кыш бабайны, оныгын?
Кем ярдәме белән ачып
Була Яңа ел юлын?

**7 нче укучы:**

Кем игелекле, шунда өмет,
Шул бәладән коткара.
Озынмы соң, кыскамы ул
Ике елдагы ара?!

**Әтәч елы:**

Кикрикүк! Кикрикүк!
Мин бик батыр йөрәкле.
Үзем барам кулга алып
Олы агач көрәкне!

Кар өемен җил җилгәрер,
Көртләрне актарырмын.
Кыш бабайны һәм Кар кызын
Мин сезгә кайтарырмын!

**Сыер елы:**

Му-у-у! Му-у-у! Үзем телим
Күрсәтергә игелек.
Миңа иптәшкә кем бара,
Теләп илгә иминлек?

**Елан елы:**

Мин барс-с-с-ам да була инде,
Шуыш-ш-шып уз-з-з-ам юлны.
Үз-з-зем телим күрс-с-сәтергә
Яңа ел өчен юлны!

**Куян елы:**

Куян куркак димәгез сез,
Мин дә бит куркып тормыйм.
Кайда икәнлеген беләм
Котыптан килгән юлның!

**Аждаһа елы:**

Мин – аждаһа, атлап түгел,
Очып та йөри алам.
Ташны түгел кыяны да
Тын белән өтеп алам!

**Дуңгыз елы:**

Я, кайсыгыз бәхәсләшә?
Алда бит минем елым.
Үзем барып алып киләм
Котыптан «Дуңгыз ел»ын.

**Алып баручы:**

Бәхәскә нокта куелды,
Дуңгыз кузгалды юлга.
Якты өметләр салынган
Юл капчыгы кулында.

**8 нче укучы:**

Ничек барып җиткәндер ул
Ничек чистарткан юлны,
Кайтып килә Дуңгызбикә
Кочаклап Яңа елны.

*Чыршыда утлар кабына.*

**Алып баручы:**

Шаулашмагыз, ишетәсезме?
Кемнәрдер ишек кага.
Бизәкле яшел чыршыда
Меңләгән йолдыз яна.

**Барлык балалар бергә:**

Хуш киләсең, «Дуңгыз елы!»
Изгелек, өмет елы.
Миһербанлык дәвам итсен
Бергә узасы юлны!

**Алып баручы:**

Карт эткә дә үпкәләмик!
Сакламыйк эчтә ачу!
Хушлашасы килмәгәндер,
Йөрәге һаман ярсу.

**Барлык балалар бергә:**

Эт елы да кабатланыр
Унбер ел үткәч тагын.
Хуш киләсең, Дуңгыз елы,
Бай булсын безнең табын!

**Алып баручы:**

Муллык хөкем сөрсен илдә,
Тынычлык һәм иминлек!
Яшик «Хәйрия елы»нда
Кылып бары игелек!

*2006 ел.*

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА**

# «“Бишле” билгесе куям»

## *Әлфия Ситдыйкова иҗаты буенча әдәби композиция*

*(түбән сыйныф укучылары өчен)*

*Сәхнә көз аен хәтерләтә, сары яфрак,*
*көзге чәчәкләр белән бизәлгән. Көзге бакчада бишек тирбәлә.*
*Урындыклар урнаштырылган.*
*Талгын гына көй агыла, сәхнәгә укучылар чыга.*

**1 нче укучы:**

Алтын көзнең кочагына
Сыендым әле бүген.
Алтын бөртеге үзем дә
Туган ягым, илемнең.

**2 нче укучы:**

Кояш кыйпылчыкларымы? –
Йөзләрдә уйный нуры.
Бөтен дөньяга яңгырый,
Нәни йөрәкнең җыры.

**3 нче укучы:**

Нур сибелгән йөзләремә,
Күзләрем балкый нурдан.
Әйтерсең лә бөтен дөнья
Тора гел тоташ җырдан.

**4 нче укучы:**

Күр син, җиһан, минем күздә
Чагыла бәхет төсе.
Кешелек, Җир, Ватаныбыз
Балалар белән көчле.

*«Алтын көзнең кочагына»*

*Сәхнәгә алып баручы чыга.*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар. Бик дөрес язган шагыйрә апабыз.

Кешелек, Җир, Ватаныбыз
Балалар белән көчле.

Бу шигырь юлларының авторы – шагыйрә Әлфия Ситдыйкова. Бүген китапханәдә зур бәйрәм.

**1 нче укучы:** Ә нинди бәйрәм соң ул?

**Алып баручы:** Бүген шигырьләр сөйләрбез, шигъри уеннар уйнарбыз. Сезнең белән бергә шигъри бәйрәм ясарбыз.

*Талгын гына көй агыла.*
*1нче укучы бишектән курчак ала, шигырь сөйли,*
*2нче укучыга курчакны бирә, шул рәвешле,*
*курчакны кулдан-кулга биреп, шигырьләр сөйлиләр.*

**1 нче укучы:**

Кошлар җырлый, җырлый тамчы,
Җырлап гөрләвек ага.
Җырларыма дәрт, ямь өстәп
Дөньяга туды бала.

**2 нче укучы:**

Кечкенә дә, төш кенә лә,
Язның тәүге чәчкәсе.
Кулга ала аны назлап
Әткәсе һәм әнкәсе.

**3 нче укучы:**

«Бәхетле бул, тәүфыйклы бул,
И күземнең карасы!» –
Диеп, дога укый-укый
Сөя әби-бабасы.

**4 нче укучы:**

Җырлый урман, җырлый җиһан,
Җырлар төренгән назга.
Нәни кызчыгым туганга
Күңел тулышты язга!

*«Бәби тугач»*

*4 нче укучы курчакны бишеккә сала.*
*Укучылар утыралар.*

**Алып баручы:** Уңганнар, булганнар җыелган монда. Кечкенә сеңелегез дә шигырь тыңлап йокыга китте. Тәмле төшләр сиңа, сабый. Әнә кояш нурларын тагын да көчлерәк сибә башлады.

*Көй дәвам итә.*

**1 нче укучы:**
Нәни кояш нурын сибә
Өебезнең түренә.

**2 нче укучы:**
Чеңләп көлгән тавышыннан
Иркенәя күңелләр.

**3 нче укучы:**
Йомшак куллар иркәләнеп
Сарылганда муенга,

**4 нче укучы:**
Бәхет кошы, әйтерсең лә,
Оя кора куенга.

**1 нче укучы:**
Сандугач сайрый өздереп,
Балам җырлый үзгәрәк.

**2 нче укучы:**
Күңелле бакчабызда яши
Аллы-гөлле күбәләк!

*«Нәни кояш»*

**Алып баручы:** Әлфия Ситдыйкова шигърияттән башка яши алмый, аның тәненең бөтен күзәнәкләре шигырь белән сулый да, уйлый да. Ул төрле жанрда шигырьләр иҗат итә. Хәзер мин сезгә «омонимлы шигырьләр» укырмын, ә сез омонимнарны әйтергә тиеш буласыз. Ә омоним ул, исегезгә төшерәм – ике мәгънә аңлатучы сүзләр. Сез әзерме? Алай булганда, киттек!

*Талгын гына көй агыла.*

**Алып баручы:**

Кояш мангач җете **алга,**
Өзелеп төште безнең **алга,**
Тәгәрәде ике **алма,**
Бирсен ал син, бирсен **алма.**

**2 нче укучы:** Бу шигырьдә **АЛГА, АЛМА** сүзе ике мәгънәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Дәвам итәбез.

Нәни кызчык тәүге тапкыр
Басып килә ап-ак **карга.**
Гаҗәпләнеп, шул мизгелдә
Аваз сала кара **карга.**

**3 нче укучы:** Бу шигырьдә **КАРГА** сүзе ике мәгънәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Шигырьне укуны дәвам итәм, тыңлагыз.

Бу инешнең ике ярын
Тоташтыра такта **басма.**
Тар басмадан чыккан чакта,
Берүк сак бул, читкә **басма.**

**4 нче укучы:** Бу шигырьдә **БАСМА** сүзе ике мәгънәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Дәвам итәбез.

Ялгыз басып торам ярда,
Бәлки килер көткән яр да.
Җырлап ага көмеш **чишмә,**
Сереңне, дип, ятка **чишмә.**

**1 нче укучы:** Бу шигырьдә **ЧИШМӘ** сүзе ике мәгънәгә ия.

**Алып баручы:** Бик дөрес. Булдырдыгыз. Рәхмәт сезгә, балалар. Әлфия апабыз китаплар укырга ярата, кечкенәдән үк шигырьләр яза. Биредә дә китап укырга яратучылар җыелганнар. Ә сез уеннар яратасызмы?

**2-3 нче укучылар:** Яратабыз.

**Алып баручы:** Әйдәгез, бергә «Кем ул?» уенын уйныйбыз. Ничек дисезме? Мин сезгә шагыйрә апагызның тагын бер шигырен укыйм. Ә шигырьдә кем турында сүз барганны сез әйтергә тиешсез? Игътибарлы булыгыз, уенны башладык.

И матур ул, ягымлы ул,
Иң җылы куллар кемдә?!
Кем яратып, гел иркәләп,
Уята безне көн дә?
Кем чәчләрне тарап үрә,
Кем бәйли оекбашлар?
Безнең өчен иртүк торып
Пешерә тәмле ашлар?
Кайсыгыз белә җавабын,
Кем ул иң изге кеше?!
Шул зирәк балага куям
Иң олы билге – бишле!

*«Кем ул?!»*

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Бик дөрес, балалар. Дәү әни, Әби, Әни җавапларын әйткән балаларның барысына «5»ле билгесе куям. Безнең Дәү әни, Әби, Әниләребез гаилә учагын саклаучылар, тәмле ашлар пешереп, мәктәпкә озатырга да, йоклаганда бишек җырларын көйләргә дә вакытлары җитә аларның. Балалар, сезнең гаиләдә ничә кеше яши?

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Бик яхшы, кемнәрдер өчәү, дүртәү, хәтта алты кеше дә яшиләр икән. Ә шагыйрә апабыз гаиләсендә ничә кеше яшәвен беләсегез киләме?

**Укучылар бергә:** Беләсебез килә, килә.

**Алып баручы:** Алайса, игътибар белән тыңлагыз. Мин сезгә шагыйрә апаның тагын бер «Без ничәү?» шигырен укып китәм:

Әткәй, әнкәй, абый, энем,
Ничә кеше без өйдә?
Сана әле, әйдә, Алсу,
Зурмы безнең гаилә?
Әле безнең песи дә бар,
Исемнәре Мыраужан.
Шулай булгач, безнең өйдә,
Яши икән ничә җан?

*«Без ничәү?»*

*Укучылар җавабы.*

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез бергә саныйбыз.

**Җавап:** 1. Әткәй,
2. Әнкәй,
3. Абый,
4. Энем,
5. песи Мыраужан.

**Алып баручы:** Укучылар, бу уенны да җиңеп чыктыгыз. Ә безнең шигъри бәйрәмебез ахырына якынлашты. Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышланган әдәби композициядә катнашкан һәркемгә «5»ле билгесе куям.

**Файдаланылган әдәбият:**

Ситдыйкова, Ә. Омонимлы шигырьләр / Ә. Ситдыйкова // Көмеш кыңгырау. – 2010. – 13 март. – Б. 4.

Ситдыйкова, Ә. Серле дөнья: шигырьләр / Ә. Ситдыйкова. – Казан: Идел-Пресс, 2014. – 28 б.

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА**

# «Җаннар назга төренә»

### *Әлфия Ситдыйкова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция*

*(югары сыйныф укучылары өчен)*

*Сәхнәдә шагыйрә Әлфия Ситдыйкова китапларыннан «Җаннар назга төренә» дигән күргәзмә оештырылган, кечкенә өстәл, урындык урнаштырылган. Түргә экран куелган, диопроектор аша фильм күрсәтелә.*

*Музыка яңгырый, сәхнәгә алып баручы чыга.*

**Алып баручы:**

Кемгә җитми җылы, кем тилмерде
Ишетергә ихлас сүзләрне?!
Шигырь юлы аша җаныгызга
Назлап бага Сөю күзләре.

Булган байлыгымны сезгә бирәм,
Әй кешеләр! Сөю кирәкме?!
Сезгә барам, кулларыма тотып
Сөю-хискә тулы йөрәкне.

*«Сарыф ителмәгән сөю ага»*

**Алып баручы:** Менә шулай шигъри юллар белән шагыйрә Әлфия Ситдыйкова безгә, шигырь сөюче дусларына дәшә.

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле дуслар! Хәерле пәнҗешәмбе көннәре белән барыгызны да.

Хатын-кызның күңеле кызыклы шигъри халәттә йөзүчән. Иртәнге якта кояшлы яңгыр булып ява, кичен җәйге чиллә халәтен кичерә. Ул серле күңел эченә нәрсә генә сыймаган: кояш нурлары, чишмә шавы, яңа гына явып үткән яңгыр нәфислеге дә, нәни бала сулышы да.

**Алып баручы:** Бу күңел янында сак булырга. Җансыз затлар ул күңелгә ачкыч ярата алмый борылып китә. Ә җанлылар аны та-

гын да бизәп, нәкышләп, бер кочак матурлык өсти. Без бүгенге кичәбез героен, аның күңеленә бер кочак матурлык өстәргә теләп, бер кочак чәчәк бәйләмнәре белән сәхнәбез түрендә каршы алабыз.

**Алып баручы:** Безнең бүгенге кичәбезнең кунагы шәһәребездә яшәп иҗат итүче шагыйрә, дистәгә якын китап авторы, 2012 елның юбиляр шагыйрәсе Әлфия Ситдыйкова.

Әлфия ханымны сәхнәбез түренә чакырыйк әле.

*Сәхнәгә чыгып утыра.*

**Алып баручы:** Әлфия Мирзанур кызы Ситдыйкова 1957 елның 14 августында Актаныш районы Күҗәкә авылында туа. Туган авылында сигезьеллык мәктәп, 1974 елда Пучы урта мәктәбен тәмамлый. «КАМАЗ» заводында эшли. «Чаллы-ТВ» телерадиокомпаниясенең «Күңел» радиосында хезмәт куя.

Әлфия бер дистәгә якын китап авторы: «Йөрәгемә яфрак сыена» (2003), «Бер җылы сүз» (2004), «Җанымда кабынган учак» (2004), «Йөрәк сүзе йөрәккә» (2005), «Җаннар назга төренә» (2006), «Хисләрем канаты – Күҗәкә» (2006), «Назга сусау» (2006).

**Алып баручы:** Әлфия Ситдыйкова исеме шигырь сөючеләр өчен күптәннән таныш. Вакытлы матбугат битләрендә шагыйрәнең беренче шигырьләре 1977 елда күренә башлый. Быел бит икеләтә юбилей, иҗатына да 35 ел вакыт түгелме соң? 35 ел дәвамында Әлфия Мирзанур кызы инде шәһәребез шигырь сөючеләрен генә сөендереп калмый, аның әсәрләре бик еш кына республикабыз басмаларында да басыла: «Татарстан», «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан» журналы битләрендә, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан», «Шәһри Чаллы» газеталары битләрендә ул үзенең шигырьләрен бастырып, шигъри җанлы дусларыбызга җан өрә. Шуларга өстәп, Әлфия Сидыйкова тәрҗемә белән шөгыльләнә. Әлфия Ситдыйкова белән Вера Хәмидуллинаның уртак җимешләре булып ике телдә: «Туган якның ике чишмәсе», «Два родника родной земли» (2007) билингваль тәрҗемәләр җыентыгы дөнья күрә. 2012 елда шагыйрә, тәрҗемә өлкәсенә керткән эшчәнлеге өчен, А. С. Грибоедов премиясенә, истәлек медаленә лаек булды.

**Алып баручы:** Бүгенге кунагыбыз шагыйрә Әлфия Ситдыйкова ишле, җиде балалы гаиләдә үсә. Инде аны тудырган әти-әнисе бүгенге көндә мәрхүмнәр. Аның күңел түрендә әти-әнисенә карата ярату, хөрмәтләү хисләре шигъри юллар тудыра.

*Талгын гына музыка яңгырый.*

**Укучы:**

Җиде җанга гомер биргән Әнкәй
Җигелеп тартты тормыш арбасын.
Сыгылмый һәм сынмый яшәгәнгә
Дөньялыкта күрә савабын.

Безнең өчен яшәү өлгесе ул,
Һәрберебез өчен кадерле.
Әткәй биреп китте бәхиллеген,
Гомере дә шуңа хәерле.

Балаларың бик бәхетле, Әнкәй,
Бәхет өчен сиңа бурычлы.
Ныклы рухың, сынмас сабырлыгың
Көнләштерер иде корычны.

Бер җаныңа җиде шатлык сыеп,
Җиде тапкыр янып көйгәндер.
Маңгай, битләреңдә сызылып киткән
Буразналар шуңа тирәндер.

Синең куллар назы белән күчкән
Йөрәкләргә кояш җылысы.
Җидебездән җиде шатлык булып,
Бәхетләрнең килсен олысы.

*«Мин – җир кызы»*

**Алып баручы:** Шагыйрь халкы фантазиягә ифрат бай халык. «Бар байлыгы шул – фантазия дә хыял инде» – дисәләр дә, бу аның бәхете бит әле. Хыялы артыннан кош булып оча, күк гөмбәзен иңли, җир астына төшә, хикмәтле образлар иҗат итә. Бу сүзләрдә бер дә арттыру юк. Менә бер шигырь тыңлап үтик әле.

**Укучы:**

Җирдә туып, җирдә үссәм дә мин,
Күкләр белән җаным сөйләшә.
Күңел кылын чиртеп, шигъри телдә
Чиксезлектән уйлы өн дәшә.

Өн телендә язам шигыремне,
Һәрбер юлы моңга төренгән.
Җирдә туып, җирдә үссәм дә мин
Торам тоташ йолдыз сереннән.

Киек каз юллары буйлап атлыйм,
Ай балкыган төнге күкләргә.
Өн телендә язам шигыремне,
Бүләк булсын җирдә күпләргә.

*«Җирдә туып, җирдә үссәм дә мин...»*

*Музыка тына.*

**Алып баручы:** Әлфия ханым бүләк итеп безгә нинди шигырь юллары юллаган, рәхмәт сезгә. Менә бу урында Әлфия ханымга берничә сорау биреп үтәсем килә.

**Сорау:**

**Алып баручы:** Инде җаваплардан күренгәнчә, Әлфия тыйнак шагыйрә. Әлфия Ситдыйкова шигърияттән башка яши алмый, аның тәненең бөтен күзәнәкләре шигырь белән сулый да, уйлый да. Ни сәбәпле шулай диеп әйтәмме. Соң, шигырьләре дәлил булып тора.

**Укучы**:

Минем җаным шигырь белән сулый,
Шигырь белән назга туена.
Мин бит кердем ап-ак шигырь белән
Ак чәчәкле яшьлек туена.

Минем сулыш – шигырь сулышы ул,
Сулыш алам халкым өчен дә.
Гомер юлым һәрбер язган юлда,
Яшәү көчем шигырь көчендә.

Минем җаным шигырь белән сулый,
Яшәешем минем шигырьдә.
Язмыш язган бәхетемне таптым
Шигырь белән үргән гомердә.

*«Минем җаным шигырь белән сулый...»*

**Алып баручы:** Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова бик бәхетле шагыйрә, бүгенге көндә шагыйрәнең бик күп шигырьләрен композиторлар көйгә салганнар. Радио-телевидение аша без аны һәрдаим җырчыларыбыз башкаруыннан ишетеп торабыз. Белүемчә, иң беренче башлап, танылган җырчы-композитор Флера Талипова шагыйрә сүзләренә көй яза:

**Җыр:**

Олы бүләк итеп бу дөньяга
Алып килгән сине якты яз.
Якты язлар кебек киң күңелең
Мөлдерәмә тулы җылы наз.

Бәхет кошым, диеп, мине назлап,
Тик син генә әйтә аласың.
Авыр минутларда күңелемне
Юатырдай сүзләр табасың.

*«Бәхет кошым»*
*(Ә. Ситдыйкова сүз., Ф. Талипова көе)*

**Алып баручы:** Әлфия бала вакыттан бирле яза. Ул үзенең беренче шигъри тәлгәшләрен шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин, язучы Эдуард Касыймовларга укуы белән дә бәхетле. Шуларга өстәп, 1979 елда шәһәребездә дөнья күргән «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең беренче «Яшьлегем – Чаллы» китабына аның шигырьләре керү белән дә бәхетле шагыйрә. Ә хәзер «Яшьлегем – Чаллы» җыентыгына кергән бер-ике шигыреннән өзек сезгә дә ишеттерәсем килә:

Кар ява, кар ява. Күңелдә
Уяна шатлыклы хисләрем.
Төшерәм исемә шул чакта
Яшьлекнең тын, айлы кичләрен.

*«Кар ява, кар ява...»*

Киң кырларда хыялланып йөрим,
Йөрәк тулы зәңгәр моңнарым.
Тагын кайтам туган авылыма,
Җырлар белән тулган юлларым.

*«Йөрәк тулы зәңгәр моңнарым»*

**Алып баручы:** Әлфия шигъри тәлгәшләре белән яшәүгә сусаган җанын кешеләргә ачып күрсәтә белә.

**Укучы:**

Суынмагыз, хисләр. Күзләрдә дә
Сибә нурын күңел кояшы.
Күзләрдә бит гомер сүнә димик,
Күзләрдә дә була юл башы.

Суынмагыз, хисләр. Йөрәкләргә
Ябылмаган әле ишекләр.
Тибрәтә дә сезне, юата да
Талдан, наздан үргән бишекләр.

Суынмагыз, хисләр. Алда кыш бар,
Кыш салкыны үтәр йөрәккә.
Җырлап яшим, сандугачым сайрый
Күзләрдә дә, кунып тирәккә.

*«Суынмагыз, хисләр. Күзләрдә дә...»*

**Алып баручы:** Шагыйрәнең яшәеше, иҗаты өчен тагын бер чыганак – тирә-яктагы кешеләр. Ул кешеләр тудырган дөнья. Бу дөньяда шатлык та, сагыш та гаять күп, өмет белән өметсезлек тә җитәрлек. Аның, бүгенге көн кадагына суккан, Ана белән Бала проблемасына борчылып язган поэмасы моның бер дәлиле булып тора.

*Талгын гына музыка яңгырый.*

**Укучы:**

Яшьлек гүзәл... Ә шул гүзәллекне
Саклый алабызмы мәңгегә:
Кем югала юлда очрап упкын,
Кем сыгылмый биек үр менә...

...Алсу йөзле, кара бөдрә чәчле,
Зифа буйлы гүзәл сылуга
Әзерләнгән каһәрләнгән сөю –
Шулдыр сәбәп канат сынуга.

...Бала елый... Җиһан үкси... Үкси...
Әй адашты сөю, адашты.
Дөнья күзе бага каләм аша
Акылыннан язган карашны.

*(«Бала елый» поэмасыннан өзек)*

*Музыка тына.*

**Алып баручы:** Әлфия Ситдыйкованың күңеле мине үзенең байлыгы, серлелеге, нечкәлеге белән сокландырды. Аның күзләрендә – дөньяны яратуы чагыла, аны иртә таңнан назлап уяткан һәрбер иртәгә ул рәхмәтле, җан түрендә – моң, шигъри гамь ята. Аның басынкы, шул ук вакытта кызу сөйләшүе, күзләренең очкынланып китүеннән шуны күрергә була – ул тормышның сикелтәле юлларын көчле рухлы хатын-кыз булып узарга өлгергән. Шагыйрә күңел кылларының кырыгын да тибрәтеп хатын-кыз җанына мәхәббәт тулы шигъри юллар сарыла.

Сарыф ителмәгән сөю ага
Шигырь булып, минем күңелдән.
Гамь шәрабе эчәм. Чишмә булып,
Гасыр ярып җанга түгелгән.

*«Сарыф ителмәгән сөю ага...»*

**Алып баручы:** Әлфия Ситдыйкова иҗатына бик күп шагыйрьләребез үз бәяләрен бирәләр. Мин сезгә Әлфия ханымга багышланган бер-ике шигырь юлларын ишеттереп үтәсем килә:

Китабыгыз – кулда... Туганнарым белән
Сезгә кергәч бүләк иттегез!
Исләребез китте: сеңелебез белән
Игезәкләр кебек икегез!!
Үзегезне, никтер, «Шагыйрә» дип
Санамыйсыз әле санавын...
Әмма хисләрегез – ташкын кебек! –
Хәтерләтә яшьлек язларын...
Һәрчак шулай үзегез булып калып,
Нур чәчегез ошбу дөньяга!..

...Ишетәсезме, Сезгә котлау булып,
Үзегез язган моңлы көй ага!..
Гомер буе моңсу яшәмәгез –
Сезгә елмаю бик килешә!..
Чынга ашсын бар хыялларыгыз
Яшәгәчтен шулай тиеш тә!..

*Шаһинур Мостафин, 2003 ел*

Август аенда тугангамы,
Кояш кебек җылы, якты син.
«Мин – җыр кызы, җирдә тудым...» диеп
Язуың белән дә хаклы син.
Туган ягың туфрагында шытып,
Яр Чаллыда канат яргансың.
Әдәбият дөньясында бүген
Үз урының таба алгансың.
Күпме җырлар, шигъри гөләндәмнәр
Бизи гомер китыбыңның битләрен.
Ак кәгазьгә иелеп күңелең түгеп
Үткәрәсең иртә, кичләрең.
Арысланнар көтү белән йөрми,
Син бик горур, кыю, Әлфия!
Талантың һәм гүзәллегең күреп
Олпат ирләр хәтта баш ия.
Бәхеткә һәм мәхәббәткә лаек
Син, дускаем, якты дөньяда.
Балаларың, оныкларың үссен
Син саклаган ныклы ояда.
Сәламәтлек – ярты бәхет, диләр,
Бәхеткәең булсын түгәрәк.
Әле тагын бик күп бәйрәмнәрне
Каршыласак иде бергәләп.

*Наилә Хөрмәтова, 2003 ел.*

**Алып баручы:** Әлфия ханымның «Назга сусау» шигъри җыентыгына тукталасым килә. Китапка кереш сүзне шагыйрь Рәдиф Гаташ язган. Кереш сүздән берничә юлларын укып үтәм:

*«...Башкалар җанына тирән үтеп кереп, аңлап, кушылып яну һәм эчкерсез саф хисләрдән матур тәкълид китабы тудыру өчен Шигъриятне, Кешеләрне, башка Каләм ияләрен югары кимәлдә ярату талантың булу кирәктер, мөгаен... Бу – сирәк йөрәкләр бәхете.*

**Алып баручы:** Язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Галимҗан Гыйльманов Әлфия Ситдыйкова иҗатына карата язган бәяләмәсендә мондый юллар яза:

*«...Туган җир – шагыйрә өчен матур сүз яки хатирә генә түгел. Аның өчен туган җир – сихри көч тә, кендек әбиләренең изге догасы да, аналарның таң җиледәй йомшак кулы да, кояш яктысын капларга тырышкан «кара хәбәр» дә, «күңел түреннән шытып чыгып, хәтер каберенә тамган гөлләр» дә, су баса дип күчерелгән күрше авыл шәүләсе дә...».*

Әлфия үзенең тулы бер җыентыгын туган ягына багышлап «Хисләрем канаты – Күҗәкә» исеме астында чыгара. Ә 2010 елда, авылдашы Рәскать Хәертдинов белән бергә, авыл тарихын, шигъри, публицистик язмалары тупланаган «Авыл җаны – Күҗәкә горурлыгы» дип аталган саллы гына китап дөнья күрә. Әлфия Ситдыйкова һәрдаим авылдашларының, районнашларының көчле иңсәләрен тоеп иҗат итә:

Коштай очып үз ягыма кайтам,
Дәрьяларны иңләп гизгәндә.
Җанда сусау, күңелемдә бушлык,
Ә тәнемдә ару сизгәндә.

Тышаусыз ат сыман бар хисләрем
Ычкыналар шул чак йөгәннән.
Әйтерсең лә яланаяк калып
Бала чагым чаба үзәннән.

*«Коштай очып үз ягыма кайтам...»*

**Алып баручы:** Шагыйрәнең күңеле нечкә, хисле. Шигъри юлларыннан күренгәнчә ул һәркемгә рәхмәтле. Аның якын кешеләре: балалары, оныклары һәрдаим Әниләренең җылы, ягымлы карашын тоеп яшиләр. Әле бик күп еллар шагыйрәбезгә ана назы сирпеп яшәргә язсын. Әлфия ханымның үзе язган шигырь юлларын үзенә үк бүләк итеп юллыйсы килә:

**Укучы:**

Ана өчен иң зур шатлык җирдә
Нарасыен алса кулына.
Тәрбияләп, назлап, белем биреп,
Чыгаралса тормыш юлына.
Тәүфыйклы һәм гадел булса балаң,
Шатлык белән тула күңелең.
Икеләтә арта дөнья яме,
Икеләтә арта бәхетең.
Кызым белән улым үсеп җитте,
Минем дәвам – якты өметем.
Балаларым өчен яшим җирдә,
Балаларым – минем бәхетем.

*«Ана бәхете»*

**Алып баручы:** Кичәбезне Әлфия Ситдыйкованың оптимист рухта язылган бер шигыре белән тәмамлыйсы килә.

Мин дөньяга килгән чакта
Гап-гади бала идем.
Үсә-үсә йөрәгемә
Салдым бар гамен илнең.

Җир сулышы, чор сулышы
Күчте минем җаныма.
Кешелекне төреп яшим
Йөрәк, күңел җылыма.

Әйтсен халкым, бу балам да
Тапты дип үз сукмагын.
Мин яратам үз халкымның
Ярлысын һәм сукбаен.

Җырым таяныч булганда
Атлармын армый алга.
Тормыш – диңгез дулкыннары
Какканчы соңгы ярга.

*«Мин дөньяга килгән чакта...»*

**Алып баручы:** Әлфия Мирзанур кызына иҗат уңышлары телибез. Беркайчан да бәхет, шатлык читләтеп үтмәсен. Бик күп еллар сау-сәламәт булып дусларын, туганнарын, иҗатташларын сөендереп яшәргә, эшләргә, иҗат итәргә насыйп булсын.

**Файдаланылган әдәбият:**


Яшьлегем – Чаллы: шигырьләр / төз., Равил Лотфуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 1979. – Б. 69–73.

Ситдыйкова, Ә. Йөрәгемә яфрак сыена: шигырьләр / Ә. Ситдыйкова. – Чаллы, 2003. – 128 б.

Ситдикова, А. Два родника родной земли / Туган якның ике чишмәсе: шигырьләр / А. Ситдикова, В. Хамидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2007. – 207 б.

Ситдыйкова, Ә., Хәертдинов, Р. Авыл җаны – Күҗәкә горурлыгы. Авыл тарихы, шигъри, публицистик язмалар / Ә. Ситдыйкова, Р. Хәертдинов. – Казан: 2010. – 328 б.

# Кушымта

## *Гаилә архивында сакланган кайбер фотосурәтләр*

 

**Әнисе Гөлсем, әтисе Мирзанур**



**Әткәй-әнкәй кочагында (уртада утырганы Әлфия)**



**Балаларым – тормыш гөлләрем...**
**Уңнан сулга: Илдар, Гөлназ, Диләрә, Камилә, Зөлфия, Владислав.**



**Туганнар бергә җыелгач. 2014 ел**



**50 яшь тә тулды... Яр Чаллы, Үзәк китапханә, 2007 ел**



**Әдәбият музеенда.**
**Уңнан сулга: Әлфия Ситдыйкова, Марс Ягудин, Рәкит Әбделманов, Фәния Хамматова, Мансур Сафин, Факил Сафин, Зөләйха Минһаҗева, Вахит Имамов, Роза Хәмидуллина, Рәшит Бәшәр. Яр Чаллы, 2008 ел**




**Язучылар сабантуенда.**
**Уңнан сулга, 2 рәт, 6 нчысы Әлфия Ситдыйкова. 2011 ел**



**Уңнан сулга: Роза Хәмидуллина, Сирень Якупова, Нәҗибә Сафина, Әлфия Ситдыйкова. 2011 ел, 20 ноябрь**



**Мәскәү язучысы Александр Тимофеевский янәшәсендә. 2012 ел**




**Казан кунаклары килгәч.**
**Яр Чаллы Үзәк китапханәсендә**



**Язучы Газиз Кашаповны искә алу кичәсеннән**



**«Үзәк китапханә бергә җыйды».**
**Уңнан сулга: Галимҗан Гыйльманов, Факил Сафин, Разил Вәлиев, Лилия Газизова, Равил Фәйзуллин, Вера Хәмидуллина, Рәзин Нуруллин, Әлфия Ситдыйкова, Зиннур Мансуров.Казан, 2012 ел**



**Зиче мәктәп укучылары янәшәсендә. Яр Чаллы, 2012 ел**



**Әлфия Ситдыйкова, Вахит Имамов, Нәҗибә Сафина, Рәшит Бәшәр, Рәзинә Сәетгараева, Роза Хәмидуллина. Әдәбият тарихы музее, 2014 ел**



**Дания Сибгатуллина, Факил Сафин, Әлфия Ситдыйкова.
16 январь 2014 ел**



**Алматыдан кайткан милләттәшебез Сания Галиева
«Мәйдан» журналында кунакта.
Баш редактор Вахит Имамов һәм Әлфия Ситдыйкова. Яр Чаллы**



**Бертөркем язучылар шагыйрь Харрас Әюпов авылында.**
**Мөслим районы, Түреш. 31 май 2016 ел**




**Бөтендөнья татар конгрессы баш референты Илдар Мингәрәев,**
**Рәзин Нуруллин янәшәсендә**




**Рабит Батулла «Әдәби Чаллы» китабы белән таныша. Казан, 2015 ел**




**Чаллы язучылары Татарстан язучылар берлегендә очрашуда.**
**Казан, 27 декабрь 2015 ел**



**«Ләйсән»ле еллар**



**Остазыбыз халык шагыйре Рәдиф Гаташ юбилее кичәсеннән соң.**
**Казан, 30 март 2016 ел**



**Олпат шәхесләр янәшәсендә.**
**Уңнан сулга: Хатыйп Минегулов, Вера Хәмидуллина,**
**Әлфия Ситдыйкова, Разил Вәлиев, Данил Салихов, Роза Хәмидуллина.**
**Казан, 2016 ел, 30 март**



**Шагыйрә 12 нче мәктәп укучылары янәшәсендә.**
**Яр Чаллы, 2016 ел, 11 март**



**Татарстан дәүләт радиосында кунакта.**
**Уңнан сулга: Нәсим Акмал, Фәния Хамматова, Раил Садри, Әлфия Ситдыйкова, Рәзин Нуруллин, Роза Хәмидуллина.**
**Казан, 2017 ел, 10 февраль**

# Күрсәткечтә кулланылган газета-журналлар исемлеге

# Использованные газеты и журналы

Авыл утлары (Мөслим)
Актаныш таңнары (Актаныш)
Безнең фикер (Яр Чаллы)
Ватаным Татарстан (Казан)
Идел (Казан)
Казан утлары (Казан)
Кама таңнары (Яр Чаллы)
«КАМАЗ» хәбәрләре (Яр Чаллы)
Көмеш кыңгырау (Яр Чаллы)
Мәдәни җомга (Казан)
Мәйдан (Яр Чаллы)
Новое время (Удмуртия)
Нур (Яр Чаллы)
Өмет (Казан)
Светлый путь (Яр Чаллы)
Сөембикә (Казан)
Таң йолдызы (Яр Чаллы)
Шәһри Чаллы (Яр Чаллы)
Шәһри Казан (Казан)
Якты юл (Яр Чаллы)
Яңарыш (Ижау)
Яңа вакыт (Оренбург)

# Эчтәлек

# Содержание


Укучыга / К читателю ....................................................................5

«Моң булып синдә таралам...» ........................................................7

Шагыйрәнең кыскача биографиясе ...............................................10

Краткая биография ..........................................................................13

Әлфия Ситдыйкованың басылып чыккан китаплары /
Изданные книги Альфии Ситдиковой ..................................19

Әлфия Ситдыйкованың «Садик» сериясендә
басылган китаплары ..............................................................21

«Садик» сериясендә дөнья күргән
тәрҗемә китаплары ...............................................................21

Вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән әсәрләре ................24

Вакытлы матбугат битләрендә басылган мәкаләләре ...................34

Әдәби җыентыкларга кергән әсәрләре, мәкаләләре /
Публикации в коллективных сборниках / ...............................44

Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова тәрҗемәләре /
Переводы Альфии Ситдиковой ...............................................48

Иҗат һәм тормыш биографиясе ......................................................51

Ә. Ситдыйкова сүзләренә иҗат ителгән җырлар .........................61

Шагыйрә Ә. Ситдыйкова фотолары урын алган җыентыклар ....65

Награды и поощрения ....................................................................66

## I. ЭФИРДА –«КҮҢЕЛ» РАДИОСЫ

Сәмум җилен җиңгән әдип гомере... ....................................70
Сибелсә дә татар чит җиргә... ............................................74
Яралы халык җанын сүз белән бәйли... ...........................79
Халкыбызның үз шагыйре ...................................................83

## II. ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Сандугачлы таңнарга гашыйк... ........................................89
Тәкъдимнамә .........................................................................90
Җанда шәмнәр янганда... ....................................................92
Тәкъдимнамә .........................................................................93
Игелекле каләм иясе ...........................................................95
Офыгы киң, күге биек .........................................................96
«Йөрәгемә яфрак сыена» ....................................................106
Шигырь күзләрендә сөю һәм наз... ..................................107
Ләйләләр телгә килсә... ......................................................109
Иҗатында язмыш бар .........................................................110
Тугандыр ул моңга уралып ................................................113
Рекомендация ......................................................................115
Где живёт счастье ...............................................................117
Тәкъдимнамә .......................................................................120
Каршылык көчен буйсындыр! ..........................................121
Сабантуйга кайткач... .........................................................126
«Сөюләрсез тормыш – буш мәгарә...» ..............................129
Утлы җимешләрдән авыз иттем .......................................134
Чаллы шагыйрьләренең иҗат үзенчәлекләре .................136
Өзелмәсен хәтер җепләре ...................................................138
Төрле әдәби очрашулардан ...............................................141
Китап укучыларыннан хатлар ...........................................151
Актаныш таңнары!.. Кем генә белми бу җырны,
кем генә эченнән көйләми?! ............................................153

Әлфия Ситдыйковага багышланган шигырьләр
Синең дөньяң ....... 154
«...Теләкләрнең телисең син...» ....... 155
«...Укыдым да хатларыңны...» ....... 156
«...Бу януың, дөрләп кабынуың...» ....... 157
«...Хисләр тулы шигырь китабыңны...» ....... 158

## III. МӨЛДЕРӘМӘ ТУЛЫ КҮҢЕЛДӘН...

Яңа ел курантлары ....... 160
«“Бишле” билгесе куям» ....... 166
«Җаннар назга төренә» ....... 172
Кушымта ....... 183
Күрсәткечтә кулланылган газета-журналлар исемлеге / Использованные газеты и журналы ....... 196

**Альфия СИТДИКОВА**

*(Биобиблиографический указатель)*

**Әлфия СИТДЫЙКОВА**

*(Биобиблиографик күрсәткеч)*

Төзүче: *Р. Г. Хәмидуллина*
Мөхәррир: *Ф. Х. Хамматова*
Корректорлар *Р. М. Насыйбуллина, Г. Р. Әхмәтшина*
Техник мөхәррире *И. З. Фәррахов*

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ
от 29.12.2010 г. № 436 – ФЗ.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 16.10.2017.
Форматы 60х84 $^{1}/_{16}$. Тиражы 1000 д. Заказ

---

Редакционно-издательский центр «Школа».
420111, Казань, Дзержинского, 3. Тел.: 292-24-76.
Отпечатано на множительном участке центра.